РӘИС САФИН

БЕР МӘХӘББӘТ ТАРИХЫ

ШКОЛА
Казан
2006

УДК 820/89 (470).0
ББК 84 (2 Рос = Тат) - 44
С 21

Сафин Р.А. Бер мәхәббәт тарихы. – Казан: РИЦ «Шко-
С 21 ла», 2006. – 228 б.

© Сафин Р.Г, 2006
© РИЦ «Школа», 2006



ТӘКЪДИРЕНӘ КАЛӘМ ЯЗЫЛГАН

Бу дөньяда адәм баласы качып котыла алмый торган ике генә нәрсә бар. Аларның берсе – Әҗәл, икенчесе – Иҗат. Әгәр якты дөньяга Хак Тәгалә тарафыннан шагыйрь, язучы – иҗатчы булырга хөкем ителеп килгәнсең икән, буйсынмаска, ризалашмаска тырышып күпме генә тартышсаң да, иртәме-соңмы, беркөн барыбер шушы тәкъдирең килеп тотачак. Иҗатка хөкем ителү... Әлеге китапның авторы Рәис Сафин белән дә шулайрак булды бугай.

...1990 елларда Татарстан радиосында «Һәр күңелдә шигырь уты бар» дигән нәни генә тапшыру ачып җибәргән идем мин. Хәзер дөресен әйтсәң дә ярыйдыр: аның идеясен «Мәдәни җомга» гәзитеннән «суккан» идем. Менә шул тапшыру, алдан уйланганча, башкаларга сиздерми генә, күңел юанычы өчен генә каләм тибрәтүчеләрнең көчләрен сынап карау мәйданына әверелде. Әйбәтен әйбәт, әмма бик тә кыйммәткә төште бу эш миңа, ник башлаганыма үкенеп бетә алмадым. Баксаң, безнең милләттә язмаган кеше юк икән ул! Радио ишек төбенә кочак-кочак шигырь күтәреп килүчеләрнең су буе чираты сузылды. Ул шигырьләрне укый-укый күзләр калмады. Аптырагач, качып йөри башладым үзләреннән. Менә шундый гасаби көннәрнең берендә эш

бүлмәсенең ишеген кыяр-кыймас кына ачып, яше олыгаеп баручы бер агай килеп керде. Тыйнаклыгына һәм үтә дә нәзәкать белән сөйләшүенә карап фикер йөрткәндә, теге «шигырь язучылар» армиясенең әрсез-һавалы солдатларына бер дә охшамаган иде ул. Гомер күрмәгән-белмәгән шушы кеше белән ничектер җайлы гына сөйләшеп-аралашып кителде. Чөнки аның күңелендә гаҗәеп ихласлык, фикер сөрешендә олпат затларга гына хас саллылык бар иде. Сөйләшкән саен үзенә тарта, үзенә тартылырга мәҗбүр итә торган күңел. Аны тыңлаганда дуамалланып чапкан вакыт үзе дә уйга калып, салмакланыбрак ага башлагандай була. Юлларда буталып йөреп, әткәм янына киңәшкә кайткан кебек хис иттем мин үземне.

Озак сөйләштек. Яңа танышым Рәис абый Сафин бары хушлашканда гына шигырьләре тупланган куен дәфтәрен калдырып китте. Радиодан сөйләтү өчен дип түгел, болай гына, бәя ишетү өчен генә дип бирде ул аны. Ләкин ул шигырьнең ни-нәрсә икәнен инде бик тирәннән аңлаган кеше буларак, минем бу шигырьләрне тән буе йотлыгып-озгәләнеп укыячагымны да, шул төндә үзем өчен яңа бер шагыйрь ачачагымны да яхшы белгәндер. Шулай булды да. Халык җыры кебек гади дә, халык җыры кебек мәгънәле дә иде ул шигырьләр.

Соңыннан белдем: Рәис абый, гәрчә яшьлегендә Казан университетының журналистика бүлеген тәмамласа да, гомере буе әдәбияттан, иҗаттан ерак эшләрдә хезмәт куйган. Гади завод эшчесе булып башлап, зур гына оешмаларның җитәкчесе дәрәҗәсенә кадәр күтәрелгән. Каләм дигәнең аңа шигырь язар өчен түгел, мөһим документларга имза салу өчен генә хезмәт иткән. Тормыш шулай үз мәшәкатьләре, үз сөенечләре белән җай гына агып барган бер көндә гомерен бағышлап сөйгән яры, тугрылыклы тормыш юлдашы —

Саниясе, күңеленә төзәлмәс яра салып, якты дөньядан Мәңгелеккә китеп бара. Әнә шул тетрәнү Рәиснең бәгърен яргалый да, йокысыз төннәрнең берендә сагыну-сагыш шигырь булып саркый башлый:

Гөлләреңне төсең итеп
Саклыйм тәрәз төбендә.
Гөлләрең тәрәз төбендә,
Үзең – күңлем түрендә...

Әнә шул чакта кабынган шигырь утының әле дә сүрелгәне юк. Шагыйрь яккан шигъри учак һаман саен яктыра, ул учактан җан җылысы алучылар ишәя бара.

Бу хәлләрдән соң инде Рәис Сафин республика матбугатендәге мәкаләләре белән үзен милләт язмышын кайгыртучы, тирән фикерле публицист буларак та танытты. 2005 елда аның «Йөрәк парчалары» дигән шигъри җыентыгы дөнья күрде. Шушы җыентыкта урын алган «Ана» поэмасы шигырь сөючеләр тарафыннан үзгә бер җылылык белән кабул ителде, һәм аның кайбер юллары халык теленә канатлы сүзләр булып кереп китте.

Ә инде бу китапка кергән «Бер мәхәббәт тарихы» бәяны – язучының иң уңышлы чәчмә әсәрләреннән берсе. Ул 2004 елда «Идел» журналында басылып чыкты һәм шушы журналны, кулдан-кулга йөреп, таушалып бетәргә мәҗбүр итте. Күпләрне уйлаткан, елаткан гыйбрәтле һәм кызыклы әсәр ул. Бу китапны кулыгызга алгансыз икән, димәк, ул Сезне дә төн йоклатмый уйлатачак, Сезне дә елатачак!

«Сәфәр чыктым хәтер буйлап...» әсәре исә автобиографик характердагы парчалардан гыйбарәт. Китапны акча түләп кенә яздырып та, бастырып та була торган шушы заманга җиткәч, андый автобиографик повесть вә романнарны күп күрергә туры килде безгә. Тик кайчандыр кайдадыр нәчәлник булып торган агайларның «хезмәт батырлыкла-

ры» бәян ителгән һәм әдәби әсәр булудан ерак тораган мондый мактанчык китапларны укучы гына юк. Ә менә Рәис Сафинның парчалары Сезне укырга, алай гына да түгел, үз кәһарманнары белән бергәләп сөенсергә, көенсергә, алар мохитында яшәпararга мәҗбүр итәчәк. Моңа иманым камил. Чөнки автор безне хәтер буйлап сәяхәткә алып кереп китеп, үзенең еллар дәвамында тупланган тормыш тәҗрибәсе, яшәү фәлсәфәсе, дөньяга карашы белән таныштыра, гомер юлында үз янәшәсендә атлаган гыйбрәтле язмыш ияләре белән очраштыра. Әнә аның ак яулыклы әнисе — кешеләргә игелек кылудан гайрене белмәгән татар хатыны Хәбибҗамал, ярын сөеп, балаларына терәк булып яшисе урында яу кырында ятып калган, ил өчен гомерен биреп тә, власовчы-сатлыкҗан дигән кара исем алган әтисе Габдуллажан. Әнә гомере буе зимагурлыкта йөреп, бурлак арканы каешлаган җилкәсенә биштәрен салып туган авылына кайтып егылган Галиулла бабасы, сагыну-сагышларга түзә алмыйча, ФЗӨ дән качып киткән Нәҗип абыйсы, халыкның канын эчеп яшәүче урман каравылчысы Сафа, кешеләргә этлек эшләүдән ләззәт табучы өлкән мастер... Рәис абыйның, бары аның язмыш юлында очраган реаль шәхесләр булар. Ләкин алар без дә белгән, без дә аралашкан кешеләр булып күз алдына килеп баса. Чөнки алар язучы каләме белә җанлы типик образлар югарылыгына күтәрелгән. Һәм ахырда автор үзенә таныш аерым шәхесләрнең генә түгел, тулы бер заманның җете төсләр белән башкарылган күпкырлы портретын, аның чынбарлыгын сурәтләүгә ирешкән.

Хәер, әйдәгез язучы каләме тудырган шушы тылсымлы дөньяга бергәләп сәяхәткә кузгалыйк!

Нәсим АКМАЛ

УЛ МИНЕ УТЛАРДА ЯНДЫРДЫ ДА

Үзенең яралмыш көненнән башлап, кеше мәңгелек двигательләр булдыру турында хыялланган. Баксаң-күрсәң, бу мәңгелек двигатель аның үзендә икән ләбаса! Әгәр без Җанны мәңгелек дибез икән, димәк, әнә шул Җан дигәнебез мәңгелек двигатель була түгелме соң инде?

Мәхәббәтне дә мәңгелек диләр. Күңелебездәге бу изге хисне, мәңгелеккә таба йөз бага. Димәк, ул да әлеге дә баягы, туктаусыз эшләп торган мәңгелек двигательнең бер төре була инде...

Шушы һич сүнмәс-сүрелмәс, ләззәтле һәм газаплы мәхәббәт хисе хакында бу хикәятем.

Вакыйга болай булды. Хәрби хезмәттән кайтып, башлыкүзле булырга уйланып йөргән көннәрнең берендә Казанның Гладилов урамында урнашкан җитен комбинатында эшләүче Хәтирә җиңгәмә әйтә куйдым:

– Комбинатта эшләүче иң чибәр, иң күркәм, иң ягымлы берәр кыз белән таныштыр әле, – дидем.

– Бар ул андый кыз, – диде җиңгәм.

Әйткән сүз – аткан ук дигәндәй, шушы «иң-иң» дигән чибәр кыз белән җиңгәм эштән соң бергә чыгарга тиеш булды. Ә калганы инде – минем эш.

Сүз куешканча, кичке сәгать ун тулыр-тулмаста, элекке Алафузов йорты, хәзер Җитен комбинаты клубы булган йортның почмагына килеп бастым. Икенче сменада эшләүче хатын-кызлар шушы вакытларда, төркем-төркем булып,

өйләренә кайтырга чыга. Ара-тирә ир-атлар да күренгәләп куя. Болары инде токарь, дежур слесарь, станокларны көйләүче кебек эшчеләр булырга тиеш. Комбинат эшчеләренең күбесе – Җиләкле, Пороховой бистәләрендә, Бишбалта төбәгендә яшәүче кешеләр. Алар бер-берсен генә түгел, гаиләләрен дә яхшы белә, тормыш-көнкүрешләре белән дә якыннан таныш. Бер-беренә кунакка, чәй мәҗлесләренә йөрешәләр. Кияү-киленнәрне дә ерактан түгел, үз араларыннан табышалар, гөрләтеп туй итәләр, гаиләләр корып, тату гына яшәп яталар. Җиләкле бистәсендә үскән егет булгач, миңа да монда эшләгән кызларның күбесе таныш дияр-лек. Петров паркында йөреп-йөреп тә, күңелгә ошаган кыз очрамаса, без, егетләр, берәм-берәм Җитсп комбинатының проходной ишек төбенә, кызлар каршы алырга килеп баса идек. Монда алар тансык түгел. Күңленә охшаганын кул-тыклый аласың, йә инде иске танышларыңнан берәрсен эләктерәсең. Әлбәттә инде, аның йөргән егете булмаса, йә култыкларга соңга калмасаң.

Шушы озатып куйган, каршы алган кызларның күзләренә бик чалынмас өчен, күләгәлерәк урынга посып, җиңгәмнең һәм әлегә таныш булмаган кызның эштән чы-гуын көтә башладым. Ләкин, кеше күзенә никадәр генә күренмәскә тырышып карасам да, июль киченең әңгер-мең-гере, проходной алдында балкып янган көчле прожектор-лар яктысы, таныш-белешләрен эзләгән кызларның үткен карашларыннан яшерә алмады мине.

– Рәис?! Әйдә, алып кайтам! – ди берсе.

– Ничек туймыйсың кызлар озатудан? Кемне каршы алырга килдең? – ди икенчесе.

Менә шундый сүзләр әйтеп, янымнан уза тордылар. Ә мин карашымны проходной ишегеннән алмыйм, дүрт күз белән тегеләрне көтәм. Күңелем бер урында басып тора ал-

маган колын кебек тыпырчына, ашкына, кинәт-кинәт эсселе-суыклы булып, сулышым тотлыгып кала, тәнем калтыранып куя. Эчемнән бөркелгән эссе сулыш ирексәремне киптерә. Үземне никадәр генә тынычландырырга тырышсам да, һич кенә дә булдыра алмыйм. Әйтерсең, мине алда ниндидер хәвеф-хәтәр сагалый, шомлы, таныш булмаган, сәер бер билгесезлек көтә. Күңелемне биләп алган тынгы-сызлык, бөтен эчемне дерелдәтә.

Инде проходной ишегеннән чыгучылар да сирәгәя ба-рып, бөрән-сәрәнгә генә калды. Алары да – йә ир-атлар, йә олы яшьтәге хатын-кызлар. Әллә инде кайтып киттеләр микән? Әллә мин күрми калдыммы үзләрен? Әнә шундый уйлар да борчый башлады күңелне. Нишләргә соң инде? Кайтып китсәм... Инде чыгасы булсалар, бу кадәр соңга калмаслар иде шикелле...

– Ярар, – дим мин үз-үземә, ниһаять, бер карарга килеп. Әгәр күрми калган булсам, иртәгә дә көн бетмәгән ич! На-сыйп булса, күрешербез. Әүвәле-ахыры гына хәерле булсын... Ә бүген инде, килгән-килгән, берочтан күрше урам кызы Рәхимәне озатып куярмын. Аларның эрләү цехы эшне ярты сәгатькә соңгарак калып бетерә, көтим инде, булмаса.

Шундый уйлар белән, бераз тынычлана төшеп, тәмәке кабызып җибәрдем. Проходнойга каршы баганага барып сөялдем. Карыйм, ишектән ике хатын-кыз чыкты. Йа Раб-бым, бу минем Хәтирә җиңгәм ләбаса! Кинәттән генә кау-шап та калган кебек булдым. Җиңгәм тирә-ягына карана башлады. Мине эзли инде. Тәмәкемне ташлап, аларга таба аныктым.

– Исәнмесез?! – диешеп, үзара сәламнәребезне дә алыш-тык.

Мин нәрсә әйтергә белми торганда, җиңгәм ярдәмгә килде:

– Син инде, Рәис, бераз көттергәнгә ачуланма. Хатын-кыз шулай озаграк җыенучан инде ул, – диде.

– Юк-юк, һич кенә дә ачуланмыйм, – дидем мин тотлыга-тотлыга.

Җиңгәм сүзен дәвам итте:

– Таныш бул: бу – Фәния исемле кыз. Без аның белән бергә эшлибез.

Аннан соң Фәниягә әйтте:

– Ә бу – минем кайнэнем Рәис була, сиңа сөйләгәнем бар кебек...

Каушавым узган кебек иде инде. Фәниягә төбәлеп карадым: гүзәл кыяфәтле, зифа буй-сынлы кыз басып тора иде. Бирсә дә өеп бирер икән Аллаһы Тәгалә бер бәндәсенә шушы кадәр камиллекне! Дөньяда илаһи әсәрләр язарга илһам биргән, бер күрүдә үзенә гашыйк итәргә, газиз башларын жуярга сәбәбче булган гүзәл затлар аз булмаган. Ләкин күбесенең бик үк килешеп җитмәгән, кимчелекле яклары да булмаган түгел. Ләкин Фәниягә табигать искиткеч гүзәллекне, ир-егетләр хыялларында йөрткән сылулыкны, ыспайлыкны шулкадәр төгәл үлчәп биргән ки, һай, бу жире болайрак булган булсачы диярлек аз гына да кимчелек юк иде.

Йөзендәге беленер-беленмәс алсу аклык, балкып торган кап-кара күз алмаларының ягымлы елмаюлары... Алар, зәңгәр диңгездә йөзүләреннән туктап калган кораблар кебек, мица тобәлгәннәр. Чак кына өскә кайтарылган озын кара керфекләр салмак кына сирпеп, шушы сихри күзләрдән нур бөркү. Маңгай читенә таба нечкәреп килгән кап-кара кашлары, күңелне тылсымлап, үзләренә тартып тора... Фәниянең беренче карашка кечкенәрәк күренгән, әмма йөзенә гаҗәеп бер ямь биргән борыны да үзенә килешеп кенә тора иде. Әнә шул «йөз күрке» дип аталган борын, кешенең йөзен

генә бизәп калмый, ул аның холкын-фигылен, эчке халәтен дә ачыклый бит әле. Ә Фәниянең борыны, аның ачык күңелле, оптимист рухлы икәнлеген искәртә. Өстәвенә, күңел көзгесе булган сихри кара-көрән күзләренә, балкып торган йөзенә, чак кына турсайган жыйнак авызына, үтә сөйкемле, нәфис иреннәре арасыннан энҗе бөртекләре кебек тезелеп киткән ап-ак тешләренә бербөтенлек, төгәллек биреп, аларны бизәп торучы таж да бит әле ул борын дигәнең!

Иягенең уң ягында ярымай сыман түгәрәк җәй дә үзенә күрә бер бизәк кебек булып тора.

Менә шушы кыяфәттә күрдем мин беренче мәртәбә Фәнияне.

Без кайтыр юлдан атлап киттек. Күп тә үтмәдек, Фәния туктап калды.

– Мин кайтып життем, – дип, хушлаша да башлады. Җиңгәм дә, аның кайда торганын белгәнгә күрә, хәерле төн, тәмле матур төшләр күрүен теләп, өйгә ашыкты. Ә мин алдан ук әзерләп куйган сүзләремне бутый-бутый, абынасөртенә әйтә куйдым. Имеш, комсомол поручениесен үтәп, аны өенә озатып куярга тиеш булганмын.

– Әгәр комсомол йомышын йомышлап кына йөрүең булса, син аны жиренә житкереп үтәдем дип исәплә, – диде Фәния. – Син мине озатып куйдың, рәхмәт. Мин шушы йортның икенче катында торам.

Фәниянең тавышын беренче тапкыр ишетүем. Бу басынкы аваз каяндыр ерактан, күңеленең түреннән килә иде. Әйтерсең, ярларны инләп-колачлап, салмак кына аккан дәрья...

Фәния Гладилов һәм К.Либкнехт урамнары кисешкән чаттагы йортта яши булып чыкты.

– Әнә, әнием минем кайтканны көтеп утыра. Мин кайтмыйча, ул утын да сүндермн, йокыга да ятмый...

– Эш урының бик якын икән синең...

– Әйе, якын. Бик якын. Ераграк булса, әйбәтрәк булыр иде. Юкса, эштә дә шул җитен исе, җитен тузаны, өйдә дә

Ул кабарып, дулкынланып торган маңгай чәчләрен төзәткәләп куйды:

– Безнең цехта бик тузанлы. Һәр көн эштән соң душта юынырга туры килә Кайчакларда чәчләрем дә кибеп бетәргә өлгерми кала.

Ул үреп салган калын, кара толымнарын кулларына алып, сыпырып куйды. Алардан берничә тамчы су, сыгылып, җиргә тамды. Ул да булмады, Фәния күрсәткән тәрәзә ачылып китте.

– Фәния! Кер инде, вакыт соң! – дигән тавыш ишетелде.

– Әнә, әни чакыра да инде. Хушлашыйк, алайса...

Мин аның кулларын учларына алып:

– Аз гына торыйк инде? – димәкче булдым.

Ләкин ул кулларымны сак кына этәрде, ягымлы гына елмайды:

– Әнинең иртән иртүк торып эшкә китәсе бар. Хуш, сау бул! – дип, кереп тә китте.

Бу күрешү бик кыска гына булса да, бөтен эчке дөньямны актарып-үзгәртеп ташлады. Җаным җырлады, күңелем мөлдерәмә булып тулды. Минем әле җырлыйсым, әле тирәякны яңгыратып кычкырасым килде, күңелем, шашып, каядыр ашкынды. Йөгерәсем, сикерәсем, тагын әллә ниләр кыласым килде. Җемелдәп торган йолдызларга очтым, төшеп җирне кочтым. Бөтен җаным-тәнемне моңарчы миңа билгесез булган илаһи бер хис чолгап алды. Тамырларым буйлап әле кайнар дулкыннар йогереп үтте, әле салкынча дерелдәвек күмеп китте. Әгәр юлымда очраган берәрсе миннән бер-бер яхшылык кылуымны үтенсә, мин моны, шиксез, шундук үтәр идем.

Кызларны берәнче тапкыр гына озатып куюым да түгел, югыйсә. Ләкин менә мондый хәлнең бервакытта да булганы юк иде миндә. Чын мәхәббәт дигәннәре әллә соң шушы була микән? Ә бит Фәния белән минем арада искитәрлек берни дә булмады! Ул хәтта кулыннан тотарга да рөхсәт итмәде. Нилектән уянды бу шашкын хисләр, йөгәнсез тойгылар?!

Ул төнне мине йокы алмады. Моңарчы һич башка килмәгән уйлар диңгезендә йөздем. Әйтеп бетергесез ләззәтле, татлы иде алар. Мин берәнче мәртәбә туачак балаларым – улларым, кызларым турында уйландым. Аларның нурлы йөзләрен күргәндәй булдым.

Җанга рәхәтлек биреп, күңелне иркәләп торган бу уйлар һич кенә дә туйдырмады. Аларны уйлаган саен уйлыйсы килеп торды. Таң беленеп, офык читләренә яктылык куна башлаганда гына йокыга киткәнмен.

Көннәр бер-бер артлы уза торды. Фәния белән очрашуларыбыз, тора-бара бер тәртипкә кереп, гадәткә әйләнде. Әгәр аның берәнче сменада эшләгән чагы булса, атнаның һәр чәршәмбесендә кич күрешеп, йә кинога барабыз, йә Петров паркына чыгабыз.

Һай, ул чакта парктагы тамашалар, андагы күңеллелек, хозурлык! Алар шул чорның яшьләре күңел түрендә, мәңге онытылмас хәтирәләр булып, сагынып сөйләргә генә калдылар шул. Футбол кырыннан башка җирен ун минут эчендә әйләнеп чыгарлык, төрле агачлар кочагына төренеп утырган шушы парк яшьләрнең очрашып, танышып-дуслашып, гомергә бергә булырга вәгъдәләр бирешкән иң кадерле, иң яраткан бер урыны иде. Бүгенге заман яшьләренең аерылмас иярченнәренә әйләнгән, көне-төне күзләрен багып, мәкиббән китеп утырырдай компьютер кебек мавыктыргыч техника җиһазлары турында хыяллана да, күз алдына да

китерә алмый идек әле без. Әйе, паркта яшьләр шыгрым тулы була. Аның үзәк юлы бигрәк тә шимбә, якшәмбе көн кичләрендә тыгыз була. Икешәр-икешәр дә, бишәр, алтышар булып та култыклашкан Җиләкле, Пороховой, Биш-балта кызлары паркның бер очыннан икенче очына, күлдә йөзгән аккошлар кебек, салмак кына, туктый-бара йөриләр. Кайсыларының егетләре килеп җитмәгән, ә кайсылары әле танышырга өлгермәгән. Алар артыннын күзе төшеп йөргән кызны аерып алырга кыюлыгы җитмәгән, кулларындагы «спорт», «норд» кебек, арзанлы папирусларын суырган егетләр, уйнаша-көлешә бара. Кызлар да, егетләр дә сөйгәне белән танышу турында хыяллана, яшерен мәхәббәт утында яна. Бары тик бер өмет – гомерлек тормыш юлдашын очрату өмете алып килгән аларны бирегә. Бу төркемнәр җәйге кино залы каршындагы мәйданчыкта түгәрәк ясап, ду килеп биегән егет-кызларга килеп кушылалар. Ә түгәрәк зурайганнан-зурая бара. Биеп арганнары, янә култыклашып, парк буйлап йөри китәләр.

Ә түгәрәк эчендә, өермәдә бөтерелеп, яшьләр бии. Кайсыларының сәләтен, нечкә зәвык белән башкарган бию алымнарын күреп шаккатасың. Ә бит ул үзе башкалардан бернәрсәсе белән дә аерылмый кебек.

Шагыйрь әйтмешли, талантлы шул, бәек шул халык. Очыныш-очыныш биегән егет үзе ошаткан кыз янына килеп, ата каз кебек тыпырдый башлый. Ә кыз чыгарга ашыкмый, ялындыра, егетне сыный. Сабырлыгы бармы, имеш, күпмегә җитәр түземлеге? Кешенең үзеннән сорама, сүзеннән сора, дигәндәй, юк кына очраклар кайчак кешенең чын йөзен ача, аның холкын чагылдыра бит. Әгәр чакыруы ихлас күңелдән икән, димәк, нияте дә чын йөрәктән. Көн үздыру өчен генә йөрүчеләрдән түгел. Кызлар да кимен куймый. Егетләр алдына килеп, шундый итеп басалар ки, үзе-

не утлы табада кебек хис итәсең. Аларның тылсымлы елмаюлары, мәхәббәтләре ташып торган сихри күз карашлары алдында үзең дә сизмәстән тыпырдый башлыйсың. Хәтта бии белмәсәң дә.

Биюләрдән ял иткән бер арада чая кыз-егетләр йөзек салу кебек уеннар оештыралар.

Бу төр уеннар да егет-кызларны бер-берсе белән таныштыруда, кавыштыруда үтә дә сыналган һәм ышанычлы чара иде.

Гармунчы, баянчылары да үз егетләребез инде. Нәҗип абыйның Вараксин гармунын уйнап, икешәр көн барган туйларда утырган мине дә читтә калдырмыйлар иде. «Гармуныныңбармаклары саен мәхәббәт аның!» Хак сүз. Гел мине күздә тотып әйтелгән сүзләрдер бу.

Гадәттә, паркка кичке тугызларга яшьләр күпләп җыелган була. Бу вакытта «Ильич лампалары» паркны балкытканбию мәйданчыгында оркестр дәртле вальс яңгырата башлый. Яшьләрнең бер ише (күбрәге урыслар) танцы мәйданчыгына юл тота. Ә татар яшьләре, әлеге дә баягы түгәрәкләрдә биеп күңел ача, парк сукмакларын таптап, йөрәк серләрен уртаклаша.

Һәр чор яшьләренең үзенә генә хас, кабатланмас үзенчәлекләре, аерым төсмерләре, холык-фигыльләре була. Әлбәттә инде, уңышлары һәм җитешсез яклары да булмый калмый. Безгә, черек бәрәңге ашап үскән сугыш чоры балаларына, сугыштан соңгы тормыш-көнкүрешнең авырлыгын күрергә дә, тормышның әледән-әле яхшыра барганына шаһит булырга да туры килде. Ит һәм башка затлы ризыкларны алырга хәлебездән килмәсә дә, ипи-күмәчкә маргарин ягып, шикәрне чәйгә теләгәнчә салып, авыз тутырып ашау бәхетенә ирештек. 400-500 сум хезмәт хакыннан берәр яңа күлмәк алып кию зур бәйрәмнәрдә генә эләкте. Кешеләр

тыйнак киенеп, тыйнак ашап-эчеп, тыйнак гомер иттеләр. Ир-егетләрнең өстендә – мамык тукымасыннан тегелгән тупас костюм, кыш көне – телогрейка, хатын-кызларның балтырларын каплап торган чәчәкле күлмәкләре гап-гади ситсалардан иде. Боларның барысы да заманына күрә зур казаныш булды. Беркем дә беркемнән көлмәде, көнләшмәде. Барына канәгать булып, шөкерана кылып яшәде.

Уңъеллык белеме булган егет-кызлар сирәк иде. Чөнки сигезенче класстан соң укулар түләүле булды. Шуңа күрә җиде класс белем норма саналды. Бу иш яшүсмерләр, икеелльщ һөнәр училищеларында укып, фабрика-завод һөнәрләрен үзләштерде. Ә 5-6 класслылар ФЗӨләрдә төзүче һөнәренә өйрәнде. Ул заман егет-кызларының барысы да диярлек шушы иш кешеләре иде. Күбесе абый-апасыннан калган кием-салымнан йөрде.

Элегрәк паркка керү түләүле булды. Әлбәттә, безнең ише койма башыннан йөрүчеләр өчен түгел, ә үзләрен җиткән егет санап, сөйгән кызы белән килгәннәр өчен. Һәм итәкләре очлы тимер койма башына эләгеп, асылынып калудан курыккан кызлар өчен. Югыйсә, аларның да бер ишләре койма аша керүдән әллә ни тартынып тормый иде.

Фәния белән паркны берәр кат әйләнеп, дус-ишләр белән күрешеп-исәнләшеп, биешеп тә алгач, Татарстанның 10 еллыгы исемендәге мәдәният сарае янәшәсендәге аулаграк аллеяларның берсенә чыгып, утыргычта сөйләшеп утырырга яратабыз. Әлбәттә, күбрәк мин сөйлим. Чөнки, ни әйтсәң дә, хәрби хезмәттә булып, егерме өченче яшен җыйган егеттә азмы-күпме тормыш тәҗрибәсе дә булгандыр, күргән-белгәннәр дә аз түгел иде. Памир таулары арасында өч ел ярым илебез чиген саклап үткән гомер үзе генә дә ни тора?! Ә Фәния – ул әле тормышка яңа аяк басып, тәүге адымнарын ясаучы, унсигез яшен дә тутырмаган кыз бала. Шу-

ның өстенә, мин – аның беренче мәхәббәте дә. Бәлкем, шуңа да аның сораулары күбрәк балаларныкына хас. Ләкин мин аларның һәркайсына, Фәниянең хәтерен калдырмаслык итеп, тулы итеп җавап бирергә тырышам. Чөнки ул сораулар «аптыратыймамы-тинтерәтимме?» өчен, сүз югында сүз булсынга гына бирелгән сораулар түгел, ә бәлки эти кеше тәрбиясе күрмәгән кыз баланың самими сораулары иде. Бу сорауларда яшь кызны борчыган күп төрле аңлаешсыз мәсьәләләрне ачыклау теләге бар иде. Без икебез дә бер үк язмыш кешеләре идек. Икебезнең дә әтиләребез сугыш кырыннан әйләнеп кайтмаган. Икебез дә шул чорның ач-ялангач тормышын үз башларыбыздан үткәргән.

Минем үземә Фәния белән аулакта, үзебез генә калып сөйләшеп утырулар бик тә ошый. Аның янымда булуы мина рәхәтлек бирә. Мин аннан күземне алалмыйм. Моны үзенә никадәр генә сиздермәскә тырышсам да, күз карашларыбыз әледән-әле очрашып тора. Аның елмайганда йөзендә балкыган нурларны күреп сокланам.

Фәния кирәккә-кирәкмәскә авызын колакларына кадәр житкереп, җәелеп китми. Кайбер кызлар кебек юк кына нәрсәдән дә чыркылдаучылардан түгел. Көлсә дә, чамасын белеп кенә, тыйнак кына итеп көлә. Көлгәндә дә тавышы тыныч, басынкы, ишетелер-ишетелмәс кенә булыр. Күз карашлары да, кешеләрне үтәли тишеп чыгарай, утлы-ялкынлы түгел, ә бәлки иртәнге кояш нурлары кебек җылы, ягымлы, иркәли торган карашлар. Оялчан көрән-кара күзләре сиңа бер дә текәлеп бакмас. Читлегеннән очып чыгарга теләгән кошчык сыман, күлмәген төртеп торган тылсымлы күкрәкләренә, җырларда җырланган шикелле нечкә, нәфис билләренә кулларым ялгыш кына тиеп китсә дә, бөген тәнем буйлап ниндидер сихри көч йогереп үтә, миңа эсселе-суыклы булып китә. Мин аның күркәмлеген күреп ләззәт алам,

затлы гүзәллегенә тан калам. Фәниянең шушы искиткеч күркәмлеген, эчке гүзәллеген әйтеп күпме генә шигырьләр язсам да, андагы сыйфатларның кечкенә генә өлешен дә ачып җиткерә алмадым кебек. Хатын-кызның илаһи гүзәллеген тулысы белән чагылдырырлык сүзләрне эзләп табу мөмкин түгелдер ул! Чәчәкләр никадәр генә сокландыргыч, гүзәл, сылу, күркәм, матур булмасыннар, ләкин алар хатын-кыз белән тиңләшә алмыйлар. Чөнки алар тере түгел.

Аулак урыннарның берсендә утыруыбызның тагы бер сәбәбе: кайчакларда парктагы егетләр арасында килеп чыккан каршылыкларны җайга салуда минем катнашым кирәк була иде.

Тормышта көтелмәгән очраклы хәлләр, телисеңме-теләмисеңме, сине үзгәртә дә куя. Син башка яссылыкта, башка тормышта яши башлыйсың. Минем белән дә шулай булды. Бишбалта егетләре белән үзебезнекеләр арасында килеп чыккан бер каршылыкны берүзем диярлек уңышлы хәл итүем мине «крутой егет» ясады да куйды. Чик сакчысы булып хезмәт иткәндә өйрәнгән төрле көрәш алымнары теге егетләрне җирдә тәгәрәтеп йөртте. Шул көннән башлап моның ише каршылыкларны минем аша чишү гадәткә кереп китте. Аннан соң мин гармунчы буларак та Җиләкле, Пороховой бистәләрендә яшәүчеләр өчен билгеле кеше идем. Хәтта әниемнең әйләнә-тирәдә танылган Хәбибҗамал абыстай булуы, тайган аяк-кулларны «эһ» дигәнче урынына утыртып, сынганнарын оста төзәтә белүе, сөлекләр салып та, башка төр алымнар белән дә халыкны дәвалавы миңа абруй китерде. Мин абыстай малае, табиб малае булып йөрдем.

Әгәр инде Фәниянең икенче сменада эшләгән атнасы булса, мин аны эшеннән каршы алырга барам. Без, бер-беребез белән озак күрешми торган мәҗнүн гашыйклар сыман,

ашкынып күрешәбез. Никадәр генә сагынышып, күңелләребездәге ташкын хисләребез мөлдерәп ташыса да, эш җитәкләшеп барудан гайре узмый. Бер-беребезнең кулларын кысып тотудан рәхәтлек алабыз, үзебезне күкнең җиденче катында кебек тоябыз. Фәнияләрнең ишек төпләреннән ерак китмичә бер-ике әйләнүгә, әнисенең: «Фәния, кызым, кер, вакыт!» дигән сүзләре безне киләсе күрешүләргә кадәр аерып куя.

Бу урында шуны да әйтү кирәктер: мин Фәниянең әнисе Бибигайшә апаны бервакытта да күреп-танып белмәдем. Ләкин ул, әниемнең якын ахирәте буларак, бездә еш булган икән. Хәтта үләренә берничә атна кала да, кереп, әнием белән бәхилләшергә онытмаган. Безнең гаиләләребезнең бөтенлеген саклап, Фәниянең әнисе икәнен белгертмичә, безнең яраларыбызны яңартмыйча, серне яшереп саклый белгән бу ике әулия анага Аллаһының мең-мең рәхмәтләре ирешсен. Авыр туфраклары – җиңел, урыннары җәннәттән түрендә булсын. Нәрсә турында гәпләшкән алар, боларның барысы да инде мәңгелек сер булып калды.

Шимбә көннәрдә эш бер сәгатькә иртәрәк тәгәлләнә иде. Фәния душка кереп, җитен тузаннарын юып, проходнойдан чыкканда төн пәрдәсе әле төшеп кенә килгән чак була. Кино залларында инде соңгы сеанслар ахырына якынлашып килсә дә, паркта усннарның иң кызган чагы.

– Юк, паркка ук барып тормыйк инде, – диде бервакыт Фәния, тубыгына кадәр төшкән толымнарын сыпырып. Алардан әле тамчылар саркый иде. Без, гадәттәгечә җитәкләшеп, туктый-бара, тын урамнарны кат-кат урыйбыз. Сүзләребез сирәк булса да, бер-берсенә тоташкан кулларыбызның кайнарлыгы җелекләребезгә кадәр үтеп кера. Безнең җаннарыбыз, тәннәребез сөйләшә, иң мөкатдәс серләре белән бүлешә, гажәеп бер кичерешләр кочагында рәхәтләнә.

Без, әледән-әле тукталып, бер-беребездән күзләребезне ала алмый карашып торабыз. Бу халәтне аңлатырлык сүзләр дә табып булмас кебек. Шул ук вакытта күңелемне авыр шом биләп ала. Кисәк-кисәк миңа эсселе-суыклы булып куя. Әйтерсең, алда мине хәвеф, борчу көтә. Әйтерсең, Фәния белән бу соңгы очрашуыбыз һәм аерылу сәгатьләре якынлаша бара. Әйтерсең, нидидер явыз көч, арабызга кереп, безне мәңгегә аерырга тели. Фәния никадәр генә ягымлы итеп елмаерга тырышса да, аның да күзләреннән нидидер моңсулык бөркелә, сагыш барлыгы сизелә. Хәерлегә генә булсын инде...

Без алар тәрәзәсе каршыннан үткәндә әнисе:

- Фәния, озак йөрмә! Инде керсәң дә вакыт булыр, - дип әйтеп калды.

Ә вакыт дигәннәрең һаман уза торды. Кешеләр һаман саен сирәкләнә барып, урамнар да тынып калды. Фәнияләрдән ерак түгел капка баганасына сөялеп, без дә туктап калдык. Мин аның биленнән сак кына кочып, алсу иреннәренә үрелдем. Безнең иреннәребез бер-берсенә кушылып эреган кебек булдылар. Тәннәребез бер-беренә сыеныш бербөтенгә әйләнде. Йөрәкләребез дә берүк ешлык белән, берүк дәрт белән типте, алар бер-берсе белән сөйләшә, алай гына да түгел, бер-берсен кочып иркәләнә, сөешә иделәр. Бу безнең, икс ай буе йөреп, беренче мәртәбә үбешүебез булды. Һәм... соңгысы да булган икән. Әйтерсең, без бу үбешүне һаман саен кичектереп килгәнбез дә, хушлашу мизгеленә мәңге онытылмас кадерле хәтирә булып калсын дип саклаганбыз. Менә, инде кырык алты ел гомер үтсә дә, бу беренче һәм соңгы үбешүнең сихри тәэсире, ләззәтле тәме минем иреннәремдә һаман да саф һәм пакь, хуш исен югалтмаган хәлдә саклана.

Беренче мәртәбә бер-беребезнең куеннарына елышып,

мәхәббәт диңгезендә йөздек. Беренче мәртәбә аның күз явын алырдай тырпаеп торган күкрәкләреңнең тәнемә төртеп китүен тойдым. Һай, никадәр рәхәт иде миңа! Аларның кагылып-кагылып китүләре җанымда ут кабызды. Тәнем тоташ ялкынга уралды. Мин беренче мәртәбә мәхәббәт дигән хиснең илаһи кодрәтен тойдым. Шул ерак үткәннәрдә кабынган хисләрем, әле тына төшеп, әле янәдән дөрләп кабына китеп, һаман дәвам итә. Ул хис миңа сихәт, яшәргә дәрт бирә. Мәңге сүнмәс хис булган мәхәббәтне йөрәгемдә, җанымда-тәнемдә йөртүемә мин бик канәгатьмен һәм үземне бәхетле кеше итеп сизәм. Шушы олы, изге хискә ия булмаганнар, аның ләззәтле мизгелләреннән татымаганнар - олы бәхеттән мәхрүм калган мескеннәрдер.

Төнге тынлыкны да, безне дә сискәндереп, Бибигайшә апаның кырыс тавышы ишетелде:

- Фәния, син кайда? Яхшы чакта кер, хәзер үк!

Без, тыннарыбызны да чыгарырга куркып, шыпырт калдык. Фәния миңа тагын да ныграк елыша төште. Бибигайшә апа янәшәбездән генә үтеп китсә дә, безне күрмәде. Әллә без капка баганасына әверелдек микән? Бибигайшә апа, сукрана-сукрана, өенә кире кереп китте.

- Өйгә керергә вакыт. Юкса, әни кирәкне бирер! - диде Фәния, борчылып-уфтанып.

(Алга китеп шуны да әйтергә кирәк: Фәниянең «Юкса, әни кирәкне бирер», - дигәне рас булган. Кызы кайтып керүгә: «Әтиең булмагач, мине тыңламаска булдыңмени, басымчак итәргә уйладыңмени! Мин сине шуның өчен, үзем ач торсам да, сиңа булсын дия-дия үстердеммени?» - дип, елый-елый, уклау белән тукмаган әнисе. Бу хакта мин кырык алты ел гомер узгач, әле шушы көннәрдә генә Фәния белән беренче тапкыр күрешкәч белдем. «Әни тукмаса да, мин бернинди авырту сизмәдем кебек», - диде Фәния. Ул

бу сүзләрне шулкадәр битарафлык белән әйтте ки, минем йөрәгем сыкрап-чеметеп куйды. Бу сүзләрдән гомеренең ничек үткәнен бераз күзалларга була иде).

Ә тегә чакта, ул өйгә кереп китәргә җыенганда, сүзләремә шаярту төсе бирергә тырышып әйттем:

- Унсигез яшен тутырып килгән бердәнбер кызына кул күтәрмәс лә инде? - дидем.

- Моңарчы андый хәлнең булганы юк иде. Әниемнән дә төнлә үземне эзләтеп йөреткәнем булмады, - дип көрсенде Фәния.

- Әллә икәү керәбезме? Эләксә, икебезгә дә эләгер?!

- Юк ла инде.

- Карале, әйтергә онытып торам икән, мине колхозга эшкә җибәрәләр бит әле.

- Кайчан?

- Бүген сәгать иртәнге унга, кирәкле әйберләрне алып, завод проходное янына килергә тиешмен. Аннан автобусларга утыртып җибәрәчәкләр, ди.

- Кайсы районга икән?

- Лаешка, диделәр.

- Ә укуын? Беренче сентябрьгә дә күп калмады ич.

- Алыштырырбыз, диделәр.

- Бер айга! Ничек түзәрмен мин бер ай буе сине күрмичә? Мин хәзер үк сине сагына башладым бугай инде. Юк, бармыйсың. Мин сине җибәрмим! - Фәния мине кысып кочаклап алды. Ул җиңелчә генә калтырана иде. - Рәис, жаным, барма... Аерылышмыйк, тап сәбәбен.

- Сәбәбе юк. Бармый калу да мөмкин түгел. Мин бит комсомол комитеты әгъзасы. Мин дә сине күрми тора алмам. Уңае чыккан саен кайтырга тырышырмын.

Фәниянең күкрәгемә иелеп төшкән башын сак кына

күтәреп, күзләренә карадым. Алардан яшь бөртекләре тама иде.

- Кадерлем, сугышка китмим ләбаса.

- Китмәсәң дә, күңелем нәрсәдер сизенә, нидер булыр кебек... Бу безнең соңгы күрешүсебез булмасын иде дим...

Фәния яшьле күзләрен сөртеп алды һәм шулкадәр моңсу, шулкадәр үзәк өзгеч итеп карады ки, мин тетрәнеп куйдым. Үземне дә ниндидер шом биләп алды.

- Барысы да әйбәт булыр, - дип кенә әйтә алдым.

Без, өйгә кайтырга кирәк икәнен дә онытып, бер-беребезне кочаклаган хәлдә тынып калдык. Күңелемне күңелсез уйлар тырнаштырып алса да, миңа бик тә рәхәт иде.

Алга китеп шуны янә искәртим: башка беркайчан да Фәния кочагындагы ләззәтне тоярга насыйп булмады миңа. Тормышым, ир кеше башкарырга тиешле вазыйфаларымны механик рәвештә үтәп, узды да китте. Һай, дип сөйләрлек, сагынып искә алырлык, гомернең асыл бизәкләре булырлык, аңа мәгънәви кыйммәтләр бирерлек бер генә хатирә дә хәтердә уелып калмады. Югыйсә, хатыным Сания белән ил-җирләрне күрдек, курорт- санаторийларында ял иттек. Тик боларның барысы да шулай булырга тиешле хәл-вакыйгалар шикелле генә булып калды. Чөнки тормышта җан җылылыгы, мәхәббәт кайнарлыгы булмаган. Кадерләнеңнең кочагында кадерләнеп, кадерленне кадерләп яшәү генә чын яшәү була икән шул.

1998 елны, ничә көтмәгәндә, хатыным Сания вафат булды. Әнием вафатыннан әле айнып та бетмәгән чагым иде, язмышның кинәт кенә бу кырыс борылышы авыр тәэсир итте. Читлеккә ябылган ятим жан иясе кебек, ике бүлмәле фатирыбызда бер үзем утырып калдым. Йокы бүлмәсенә керсәм - әни ятагы буш, залга керсәм - безнең ятагыбыз нәүмизләнеп, хуҗабикәсен көткән кебек. Лоджига чыксам

– анда Саниянең гөлләре боегышып утыралар. Хәтта су сипкәнгә дә исләре китми. Сагыну-сагыш гөлләргә дә хас икән. Үземне инде – әйткән дә юк. Җанымда юксыну, башымда мең төрле уйлар давылы. Шул хәлгә килеп життем ки, эчемдә кайнаган кайгы-хәсрәт, шашкын хисләрем язгы ташкын кебек ургылып, бугазыма төер булып утырды. Мин, ирексездән, кулыма каләм алдым һәм жанымда вулкан булып атылырга торган уй-хисләремне кәгазьгә күчерә башладым. Бу минем, алтмыш өч яшен тутырган кешенең, ижат башы булды. Мөлдерәмә күңелем ташыды да ташыды, шигырь юллары агылды да агылды. Дөресен әйтергә кирәк: бу югалтуларны мин бик авыр кичердем. Ни генә булмасын, хатын белән утыз алты ел бергә тормыш ителгән. Гомернең иң матур чоры – дәрт-дәрман ташып торган, жир жимертеп эшләгән, аяк тибеп яшәгән, тырыша-тырмаша балалар үстергән иң күркәм, иң күңелле һәм кайнар чоры үтелгән.

Шигырьләремне Саниягә багышлап яза тордым һәм үземне борчыган сорауларны үз-үземә бирә тордым. Саниягә багышланган шигырьләремдә, хәтта поэмаларда мин әллә нинди, эчкерсез бер мәхәббәт сурәтләнүен тойдым. Ничек була соң инде бу? Әйткәнемчә, бергә гомер иткәндә безнең арада мондый кайнарлык, мондый хисләр юк иде бит! Бу табышмакны ничек аңларга? Уйлый торгач, мин шундый фикергә килдем.

Бу якты дөньяда яшәгән гажәеп бер вакытларда, бигрәк тә гомеренең яшьлек чорында, күкләрне ярып яшьнәгән яшен кебек, мәхәббәт хисе кагылып үтә кешегә. Бу хис бөтен күзәнәкләргә сеңә, күңелләрне өермәдәй туздырып ташлый, жаннарда ярату-сөю давылы куптара. Кайберәүләрдә бу хәлләр шулкадәр көчле була ки, кеше акылыннан язар хәлгә житә, уйлау-фикерләү сәләтен югалта. Давыл-өермә узгач, гадәттәгечә, янә ялтырап кояш чыга. Янә барча жан иясе, барча тереклек аның рәхимле нурларында коенып сихәт ала, тормыш янә үз кануннары кысаларына әйләнеп кайта.

Без, кешеләр, табигать балалары буларак, табигатьтә барган галәмәтләр кебек, төрле сыйфатларга кереп тормыш кичерәбез. Тик бу галәмәтләр, безнең күңелебездә яшен тизлегендә ялтырап, кояш кебек балкып үтәләр дә, аларның тәэсире-көче гомеребез буена житә. Бу күренеш бары тик аерым бер мизгелләр арасында гына булып алса да, аның яктылыгы, аның балкыш көче шулкадәр куәтле була ки, шифалы энергиясе, шәфкатьле нурларының жылысы гомер буена житә. Кешe гомере буе алардан көч-куәт, илһам алып яши. Югыйсә, күп кенә парларның мәхәббәт кояшы, күңелләрдә иң мөкатдәс хисләр уяткан балкышы башка берәүне яратудан, аңа гашыйк булудан балкыган булса да. Алар да шушы балкыш тәэсирендә калып, шул башка берәүгә багышланган сихри хис-тойгыларны хәләл жефетләре белән бүлешеп, үзара ихтирамлы, хөрмәтле мөгаләмәләр урнаштырып, тормышның бөтен шатлык-кайгыларын уртаклашып, көн күрүләреннән канагать булып яши бирәләр. Шушы төтрыклы халәтне гомерләренең соңгы минутларына кадәр саклап калалар. Мин дә менә шундый затларның берсе булдым кебек...

Дөрес, кайберәүләрнең мәхәббәт кояшы баеган, күңелләренә хыялый өметләр биреп торучы хисләр балкышы сүнгән була. Ләкин аларның күбесе гаиләне таркатмый, балаларны ятим итми, аларны тәрбияләүне үзләренең изге бурычлары санап, бөтен булган наз-яратуларны аларга биреп, сыкрана-сыкрана булса да гомер итәләр. Алар, күктәге ай кебек, үз гаиләләренә жан жылысын түгел, яхшылык кына биреп яши. Жылылык булмаган жирдә чын яшәү дә юк, бәхет-шатлык та булмый. Шуңа күрәдер, кайберәүләр жан жылысын, күңел назын читтән эзләргә мәжбүр, ә кайберәү-

ләре, эчүгә салышып, күңелен хәмер белән баса. Һәм якты дөньядан вакытыннан элек китеп тә бара...

Менә хәзер югарыда әйтелгән: «Ничек итеп хатыным Саниягә иң мөкатдәс хисләрем белән сугарылган шигырьләремне багышлый алдым икән», дигән сорауга бернигадә җавап та таптык кебек. Күңел түрләреннән саркып чыккан, җан газабы белән сугарылган ул шигырьләрнең язылуына иң беренче чиратта ул – минем беренче һәм соңгы мәхәббәтем Фәния сәбәпче икән бит!

Яшьлектә тапкан саф мәхәббәтемне югалтудан, шул илаһи мөхәббәт кояшын балкыткан җан иясен сагынудан, ул кадерле кешенең, һич тә истән чыкмый, гомер буе хәтердә йөрүеннән тугандыр ул шигырьләр. Нәкъ аңа багышлап әйтеләсе бу сүзләр Сания исеме аша дөнья күргәндер. Кеше күңеле – укылмаган китап, серле табышмак, диләр бит. Аның тирәнгә яшерелгән бу серләрен әлегәчә берәүнең дә белеп бетергәне булмады һәм булмас та кебек. Чөнки күңел, җан хәятә тик бер Аллаһы Тәгаләнең тиңсез кодрәтенә генә бәйле.

Менә, таң да ата башлады. Кояш әле үзе күренми. Ләкин аның якты нурлары, сәкаларга сузылып, офыкларны алсу төскә манды. Бу алсулык һаман өскә таба сузылып, һаман саен киңәя, яктыра барып, күкнең йөзен ап-ак нурга төрде. Аның кояш чыгышы ягы шул кадәр пакь, чиста ки, анда бер генә тап әсәре дә юк, бер генә нокта да күренми. Шушы искиткеч ап-ак һәм пакь җәймә уртасында яткан сабый бала сыман итеп, иртәнге август кояшы елмайды. Аның шифалы җылы нурлары Җир-Анага үрелеп, барча җан ияләрен, барча тереклекне иркәли башлады. Аллаһы Тәгаләнең чиксез рәхмәте белән, искиткеч матур яңа көн туды. Мин Фәниягә карадым. Аның да йөзендә, күктәге манзара кебек, искиткеч күренеш иде. Бит урталарындагы алсулык-

ның әйләнә-тирәсен күктәге кебек аклык кочып алган. Елмаюлы ягымлы йөзеннән таң сафлыгы бөркелә. Мөлдерәтеп караган ягымлы күз карашларыннан нурлар сибелә. Бу нурлар аның эченнән балкып ургыла сыман. Мин ике кояш уртасында торып, ике кояшның да иртәнге саф нурларында коенам.

Әйе, татар хатын-кызларының шәфәкъ алсулыгы иңгән йөзләреннән таң нурлары сыман нурлар бөркелүе серак әби-бабаларыбыздан килә. Бу нурлар әле төрле төрки кавемнәр булып яшәгән чорлардан алып, буыннардан-буыннарга күчеп, милли нурларыбызга әйләнгән. Алар Бөек дала гүзәллеге белән кушылып, аның сафлыгын, пакьлеген үзләштереп, даладагы мең төрле шифалы үләннәрнең, гөлчәчкәләрнең хуш исләрен сеңдергән төс нурлары. Әби-бабаларыбызның Ислам динен кабул иткәннән соң иңгән иман нурлары. Аллаһы Тәгаләнең сөекле мәселманнарына биргән илаһи нурлары. Халкыбызның гүзәл затларының буй-сыннары, төс-кыяфәтләре һаман камилләшә гүзәлләнә барып, милләтебезнең асыл ташларына, энҗе бөртекләренә әверелгән. Мин алар белән чиксез горурланам. Аларның һаман да, әби-бабаларыбыз кебек, мөэмин-мөселман булып, әдәп-әхлаклы, тәртипле-тәрбияле, оят-намуслы, шәфкатьле-игелекле, итагатьле-кешелекле, затлы-зәвыклы, исламлы-иманлы һәм башка күп төрле күркәм сыйфатларга ия булган милләт апалары булып калуларын телим.

Нихаять, бер-беребезнең кочакларыннан чыгып, Фәнияләр йортына таба атладык. Кысышкан кулларыбыз бер-берләрен җибәрергә теләми иде. Әйтерсең, алар бу күрешүнең соңгы күрешү икәнен сизенгән, башка беркайчан да күрешә алмауларын тоемлаган булган.

– Рәис, мине исеңнән чыгарма, мине онытма. Мин сине

һәрвакыт өзлеп котәрмен! – диде Фәния, миңа сагышлы караш ташлап.

Без аерылыштык. Без мәңгегә аерылыштык.

Мин, әле йөгерә төшеп, әле әкрен атлап, өйгә кайтып барам. Ләкин аякларым җирдән атламыйлар кебек. Күңелем читлегеннән ычкынган кошчык сыман каядыр ашкына. Мәхәббәт өермәсенә уралып күкләргә ашам. Җаным-ны тибрәткән шатлыгым моң булып тышка агыла. Шаркылдап көләсем, үземнең чиксез бәхетемне кемгәдер сөйлисем килә. «Фәниям, мин сине югалтмам, мин сине яратам!» – дип пышылдыйм.

Ләкин шунда ук, күңелемне шомлы төшенкелек сарып, моңсу өметсезлек биләп ала. Ниндидер күңелсез уйлар йөгереп үтә. Эчемнән кайнар сулыш бөркелә. Тәнемә кинәт каз тәннәре чыгып, чемер-чемер килә башлый. Әйтерсең, тәнемә мең төрле энәләр белән кадыйлар. Хәвеф-хәтәр янагандай, эсселе-суыклы булып китә. Кисәк кенә җаным-тәнем, бөтен эчке дөньям калтыранырга тотына. Бугазыма төер утыра. Мондый сәер халәтне минем беренче мәртәбә кичерүем иде. Хәерлегә булсын инде...

Күкрәп үскән иген уңышын вакытында һәм югалтусыз жыеп алырга дип ярдәмгә килгән бер төркем эшчеләрне автобус Лаеш районына, Октябрьнең 25 еллыгы исемендәге совхозның бер бүлекчәсе булып саналган, таркалуга-бетүгә йөз тоткан кечерәк кенә урыс авылына алып килде. Тешләре яртылаш төшеп беткән авызга охшап калган бу авылның исән торган йортлары да тузган, искергән. Аларның күбесе менә авам, менә түнәм хәленә житкән. Бүлекчәнең бригадиры – тәбәнәк кенә буйлы, кызыл чырайлы, хәйран гына зур корсаклы, илле яшьләр чамасы Федор Степанович безнең барыбызны да фатирларга урнаштырып чыкты. Мөбарәк исемле егет белән мин Анастасия исемле әбигә

эләктек. Ул алтмыш тирәләрендәге, чандыр гәүдәле, җыйнак кына урыс карчыгы иде. Өстендә һәрчак бер үк киемнәр: киң итәкле кара күлмәк, аның өстеннән кофта сыман нәрсә кия. Башындагы яулыгы ияк астыннан ни белән-дер эләктереп куелган булыр. Әбинең ак мунчадан бераз гына зуррак булган бүрәнә йорты үзе кебек үк картайган; чоланы, йортыннан аерыла барып, ишегалды ягына янтая төшкән. Шушы йортта гомер кичергән Анастасия әби бер үзе яшәп ята иде. Өй эчендә әбинең, агач кроватеннан кала, берничә иске урындыгы, почмакта торган, лаклары кыршылып, кара төскә керә башлаган савыт-саба шкафы бар. Шундый үк өстәлдән кала башка җиһаз юк дияргә була. Ә менә шкаф дигәне, заман тузаннары кунып каралган, керләнгән булса да, үзенең затлылыгын югалтмаган. Аның алгы өлеше, ике якка ачылышлы ишекләре, ян-яклары, чат терәкләре агачны уеп, зәвык белән, искиткеч матур бизәкләргә бизәп эшләнгән. Баш очындагы таҗ сыман кал-фагы аңа ямь биреп, дәрәҗәсен күрсәтеп тора. Шкафны эшләгән кеше, һичшиксез, үз һөнәренең остасы булган. Ишегалды ягына караган уң як почмакта, тартма сыман итеп ясалган ояда, Иисус-Христос сурәте төшерелгән тәре һәм шәмдәл куелган. Ул ак пәрдә белән уратып алынган. Монда әби көн дә чукына-чукына гыйбадәт кыла. Без чоландагы сөкедә йокларга тиеш булдык. Әби урын-җиргә бай булмаса да, каз мамыгыннан ясалган мендәрләре йомшак иде. Сәке өстенә берничә иске-москы ташлагач, менә дигән ятак булды. Ул арада чәй дә өлгертте. Үзебез белән алып килгән ризыклар һәм тәм-том белән өчәүләп чәй эчтек.

– Әгәр хуш исле печән өстендә йокларга теләсәгез, чалгы – чормада, үлән бакча башында, – диде әби.

Без шулай эшләдек тә. Күптән тотылмаган чалгыны, балта түтәсе өстенә куеп таптап юкарткач, беләү белән ыш-

кып та җибәргәч, эшкә яраклы хәлгә керде. Мөбарәк белән рәхәтләнеп печән чаптык. Ул кичкә кадәр кибеп тә өлгерде. Кичен бригадир килеп, иртәгә салам эскертләргә барачагыбызны әйтеп китте. Анастасия әбигә ниндидер серле сәнәкләрне табып, безгә бирүне йөкләде.

Иртә белән «Белорусь» тракторына тагылган өрҗәле арбага утырып, кырга чыгып киттек. Әле күптән түгел генә диңгез кебек дулкынланып торган иген кырларында салам чүмәләләре генә утырып калган. Бригадир кемнең нәрсә эшләргә тиешлеген әйткәч, без эшкә керештек. Мөбарәк белән миңа эскерт янына китерелгән саламнарны эскерт өстенә биреп тору йөкләнде. Без Анастасия әби табып кайткан, җәпләре болан мөгезе кебек тырпаеп торган, озын саплы агач сәнәкләр белән, килгән салам өемен «эһ» дигәндә эскерт өстендә торучы урыс агаеның алдына китереп тә салабыз. Агай салам эченә күмелеп калгандай була. Аннан көч-хәл белән арынырга өлгерми, без икенче өем белән күмеп китәбез.

– Бу татар малайларының мондый сәнәкләр белән эшләргә көчләре җитмәс дип уйлады инде болар. Үзләренчә безне кызык итмәкче. Юк, брат, без дә төшеп калганнардан түгел, – ди Мөбарәк, учына төкереп.

– Егетләр, зинһар, ашыкмагыз инде. Күрәсез бит, өлгерә алмыйм! – ди, эскерт өстендә торучы Михаил дәдәй.

– Җәһәтрәк эшлә! Килгән саламны эскерт кырыенда яткырып булмый ич инде, – ди Мөбарәк, миңа күзен кысып.

Сәгать уникеләр тирәсендә әбәт китерделәр. Аның артыннан ук бастырып, бригадир да килеп житте. Ул бүлтәеп торган, бүселеп чыккан, ә урыны-урыпы белән иләмсез җәелеп үк киткән эскертне әйләнеп чыкты да, бик каты сүгенеп:

– Бу нәрсә, анаңны шулай итим, эскертме, әллә Катяның арт санымы? – дип, эскерт башында торучы агайга кычкырды. Агайның кус борчак аша белән тулы кашыгы ярты юлда туктап калды.

– Мин сиңнән сорыйм! – диде бригадир яхшы ук кыза китеп. – Әллә күзең чыкканмы, эскертне ничек салырга кирәген онытттыңмы? Бу бит адәм көлкесе, басу карачкысы булган!

– Егетләр саламны чүмәлөсе белән күтәреп тондыралар. Рәтләп салырга өлгерә алмый калам. Алар тизлегендә эшләргә күнекмәгән мин. Коляны ярдәмгә бир, – дип аклануы агай.

– Ие, егетләр, безнекеләр кебек, бер сәнәк салам ыргыткан саен перекур ясамыйлар шул! – диде бригадир бераз суына төшеп. – Икенче эскерткә тотыныгыз. Аныспн әнә тегендәрәк, юл буенарак салырсыз. Ә монысын, эштән соң калып, үзең адәм рәтенә кертерсең. Аңладыңмы?

– Аңладым, – дип мыгырданды агай.

Көннәрдән бер көнне бригадир белән совхоз директоры Исламов үзе һәм алар белән тагын бер кеше килде. Соңыннан ул кешенең районнан килгән вәкил икәнен белдек. Эшнең кояш кыздыргандай челлә чагы иде. Безнең дә, тегә агач сәнәкләрне батырып, салам өемнәрен берсе артыннан берсен эскерт башына чөйгән чак булды. Хәзер анда ике кеше тора. Коля дигәннәре эшнең җаен белеп эшләүче булып чыкты. Начальство безнең эш барышын читкә басып, күзәтеп, карап торды.

– Яхшы эшлисез, ипташлар, молодцы. Ә бу егетләр аерым мактауга лаеклар, – диде директор, безне күрсәтеп. Аннан бригадирдан:

– Ашау-эчү яклары җайланганмы? Дәгъвалар юкмы? –

дип сорады. – Бу егетләргә ризык-ашамлыкларны җәлләмә. Итне өстәмә бир. Эшләрс авыр, – дип китеп барды.

Ашау-эчү яклары, чыннан да, тел тигерерлек түгел иде. Эштән кайтышыбызга, әби бер чүкн итле ботка пешереп куйган була. Бер кат юынып алгач, теге чүенны өстәл каршыбызга куеп, төбенә төшеп җитә язабыз. Бербөтен түгәрәк ипинең дә яртысы беткән була. Аннан, корсакларыбызны көчкә күтәреп, ишегалдын тутырып үскән ромашкалы бәбкә үләнле яшел хәтфәгә чыгып тәгәрибез. Бетен сойләшкән сүзебез кызлар турында. Мөбарәк үзенең Гөлсинәсен теленнән төшермәсә, мин Фәниямне сөйләп туя алмыйм. Сөйләшә-сөйләшә, шул ятудан йоклап та китәбез.

Басу-кырлар буйлап салам эскертләре сала-сала, ике атна вакыт узып та китте. Авылда да безгә караш үзгәрә төште. Төрттереп әйтүчеләр дә, кырын караучылар да табылды. Имеш, без мужикларның дәрәҗәсен төшерәбез икән. Эскерт салган өчен түләү бәяләре дә үзгәрүгә сәбәпче булуыбыз бар, диләр. Югыйсә без, беләкләребездә көч-куәт ташып торган ике егет, яхшы итеп эшләргә генә тырыштык. Тора-бара агач сәнәкләр дә сәер рәвештә юкка чыкты.

– Кончелек белән берәр начарлык эшли күрмәсеннәр тагы. Сак булыгыз, – дип, кисәтте безне Анастасия әби.

Шимбә көнне төштән соң күк йөзен кара болытлар каплап алды. Бераз җилләп алганнан соң, табигать тынып калды. Әкрен генә вак яңгыр сибәләргә кереште.

– Бу берәр тәүлеккә бара инде, – диделәр мужиклар. Эшне иртәрәк бетереп, без кайтыр юлга чыктык. Озак барырга да өлгермәдек, каршыбызга йөк машинасына утырган бригадир килеп туктады.

– Яңгыр яуганда эшләмәвәгез яхшы булган. Юсш салам эскерттә череп кенә ята ул. Ә мин Казанга кайбер кирәк-

яракларга барам. Кайтып җитмәсәм, иртәгә үз эшегезне дәвам итәрсез.

– Әгәр шушылай яңгыр явып торса дамы?

– Юк. Яңгыр явып торса, ял итәрсез, – диде бригадир.

Шул арада башыма да, телемә дә берьюлы бер фикер килде:

– Федор Степанович, мица да сезнең белән өйгә кайтып килергә мөмкинме? Иртәгә иртүк килеп җитәрмен! – дидем.

– Иртәгә килеп җитү шарты белән мөмкин. Тик кузовта утырып барсаң гына инде.

– Анда брезент бар. Шуның белән капланып утыр, – диде шофер.

Без кузгалып киттек. Мин, Фәния белән очрашу турында уйлап, татлы хыялларга чумдым. Һай, ничек өзелеп сагындым мин аны, ничек күрәсем килде! Ләкин минем татлы уйларым буш хыяллар гына булып чыкты. Күршеләрс Фәниянең әнисе белән каядыр китүләрен әйтте. Шулай да кайтуым яхшы булды әле. Әнием бик шатланды. Башымнан сыйпый-сыйпый, аркамнан сөя-сөя яратты. Юкка гына «Ана күңеле – балада, бала күңеле – далада» димәгәннәрдер шул.

Вак яңгыр икенче көнне дә төтәде дә төтәде. Әнием: «Күрмәгән дә шикелле булдым. Әллә иртәгә китәрсең», – дисә дә, барырга булдым. «Килеп җитәрмен», дигәч, таш яуса да барырга кирәк. Егет сүзе бер була. «Бирәм дигән колына, чыгарып куяр юлына» кебек булды. Лаеш юлына килеп күп тә тормадым, бер узгынчы машинага кул күтәргән идем, бәхетемә күрә, ул шул совхозга баручы машина булып чыкты. Анастасия әбигә килеп җиткәнче минем өйдә алышып кигән киемнәрем лачма су булган иде. Ә Мөбарәк, тынгы белмәс Мөбарәк тик тормаган, яңгыр дип ятып та

йокламаган. Ул Анастасия әбинең алга таба түнтәя башлаган чоланын сүтеп ташлап, инде ян-як баганаларын да зур ташлар белән яхшылап түшәгән нигезгә утыртып, үзара тоташтырып, беркетеп куярга да өлгергән.

Минем килүемә икесе дә шат булдылар. Анастасия әби үз улы кебек итеп, кочагына алып яратты.

– Раббым сезне рәхмәтеннән ташламасын, бәхет-тәүфыйкларыгызны арттырып бирсен, сәламәтлегегездән аермасын, – диде ул, ихластан чукына-чукына.

Әнием биреп жибәргән күчтәнәчләр белән бер кат чәй эчеп алгач, киемнәремне алыштырып, мин дә эшкә керештем.

– Һич югында тагы ун-уникс такта юнәтеп булмас микән? Болары бигрәк иске, кадак тотарлыклары калмаган, – диде Мөбарәк, әбигә карап.

– Белмим шул. Федор Степанович янына барып карасам гына инде.

Без, иске тактадардан кадакларны суырып, аларны турайтып маташкан арада, Анастасия әби дә шатланып кайтып керде:

– Булды тагы, Ходайның рәхмәте белән. Менә, пилорамнан алырга рөхсәт кәгазе бирде бригадир, – диде. – Барып кына аласы бар. Ә сезгә чоланны эшләгән бу көннәрне эш көне итеп санармын, дип әйтте.

– Ул эш көннәренең безгә һич кенә дә кирәкләре юк, эш хакын безгә завод түли. Әгәр дә эш көннәре сиңа кирәк икән, без аларны, рәхәтләнеп, сиңа бирәбез, – дидек без.

Алгы ягын һәм ишекне – яңа тактадардан, калган өлешчен искеләрне кисә-ялгый әмәлли торгач, яңгырның туктаусыз тәтәвенә карамастан, көч-хәл белән оештырып та куйдык чоланны. Анастасия әби каяндыр табып кайткан ярты төргәк рубероид белән түбәсен дә ябып алдык. Яңа, иске тактадардан җыелса да, ала-кола булса да, хәйран гына килеп чыкты тагын үзе. Әбинең шатлыгы эченә сыярлык түгел иде. Ул, чоланның әле бер ягына, әле икенче ягына чыгып, аны этеп-төртеп карады. Янәсе, авып китәрлек түгелме. Аннан соң, чолан каршына басып, иелә-турая:

– Ходаем, игелеген күргә насыйп ит, ут-күзләрдән үзең сакла, – дия-дия, озак кыпа чукынып торды. Безгә дә иксез-чиксез рәхмәтләр укыды, саулык-сәламәтлек, гаилә бәхете теләде.

Тәүлектән артык яуган яңгырдан соң табигать тынып калды. Әйтерсең лә, иннәрендә күтәреп йөрткән авыр йөгеннән бушанып, ялга туктады. Ләкин күк йөзен әле һаман да тоташтан аксыл-кара болытлар каплап алган. Алар инде көнчыгышка якынаеп, юкарып калганнар. Кайчак болыт ертыгыннан нурлы зәңгәр төсләр дә күренгәләп куя. Бу инде көннең аязып китүенә өмет бар дигән сүз. Тик әлегә һава бәркү. Ул дым белән сугарылган. Шушы дымлы бәркүлек кешеләрне бастырып куйды сыман. Урамда бер генә кеше әсәре юк. Әйтерсең, авыл тирән йокыга талган. Анастасия әбинең итле борчак боткасын ашап, без дә чоландагы урыныбызга түндек. Дәресен генә әйткәндә, моның сәбәбе шул: кичә яңгырда чыланган киемнәребез әле кибеп тә җитмәгән иде.

– Бүген рәхәтләнеп ял итегез. Кыр-басулар бераз кибә төшми, саламнар җилләми торып, эшкә керешә алмассыз, – диде Анастасия әби.

Эшкә барганда, басуда-кырда чакта алай ук түгел, ә менә мондый көннәрдә, өйдә эшсез яткан вакытларда уйландыра да уйландыра. Казанга кайтып та, Фәнияне күрми китүем күңелне әрнетеп-сыкратып тора. Сагындым, шулкадәр сагындым мин аны. Әгәр дә бер исәр булсам, акылым күңел-

не йөгәнләп тора белмәсә, ике дә уйламый Казанга чыгып чабар кебек идем мин. Мондый халәт еш кабатланды миндә

Кипкән печәннең исе Фәнияне, аның чәчләреннән, тәненнән, өс киемнәреннән килгән исне хәтерләтә. Яңгырдан соң дымланып торган һавадан да мин шул ук татлы исне тоям. Кайдадыр еракта янган утлар мина Фәнияләр өснең тәрәзәсе булып күренә Ах, сагындым, ничек сагындым мин сине, Фәния!

Мин сизәм, Мөбарәк тә авыр сулап куйгалый. Беләм, аның да йөрәгендә ниндидер бер сагыш, сагыну, юксыну яши. Тик ул әле миңа ачылмый, ачылырга ашыкмый, эчтән генә сыкрана. Мин Казанга кайтып килгәч, бик ук тырыдан бәрелмичә генә, сүз уңаеннан гына сорагандай итте:

- Фәнияңне күрдеңме соң? - диде. Мин ул чакта бик нык гаҗәпләндем. Ничек инде?! Минем бит Мөбарәккә Фәния турында әлегә бер сүз дә әйткәнем булмады кебек?! Мөгаен, гаҗәпләнүем йөземә үк чыккан булгандыр, Мөбарәк елмаеп куйды, аннан соң инемә катып эйтте:

- Яшермә, яшермә, дускай, ике көн инде төнлә тошләнеп-саташып чыктың, һаман ниндидер Фәнияне чакырдың, - диде.

Ah, Мөбарәк! Башта ук миңа әйтмәгән бит, көлешеп-үртәп сораштырмаган. Мин Казанга кайтып килгәч кенә, менә, түзмәгән, «Фәнияне күрдеңме соң?» - ди. Аның да Казанда сөйгән кызы барын мин әнә шул чакта белдем.

Инде дустым Мөбарәк турында берничә сүз әйтеп үтим. Ул Питрәч районының Күн авылы егете. Кечкенәдән ятим калып, апасы белән авылдан-авылга хәер эстәп йөреп жан асрыйлар. Ач-ялангач йөргән бу икс сабыйны күреп, мәрхәмәтле кешеләр аларны балалар йортына урнаштыралар. Әлбәттә, биредә тамаклары тук, өсләре бөтен була. Азмы-күпме тәрбия һәм жиде класс белем алып, кире авылларына кайталар. Үзләре юк чакта ярым жимерек хәлгә килгән йорт-жирне, каралты-кураларны яшәү өчен яраклы хәлгә китерергә кирәк була.

Ана назыннан мәхрүм калган, ата тәрбиясе күрмәгән бу икс нәүмизгә дә, сугыш чоры балалары күргән барлык авырлыкларны үз жилкәләрендә кичереп, тормышның ачысын-төчесен мулдан татырга туры килә

Мөбарәк хәрби хезмәткә алынганчы үз авылларында, бер көн дә калмый, колхоз эшендә була. Күбрәк ат белән бәйле эшләрдә. Соңрак балта осталары белән каралты-кура, йортлар салып йөри. Бер очтан үзләренә дә зур булмаган йорт өмәлли. Әбинең чоланына керешүе дә, бу һөнәр иясенең капына сеңгән төзү-төзәтү гадәте тынгылык бирмәүнең бер игелекле чагылышы, күрәсең. Мин, әлбәттә, «оста барда кулыңны тый, галим барда теленне тый» дигәндәй, ярдәмче буларак кына өлеш керттем.

Уртача буйлы, чандыр гәүдәле, корычтай мускуллы, төскыяфәте белән дә үзенә каратып тотар егет Балтыйк диңгезе корабларының берсендә хезмәт итә. Хезмәттән соң Караваи поселогында яшәп яткан апасы һәм жизнәсе янына кайта.

Заманында уналты саны белән йөртелгән заводка слесарь булып эшкә урнаша. Без аның белән бер төркемдә эшләдек. Ул эшнең жаен, тәмен белеп эшли. Кулына тоткан һәр эшне ут уйнаткан гайрәтле Мөбарәк, салам чүмәлоләре белән дә уйнагандай итеп кенә эш итте.

Мөбарәк эштән-эшкә күчеп, урын алыштырып йөрмәде. Бер урында эшләвен белде. Озакламый, жизнәсе, апасы ярдәме белән, үзләренең бакча башына менә дигән йорт та салып куйды. Күршеләрендә квартирда торган, үзе кебек ятимә кыз Гөлсинә белән кушылып, тату гомер кичерделәр. Үзләре шикелле тыйнак, итагатьле, күркәм холыклы икс

кыз үстерделәр. Шулай уңай гына, гөрләшеп кенә яшәгән көннәрнең берендә ашказаны яман чире белән газап чиккән Мөбарәк, якты дөньядан вакытсыз китеп тә барды. Авыр туфрагы җиңел, урыны җәннәттә булсын.

Завод җитәкчелеге, комсомол оешмасы мине онытмаган булып чыкты. Кичке мәктәптә укучы буларак, миңа, август ахырларында алмаш килде. Барысы белән дә хушлашып, Казанга кайтып киттем. Бригадир Федор Степанович Мактау грамотасын һичшиксез җибәрәчәген әйтеп калды.

Менә, мин янәдән җитен комбинаты тирәсен әрле-бирле килеп әйләнәм. Фәниянең эшен бетереп чыгарына әле ике сәгатькә якын вакыт бар. Ничек тизрәк уздырырга бу вакытны? Сагындым, бик тә сагындым шул үзен. Ашкынулы хисләрдән ярсыган җаным үзенә урын таба алмый. Комбинатның урам якка карап торган тәрәзәләрен күрсәм дә җаныма сихәтә тияр, бераз тынычланырмын кебек. Хәзер миңа бу җитен комбинаты шулкадәр якын, шулкадәр кадерле, әйтерсең, ул минем туган йортым. Хәтта аның тирә-якка аңкыган төче исе дә үз, тыннарны куырмый кебек. Чөнки анда минем шашып яраткан, сөйгән кешем эшли.

Һай, бу вакыт дигәннәре. Сиңа кирәк чакта ташбака сыман кыймылдый. Күңелемдә ут, йөрәгем читлегеннән чыгарга талпынган кошчыктай каядыр ашкына.

Башымдагы уй-хисләр өермәсе тагы да котырарак төште. Чигә тамырларымның леп-леп тибүләреп аермачык тоям. Күңелем ярсу ат сыман каядыр ыргыла. Сулышымның кайнарлыгы иреннәремне пешереп-пешереп алган шикелле. Бербер артлы тарткан тәмәкем дә нервларымның кисренкелеген йомшартмый. Кисәк-кисәк күңелсемнән шом йөгереп үткәндәй була. Гүя мине ниндидер хәвеф сагалый, күңелсезлек көтә. Мин, шулардан качарга теләп, адымнарымны кызулатам. Ләкин кинәт туктап калам. Шунда башыма

Фәниянең: «Кайбер егетләр кызлары янына комбинатка кереп тә йөриләр», дигәне кәлт итеп исемә төште. Ә нәрсә? Мин кемнән ким?! Өзелеп яратуымны исбатлаучы уңай очрак түгелме соң бу? Менә булыр сюрприз! Шаккатып карап торсын әле Фәниям. Мин дә бит төшеп калганнардан түгел! «Уйланган эш – эшләнгән эш» диләрме әле. Аллага тапшырып, тәвәккәлләдем.

Мәшһүр Памир тауларын кичеп, диңгез тигезлегеннән биш мең ике йөз метр биеклектә торган заставада хезмәт иткән чик сакчысына җитен комбинатының өч метр биеклектәге кирпеч коймасы, аның өсте буенча сузылган бер метр чамасы чәнечкеле тимер чыбыклар белән үрелгән корылмалары нинди каршылык күрсәтә алсын ди?! Мин аларны «Ә» дигәнче сикереп үттем. Хәтта койма кырые буйлап ярсып өреп йөргән этләр дә, каланчада утырган сакчылар да сизми калды.

Менә мин комбинат ишегалдында, кая барырга белми басып торам. Кайсы цехта эшли икән соң минем Фәниям? Йшек алдында, сирәк кенә булса да, кешеләр үткәләп киткәли. Аларның һәркайсының үз шөгыле. Миңа таба әйләнеп тә карамыйлар. Үземнән ерак түгел генә үтеп баручы ханымны куып җиттем:

– Гафу итегез. Сез Фәния исемле кызны белмисезме? Аның кайсы цехта эшләгәнен әйтә алмассыз микән? – дим.

– Комбинатта Фәния исемле кызларның күп булуына шигем юк. Аларның эрләү цехында да, сугу, туку цехларында да эшләүләре мөмкин.

– Әйе, әйе, сез хаклы. Тагын бер тапкыр гафу итегез.

Мин әледән-әле кешеләр кереп-чыгып йөргән икенче каттагы ишеккә таба киттем. Эчкә кердем. Бу – комбинатның Гладилов урамы буенча сузылган бер цехы иде. Гаскәр кебек, берсе артыннан берсе тезелеп киткән станокларда зур-

зур кәтүкләр әйләнә. Алардан, үрмәкүч пәрәвезе кебек, җепләр сузылган. Цехның эче бөркү. Идәннән түшәмгә кадәр соры тузан пәрдәсе эленгән. Лампочкаларның көчле балкышы шушы тузан пәрдәсе белән кушылып, соры төс хасил иткән. Хатын-кызлар, әле тегесенә барып, әле моныcына килеп, станокларның эшен күзәтәләр.

Мин дә бер почмакка барып, тәмәке кабызып җибәрдем. Кая барырга белми аптырап торганда яныма пөхтә генә киенгән бер ханым килде.

– Сез нишләп әле монда тәмәке тартып торасыз? Әллә цехта тәмәке тартуның катгый рәвештә тыелганын белмисезме?

– Юк, белми идем. Хәзер сүндерәм.

– Сез кайсы цехта эшлисез? Сез, гомумән, безнең эшчеләргә охшамагансыз. Сез каян?

– Урамнан.

– Әәә?! Ничек бирегә кердегез?

– Койма аша сикереп кердем.

– Шаяртмагыз!

– Һич кенә дә..

– Алай булгач, кадерле иптәш, сезгә минем белән барырга туры килер.

– Алай булгач, мин киттем инде.

– Юк инде, беркая да китмисез!

Ханым үзенә ярдәмгә берничә ир-егетне чакырып алды. Тегеләр, минем як-ягыма басып, үзләре белән барырга куштылар. Без киттек. Ишегалдына чыккач, эшнең мөшкел якка барганын сизеп, теге ир-егетләрне бер селтәнүдә тәгәрәтеп яткырдым. (Чик буенда безне күп төрле көрәш алымнарына өйрәткәннәр иде.) Тегеләр аякларына баскан арада, мин проходной ишеге төбендә идем инде. Ләкин проходной вертушкасына кереп тыгылган юан хатын тиз

генә аның аша үтәргә мәмкинлек бирмәде. Мин өстән чыгарга маташкан арада, кемнәрдер килеп, өстемә ябырылдылар. Мине егып, өстемә үк менеп утырдылар.

Яшьлек җүләрлеге белән эшләнгән бу аяныч хәлләрнең ачы җимешләрен гомерем буе татыдым мин. Ләкин мин моны һич кенә дә үкенеп әйтмим. Һәр эшнең уңай һәм тискәре яклары да була.

Озак көттерми, милиция экипажы да килеп җитте.

– Торсын, – диде таныш аваз. Күтәрелеп карасам, каршымда милиция старшинасы Ибрай абый басып тора. Фронтта разведчик булып хезмәт иткән, чандыр гәүдәле, кырыс йөзле Ибрай абыйны Киров районында белмәгән кеше аз булгандыр. Бормалы-сырмалы булып, ераклarга сузылып киткән он чиратларында тәртип саклаучыларның берсе һәм ин билгелесе – милиция старшинасы Ибрай абый иде. Бер чакны, таеп чыккан аягын үз урынына утырттырырга дип, аның әнием янына да килгәне булды. Ул заманнарда аяк-кулары сынган-тайганнар якын тирәдән генә түгел, ерак авыллардан да әнием янына килә иде.

Старшина Ибрай абый белән без яхшы ук танышлар идек. Карашларыбыз белән генә булса да, исәнләшеп тә алдык. Мине тоткарлаучыларның берсе, милиция каршында әтәчләнеп, күкрәгемә төрткәләде.

– Яшерен-батырын түгел, энекәш. Сине алып китүе миңа бер дә җиңел түгел. Алып китмәсәм, таякның авыр башы миңа төшәчәк. Юри качырды диячәкләр. Менә шундый ералаш, – диде Ибрай абый, төшенке тавыш белән. Инде мәсьәлә хәл ителеп, кулларымны артка каерып бәйләргә теләгән милиционерга: «Ул болай да беркая китми», – дип, юлына аркылы төште. Мин милиция машинасына таба атладым. Берничә кешедән эшнең ничек булганын әйтеп

язылган аңлатма көгазьләре алгач, машина данлыклы Бөкере күпер янәшәсендәге милиция бүлегенә юл тотты.

Төне буе тар камерада исерекләр һәм үзем шикелле тәртип бозучылар белән йокысызлыктан газапланга торгач, безне берәм-берәм бүлек начальнигы бүлмәсенә әңгәмәгә чакыра башладылар.

– Дон Жуан Сафин, – диде бүлектә дежур торучы өлкән лейтенант.

Ишектән керә-керүемә бүлек башлыгы полковник әйтте:

– Син старшина Гомәровны белөссеңме?

– Аны кем генә белми икән?

– Әйе, аны беләләр. Ул да сине белә

– Югыйсә, ул сырлаган рапорт буенча сиңа медаль дә бирергә мөмкин булыр иде, – дип елмайды. – Ә шулай да бу кадәр акылсызлыкны эшләргә нәрсә этәрде сине?

– Мохәббәт.

– Аңлыйм. Мәхәббәт көчле, изге нәрсә. Ләкин бу мәгънәсезлекнең ахыры синең өчен күңелсез булып бетүе дә ихтимал. Хәрби заказлар үтәгән комбинатка койма аша керү уен эш түгел. Тегенди-мондый гына эш булса, үзем генә хәл итәр идем дә бит. Юк шул. Бу суд органнары гына хәл итә торган бик четерекле мәсьәлә

Менә мин судья карлыында басып торам. Утыз биш яшьләрдәге судья ханым милиция бүлеге әзерләп җибәргән документны укый.

– А-а-лай икән. Дөньяда искитмәле гаҗәп хәлләр дә булып куйгалый. Тәкатен жуйган егет яраткан кызын күрер өчен чәнечкеле тимер чыбык белән уралган коймаларны сикереп үтә, диген. Этләр дә сизми, каравылчылар да күрми кала. Менә ничек саклыйлар житен комбинатын! Бер караганда, менә кемнәрне жаваплылыкка тарту кирәк беренче чиратта.

Судья беразга тынып калды. Ул ниндидер хатирәләр диңгезендә йөзә кебек иде.

– Димәк, ул кызны яратасың инде?

– Яратам.

– Бу гамәлең өчен үкенмисеңме?

– Юк!

– Безнең заманда рыцарьлар юк, дигән булалар. Менә ул – безнең заман рыцары, каршыгызда басып тора, – диде судья, як-ягында утырган хатын-кызларга. – Сөсклесе белән күрешү теләген бернинди киртәләр дә тоткарлый алмаган. Инде нишлик соң бу мәхәббәт дигән изге хис корбаны белән? Җәза бирсәк, мәхәббәтне рәнжеткән кебек була. Күрмәмешкә салышып калып та булмый. Законда мондый гамәл өчен жиде елга кадәр иреннән мәхрүм итү каралган. Ярый, киңәшеп карыйк әле, киңәшле эш таркалмас, диләр.

Хатын-кызлар, торып, киңәшү бүлмәсенә кереп киттеләр. Озак та тормый, көлешә-көлешә чыгып та килделәр.

– Менә нәрсә, егет. Бу ханымнар, бөтен жаваплылыкны үз өсләренә алып, сине якладылар, ярсый-ярсый акларга тырыштылар. Суд утырышы эгъзаларының фикерләрен искә алып, син жиде тәүлеккә административ жаваплылыкка тартыласың.

Соңыннан өстәп куйды:

– Ә инде үз исемемнән шуны әйтәм. Мәхәббәтеңә һәрчак тугры кал. Сөйгәнеңне ташлама, аны ярат.

Безне Петрушкин төрмәсенә алып килделәр. Төрмә ишекләренең әле берсен ачып, берсен биклән, өч-дүрт ишек аша үткәч, кесәдәге әйберләребезне, бил каешларыбызны салдырып алганнан соң, бер камерага кертеп жибәрделәр. Ул хәйран зур бүлмә иде. Ян-як стеналарындагы ике катлы сәндрәләрнең күбесендә тоткыннар сузылып яткан. Арабыз-

дан берәү түрдәге буп сәндрәгә таба ашыкты. Без кергән тавышка янәшә сәндрәдә ятучы кеше, башын күтәреп, тирәякка күз ташлады. Ул Петров паркы әйләнә-тирәсен үз кубызына биеткән, егетләр арасында үзенең көче-куәте белән дан тоткан ныкбәдәнле, атлетлардай буй-сынлы Рафыйк исемле егет иде. Мине танып, күреп алып:

– Рәис?! Мин сине монда чакырмаган идем ич! – дип, көлеп җибәрде. – Кил яныма, менә бу урынга.

Теге, бсрснчс булып алдагы сәндрәгә ыргылган кешегә әйтте:

– Бу урында минем дустым ятар, – дип, мица күрсәтте.

– Мин алган идем ич инде аны!

Рафыйк, тегенең муен тамырыннан элəктереп, этеп җибәрде, ул, мескен, идән буенча түшендә шуып барып, башы белән ишек янындагы парашага ук килеп төртелде.

– Шунда синең урының, – диде Рафыйк.

Мин сәндрәне караштырган арада ул кәяндыр бер «яртыжны тартып та чыгарды. Колбаса, ипи кисеп куйды. Без берәр кырлы стаканны бушатып та куйдык. Тагы берәр стаканны өстәгәч, телләр чишелеп китте, тамырларда аракы давылы котыра башлады. Мин үземнең кичәге мажараларымны сөйлидем. Ә ул исә, үзе әйтмешли, бер «хәшәрәт»не акылга утыртырга теләгән булган икән. Теге хәшәрәт Пороховой заводыннан икенче сменадан кайтып баручы бер хатынны алтынчы мунча янындагы агачлар арасына алып кереп таларга тотынган. Ләкин, Рафыйк йодрыкларыннан зыян күрүче буларак, судан коры чыккан, теге хатын да китеп югалган, егетнең үзен элəктереп алганнар.

Рафыйк ул кешенең төс-кыяфәтен тасвирлагач, мин аның кем икәнен шундук абайладым. Чөнки Жиләклс, Пороховой бистәсендә яшәүчеләр бер-берләрен яхшы ук белә иде.

– Борчылма, батыр ярасыз, яшьлек хатасыз булмый,

диләр ич. Безгә дә моның нәрсә икәнлеген белеп, төмен татып карарга кирәк булгандыр, күрәсең. Тик һәрнәрсәдән нәтиҗә ясап, гыйбрәт ала белергә кирәк. Ә теге егет кисәген мин үзем икенче мәртәбә хатын-кызларга кулын күтәрмәслек итеп, акылга утыртам әлс, – диде Рафыйк.

Милиция бүлегендә йокысыз үткәргән төн үзенекен итә башлады. Мин сәндрәмә таба үрмәләдем.

Иртәгесен иртүк безне «сатып алучылар» килеп, кайсыбызны кая алып киттеләр. Мине ниндидер төзелешкә алмакчыдар иде, Рафыйк үзе белән җибәрүләрен сорады. Калганнарыбызны җыеп, милиция сержанты «Минем арттан», диде. Иртәнге унберләргә кадәр эленке-салынкы бераз кыймылдагач, кичке биштә шушы урында очрашырга сүз куешып, өйләребезгә таралыштык.

Аякларым өйгә таба йөгерсәләр дә, әниемнең күзләренә нинди йөз белән күрсәтермен дигән уй җанымны тырный, күңелемә тынычлык бирми. Нинди оят бит, валлаһи – абыстай малае, тәртип бозып, төрмәдә утырсын инде! Хурлыгы ни тора!

– Әнием, мин бер зур хата эшләдем. Гафу итүеңне сорарга да оят, – дидем мин, яшермичә.

– Беләм, беләм, улым. Миңа бөтенесен дә бәйнә-бәйнә җиткерделәр инде. Ике тәүлек Аллаһы Тәгаләдән сине рәхмәтеннән ташламавын, ярдәм итүен сорадым. Сиңа саулык-сәламәтлек, үземә сабырлык бирүен теләдем. Инде сине болай күрүемә бик тә, бик тә риза, шатлыгым эчемә сыймый. Тик мондый хата-ялгышны Аллаһы Тәгалә киләчәктә күрсәтмәсен. Ят, ял ит. Ашыйсың килсә, ризык плитә өстендә. Мин сөлек салып кайтырга киттем.

Ә шулай да, әнием каты бәрелмичә жайлап кына әйтсә дә, аның шушы киң күңеллелеге жанымны тетрәтте. «Нишләп без иң якын кешеләребез хакында аз уйлыйбыз,

аларның кадерен вакытында белмибез? Әнә шундый уйлар урап алды, гарьлегем бугазыма төен булып утырды. Әгәр «Әйдә, чык, сине атарга булдык» дисәләр, бер дә икеләнми ризалашкан булыр идем кебек тоелды.

Кичен безне Елан тау башындагы монастырьга алып килделәр. Анда утыручы ир-егетләрнең берничәсе генә таныш түгел иде. Монда иркен, түшәмнәр биек, һава саф. Төүлекчеләрнең барысы да диярлек «ярты» кыстырып кергән. Кабымлыкларга да мохтаҗлык юк. Кешеләр икешәр-өчәр берләшеп, йә өерләре белән җыелышын көсф-сафә кыла. Ашау – байдан, үлем – ходайдан, дигәндәй, иртәнге «сатып алучылар» бүл күл белән җибәрмәгәннәр. Юлга «күчтәнәч» тыкканнар. Ә инде ашау – хөкүмәттән. Шуна күрә, берсенең дә эче пошмый, монда элөккәненә борчылмый кебек. Кайберләре монда еш кына кунак була икән. Ә нәрсәгә борчылсын алар: тамак тук, өс бөтен, алимент та түлисе юк. Тик берничә олы яшьтәге агай гына үзләренә урын таба алмый, әрле-бирле, керә-чыга йөри.

Җиде төүлеккә сузылган газаплы көннәремне уздырып, мин, ниһаять, өйгә кайттым. Алда тагы да авыр-раклары: цех җитәкчесе һәм комсомоллар алдында җавап тотасы бар иде әле.

Әлбәттә, бөтен күзәнәкләрне, нервларны ярсытып-кисеп торган бу вакыйгалар эзсез генә үтмәде. Цех начальнигы Попов партия, комсомол бюросы секретарьларын һәм профсоюз комитеты рәисен үз бүлмәсенә чакырып, мине эссе табага яткырып, әйләндерә-төрләндерә кыздырды да: «Сез ничек хәл итсәгез, шулай булыр», – дип бүлмәсеннән үк чыгып китте. Сугышның башыннан ахырына кадәр үткән парторг Сәгыйть Низамов басынкы тавыш белән: «Егетне читкә этәрү дөрес булмас. Ә комсомолда калу-калмавын комсомоллар үзләре хәл итсеннәр», – диде.

Җыелыш бик үҗәтле үтте. Бертөркем комсомоллар: бухгалтериядә, план-икътисад бүлегендә эшләүчеләр, контролер кызлар, аларга әле лаеш шулпасы чөмермәгән яшь егетләрнең кайберләре ияреп, мине комсомолдан чыгарырга дип бик тырышып карасалар да, производствода эшләүче егет-кызлар мине яклап чыгыш ясадылар. Нәтиҗәдә, комсомол бюросы әгъзасы булудан азат итеп, каты шелтә бирү белән чикләнделәр. Икенче көнне стена газетасы тактасына минем карикатурам ясалган зур ватман кәгазе элгәннәр иде. Мин анда кулыма ярты литр аракы шешәсе тотып, җитен комбинаты коймасын сикереп маташа идем. Бик чәнечкеле итеп шигырь юллары да сырлаган иделәр. Этешә-төртешә караган эшчеләрнең авызлары колакларына кадәр җәелгән иде. Карикатура озак эленеп торды.

Боларның берсе дә эзсез генә үтмәде шул: Фәнияне бик күрәсем килсә дә, ниндидер бер көч минем ихтыярымнан өстен көч, мине аның янына җибәрми, тоткарлап торды. «Менә бүген, иртәгә, һичшиксез, барам», дия-дия, көннәр бер-бер артлы үттеләр дә үттеләр. Шушылай аңкы-миңке икеләнеп йөргән көннәрнең берсендә, икенче сменада эшләгән чакта, гильотина кайчысында кисәргә дип алып барган бертөркем юка калайларның берсе, әрле-бирле килеп, сул кулымның беләзек турысыннан, тамырларымны кисеп, төшеп китте. Мине ашыгыч ярдәм машинасында хастаханәгә озаттылар. Операция ясап, кулның йод белән майланган урыннарында аллергия бетчәләре бүртеп чыкты. Шушыны гына көткәндәй, күптәннән иза чиктергән юеш экзема уянып, дөрләп кабынып китте. Мине Толстой урамындагы тире авыруларын дәвалау хастаханәсенә күчерделәр. Минем хәлем шулкадәр авыр иде ки, күпереп шешенгән тәннәремнән туктаусыз саркып торган су тамчыларын туктата алмый газапландым. Тамчылар хәтта керфек-

ләремнән дә тама иде. Озак корылыктан соң чатнап ярылып-ярылып киткән җир өсте кебек, көне-төне ривонол дигән сары сыекча белән чылатудан бераз кипшереп киткән, ләкин әле чыныкмаган тиреләрем аз гына хәрәкәтләнсәм дә ертылып, чәрдәкләнеп китәләр. Яңа лыждырдап саркый башлыйлар. Дәвалаучы врачлар тәнемә мазь килештерә алмый аптырадылар. Озак эзләнгәннән соң гына миңа преднизалон дигән мазьның кулай икәне ачыкланды. Гомерем буе ул минем һәрвакыт кул астымда булды.

Үземнең коточкыч хәлемне Фәниягә күрсәтәсем килмәде. Больницада ике айдан артык дәваланып ятып, аннан чыкканда, Яңа ел якынлашып килә иде инде.

Бу вакыйгаларның булып узганына инде кырык алты ел вакыт үтте. Ләкин Фәния һәрвакыт минем янәшәмдә кебек булды. Аны әледән-әле исемә төшереп, аның йөрәк тибешен һәрчак төеп яшәдем.

1998 елны, һич көтмәгәндә хатыным Сания вафат булгач, Фәния-не күрәсе килү теләге, аны юксыну аерым бер көч белән кабынып китте. Озак йокыдан уянып киткәндәй булдым. Ана карата булган хисләрем һаман саен күңелемне ныграк кочып алды. Фәния белән үткәргән чакларымны сагыну бәгыремне телгәләде. Тәүге мәхәббәтем, таң йолдызы кебек, күңел күтемдә янә балкыды. Гомерем көзендә мәхәббәтемнең әбиләр чуагы башланды. Кем ул, нинди ул бүгенге Фәния? «Әллә көндәлек матбугат аша эзләп караргамы?» дигән уйлар да чуалды башымда. Шушы сагынуюксынуларым, уй-хисләрем тора-бара шигырь юлларына яттылар.

Гашыйк булдым. Шашкын мәхәббәтем
Өермәсе алды бөтереп.
Мин күкләргә аштым, җиргә төштем,
Хис давылларына үрелеп.

Сөйгәнемнең уйнап, тик шаяртып:
«Кер яныма, цехка» дигәне,
Мин Мәҗнүнне җинаятьче ясап,
Кияү йорты иттем төрмәне.

Чәнечкеле тимер чыбыкларда
Эленеп калды сихри мәхәббәт.
Гомерем буйларына сызлый-сыкрый
Мәхәббәттән алган җәрәхәт.

Юк, юк! Сиңа үпкәләмим инде,
Әйтсәң әгәр: «Кил!» дип яныма.
Каф тауларын, дәрья-дингезләрне
Кичеп үтәр идем яныңа,
Кичеп үтәр идем яныңа.

«Өендәге хәлне күршеңнән сора», дигән әйтем бар. Хатыным Саниянең дусты, бишенче катта торучы Рәйхана безне һаман да якын итеп, икенче хатыным Асия яныпа да керә торган булды. Чөнки Асия, менә инде, унбиш ел изге Коръәнебезне уку-өйрәнү юлында Юныс һәм гарәп илләреннән килгән күп кенә хәзрәтләрдән дәрес алып, гыйлем эстәгән, мәгълүмат туплаган кеше. Ул Рәйханәне сүрә, аять, догаларны дөрес итеп укырга өйрәтә

Көннәрдән бер көнне, чәй табыны вакытында сүз иярә сүз чыгып:

– Рәис абый, синең яшьлектә очрашып йөргән бер кызың безнең йортта яши икән бит, – диде Рәйханә

– Кем икән ул? Исеме ничек? – дим мин.

– Фәния исемле...

Бу исемне ишеткән хатыным кинәт сискәнеп киткәндәй булды.

– Әллә теге шигыреңне багышлаган Фәния микән? Әллә тагы берәр Фәнияң бар идеме?

– Юк. Башка Фәниям булмады, – дидем.

Фәния дигән исемне ишеткәч, мин өнсез калдым, башым ук әйләнеп китте.

– Карале, карале, Фәния дигәч, Рәис абый бөтенләй үзгәреп китте ич! – диде Рәйханә.

Хатыным Асиядә күз карашларын аска төбәп, тынып калды. Чөнки ул Фәния белән булган фажигале хәлләрне белә иде. Аңа багышлаган шигыремне дә укыганы булды.

Искитмәле хәл булып чыкты бу. Иң гаҗәбе шул: унтугыз ел бер йортта, бер подъездда, Фәния – тугызынчы, мин икенче катта яшәп, ничек безнең юлларыбыз кисешмәде икән соң? Әллә соң аны очратып та, танымый үткән очраклар ым булды микән? Кайтканда, барганда әллә кемнәр исәнләшеп үтәләр. Бер караганда ул кешеләрне белмим дә кебек. Очратканым да булмады шикелле. Ләкин үзара исәнләшәбез. Димәк алар мине беләләр булып чыга. Гаҗәп тә түгел. Кырык биш ел эшләү дәверендә кемнәр белән генә очрашырга туры килмәгәндер дә, кемнәр белән генә эшләнмәгәндер. Дүртәр мең кешелек коллективлар белән җитәкчелек итәргә туры килде ләбаса. Төзелештә дә, автохуҗалыкта да, җәмәгать тукланы предприятиеләрендә дә, заводфабрикаларда да эшләргә насыйп булды. Кыскасы, партия кая җибәрсә, шунда эшләргә туры килде. Ә җитәкче кеше һәрберсенең күз алдында. Аны һәркем таный, күреп белә. Бәлкем минем белән исәнләшеп йөрүче ханымнар да, кайчандыр шул предприятиеләрнең берсендә эшләгән булганнардыр. Исәнләшәләр икән, димәк, мин аларның күңелләрендә яхшы тәэсир калдырганмын. Ә бу инде зур мәртәбә, үзеңә карата олы хөрмәт һәм ласклы бәя дигән сүз. Шул исәнләшеп йөрүчеләрнең берсе Фәния булды микәнни? Кешең йөзенә текәлеп карау гадәтем булмаганга, мин аны танымаганмындыр. Ә үзенең кемлеген әйтергә кыюлыгы җитмәгән, күрәсең. Ә бәлки... теләмәгән.

Язгы иртәләрнең берсендә, бакчага бару теләге белән, урамга чыктым. Баскыч төбендә берничә хатын-кыз сөйләшеп тора иде.

– Исәнмесез, хәерле иртә! – дидем, узып барышлый.

Шунда теге хатын-кызларның берсе, яныма килеп:

– Ник эндәшмисең, ник сөйләшмисең соң син, Рәис? – дип, күзләремә мөлдерәтеп карады. Аның өзгәләнеп әйткән бу сүзләрендә бетмәс-төкәнмәс сыкрану, җан газабы, көйдереп алырдай сагыш ялкыны бар иде. Мин тетрәнеп куйдым. Тез буыннарым йомшарып, чүгәли яздым.

Бу хатын Фәния иде. Ул, башын түбән иеп, әкрен генә атлап китеп барды. Мин дә баскан урынымда тораташ кебек катып калдым. Кырык алты елдан соң яшьлекнең ялкынлы мәхәббәте белән очрашу зур имтихан икән шул.

Фәния белән күрешеп, сөйләшеп утырырга никадәр генә теләсәм дә, кыш буе аны очрата алмадым. Көн артыннан көн узды, ямьле җәй җитте. Тик июнь уртасында гына аны күрү бәхетенә ирештем. Ул ишегалдында, ирләрнең иртәдән кичкә кадәр домино суга торган өстәлләреннән арырак урындыкларның берсендә ялгызы гына утыра иде. Мин дә янына килеп купакладым.

– Исәнмесез, Фәния... – дидем.

– Хәзергә исәнен исән дә. Тик кәефем яхшыдан түгел. Һава җитми, йөрәгем сикерә.

Кырык алты елдан соң, мин беренче мәртәбә аның йөзенә текәлеп карадым. Әйе, Фәния теге вакыттагы, әле унсигез яшен генә тутырып килгән чая, зифа буйлы гүзәл түгел иде. Коңгырт кара күзләреннән, элекке кебек, очкыннар да бөркелми. Алар тоныклана төшеп, карашлары офыгына

якынлашып килгән кояшка охшап калган. Ләкин ирennәре үзләренең сихри алсулыкларын саклап калганнар. Алар бүген дә нәфис, нәзакатьле иде. Еллар кешеләрнең төс-кыяфәтләрен дә, холык-фигыльләрен дә үзгәртәләр шул. Янәшәмдәге ханымның нечкә билләре дә, аларга кадәр сузылып төшкән ике калын толымнары да юк иде инде. Хәйран гына тулы гәүдәсенә озынча күлмәк кигән, битараф карашлы Фәния ханым гына калган.

– Тыйнаксызлык итеп санамасаң, кайбер сорауларга ачыклык кертергә мөмкинме?

– Мине дә билгесезлекләр гомерем буе борчый.

Безнең кыска гына сөйләшүдән шул мәгълүм булды: Фония минем җитен комбинатына койма аша сикереп кергәнемне дә, төрмәдә утырганымны да һәм озак кына хастаханәдә авырып яткынымны да белмәгән булган. Анын болар турында беренче мәртәбә ишетүе булды.

– Бу йортта яши башлаганыбызның беренче көненнән үк мин сине таныи алдым. Син дә танырсың дип өмет иттем. Ә үзем янына килергә кыймадым. Сине һәрчак кешелөр уран алган була. Эчемнән генә озгөләндем. Яндым-көйдем, инфаркт алдым. Хәзер икенче группа инвалид инде, – диде Фония, миңа моңсу караш ташлап.

Аның сөйләвеннән шуны аңлыйм, шуна төшенәм мин.

Мин шифаханәдә тәнемне каплап алган юеш экземаммы ревонол дигән дару белән киптереп, шушы холгә калуымда Фәнияне гаеплән, аңа нык үпкәләп, (җүләр түгел диген инде мине!) урынымнан кузгала алмый яткан чакта, Радик исемле бер егет Фәнияне күреп, аңа гашыйк була. Ул Фәниянең артына тагылган кебек йөреп, аларның ишек төбеннән китми. Үзенең Фәнияне шашып яратуын әйтә, кәләше булуын үтенә. Айлар буе Бибигайшә апа фатирыннан чыкмый, аның фатыйхасын сорый.

Әти-әнисе, туган-тумачалары да килеп, Фәнияне бик тә гозер иткәч, ананың да түземлеге бетеп, ризалыгын бирә.

Озак вакытка хәбәрсез югалган мине күрүенә өмете өзелгән Фәния дә язмышына буйсына, Радикка кияүгә чыга. Декабрь аенда никах укытып, ирле-хатынлы булып, Фәнияләр фатирында яши башлыйлар.

Юк, Фәнияне язмышына сукыранып, бәхетсез гомер кичергән хатын дип, һич кенә дә әйтмәс идем. Ул бүген дә ире Радик белән тату тормышта булып, улын, оныкларын яратып,үзе дә аларның эчкерсез мәхәббәтләрен тоеп, кадерхөрмәттә яши...

Февраль, 2004 ел.

МИРАС

Бүген мин, бу дөньяда шактый ук гомер кичереп, шул гомердә рәхәтен дә, аннан болай михнәтен дә татып, олыгаеп килүче гап-гади бер татар агае, уйлыйм-уйлыйм да, уйларымның очына чыга алмыйм. «Ни өчен безнең гаиләбезне авылыбызда кайберәүләр өнәп бетермәде икән?» — дим. Югыйса сугыш елларында, аннан соңгы авыр чорларда башкалар кебек үк ачлыктан да шешендек, кайгы-хәсрәтен дә күрдек, черек борәңгесен дә жыйдык, кычыткан, алабута ашлары белән дә тордык.

Әтиебез Габдуллажан, генерал Власов армиясенә эләгеп, Ленинград сазлыкларына батып хәбәрсез югалды. Без аны кайдан гына, ничекләр генә эзләтеп карасак та, бернинди дә мәгълүмат бирүче булмады. Хәрби архивлар хатларыбызны җавапсыз калдырды. Бары тик хәбәрдарлык заманы житеп, Казан студентларының «Кар десанты» фидакарь эш-гамәлләр башкарып, шул сазлыкларда ятып калган меңнәрчә солдатларның сөякләрен табып жир куенына индерә башлагач, моңынчы жиде йозакка бикләнгән серләрнең бер чите ачыла төште. Минем әтием дә илен «саткан власовчы» булып чыкты. Ярый шулай да булсын ди. Ләкин кулына корал алып Ватанны сакларга сугышка киткән шул гап-гади бер авыл агае кем гаебе белән алган соң ул каһәрле исемне?

Ярар, бу җавапсыз сорау тарихчылар, сәясәтчеләр хозурында калсын. Биш яшьлек Рәисә сеңлемне, унбише дә

тулып житмәгән Фәрит абыемны һәм тагын өч улын кочагына сыендырып калган авыру әниемә тормышны алып барырга, безне туендырырга, киендерергә, укытырга, кеше итәргә кирәк иде бит әле. Уйлап баксаң, без дә, кайбер гаиләләр сыман, ачлыктан интегергә, хәер сорашып йөрергә, балалар приютына эләгеп, таралып-таркалып бетәргә тиеш идек кебек. Ләкин әниемнең зирәклеге, дөрес тәрбиясе бөрабәренә без таралмадык та, таркалмадык та, шөкер. Ул безне кечкенәдән эшләп ашарга, хәләл хезмәт белән тормыш итәргә өйрәтте. Без авыл халкының сыер-бозауларын, кәҗә-сарыкларын, каз-үрдәкләрен көттек. Буш вакытларыбызда «уфалла» арбасы тартып урманга чаптык, болынга йөгердек. Басу-кырларда печән жыйдык. Ул чорның закуны рәхсәт иткән кадәр мал-туар асрадык. Фәкать үзебезнең тырышлыгыбыз, иртәдән кичкә кадәр карусыз хезмәт кенә безгә исән калырга мөмкинлек бирде. Арыш, бодай орлыклана башлауга, борчакның сусыл кузагы күренүгә – ул безнең авызда иде инде. Елның ин авыр вакыты – июнь, июль айларында әни сөттән төрле ризыклар әзерләп, кычыткан, алабута ашлары хәстәрләп, безне ашатты, эчертте, түкми-чәчми үстереп кеше итте.

Шунысы сәер, безнең тырышлык кайбер авылдашларга оnамый иде. Хәтта якын туганнарыбыз дигән кешеләргә кадәр безнең хакта нахак сүз сөйләп, гайбәт сатып, яла ягып йөрделәр. Безнең исән-имин яшәп ятуыбыз килешмәдеме, күнелләрен хөсетлек хастасы кимердеме, белмим. Мөгаен шулайдыр. Ничек инде аларның килене — йөрәк авырулы Хәбибҗамал ялынып, ярдәм сорап килми? Югыйсә бит бу туганнарыбыз әлләни мохтаҗлык кичерми генә, бик үк жәфа-газап күрмичә генә яшәп ятучылардан иде. Әтиләрс сугышка китми калган гаиләләрне ачлык-фәкыйрьлек читләтеп үтте диярлек. Ат жигеп, җаен белеп эшләүче ир-атка

муллык, акмаса да, тама бит ул. Ә авырлыклар, кайгы-хәсрәт беркемне дә «өлешсез» калдырмады. Кара көгазь алмаган йортлар булса да, сирәк булгандыр.

Халыкта: «Кем эше? Гали эше. Кем ниткән? Гали ниткән»,– дигән гыйбарә бар. Дөньяга бер яманатың чыксa, бөтен гаепне сиңа сылтый башлыйлар. Без дә күп вакыт шул Гали хәлендә булдык.

Нахак такма, яла якма,
Рәнҗетмә син күршеңне.
Ялган-әләк, зәһәр гайбәт,
Сүз үтерә кешене.

Дошманнар теленә кереп,
"Үләксә" булма берүк.
Ертлачлар ертыр, умырыр,
Каргалар чукыр "тук-тук".

Кортлар кимерер төнеңне ,
Эт-фәлән иснәр, ялар.
Шакалы да килеп өзәр,
Бүреләр йолкып талар.

И, тере адәм баласы,
Булма тере үләксә!
Яхшы явызга әйләнер,
Яман телгә эләксә

Дөрес, җил исмәмәсә, яфрак селкенмәс иде. Безгә бер дә юкка гына «Апу малайлары» дигән кушамат такмагандыр авыл халкы. Берәүләр моны үз балаларын безгә үрнәк итеп әйтсә, икенчеләр исә бу сүзне зәһәргә төреп, чагарга

әзерләнгән елан тавышы белән ысылдады. «Апу бандитлары» дип тә җибәрәләр иде әле. Йа Хода, нинди бандит булыйк ди инде без, көтү көтеп йөргән малайлар?! Кагылып кара калхузының берәр ниенә, төрмәгә барып кергәнеңне сизми дә калырсың. Бер уч арыш өчен бишәр ел бирделәр ул заманда. Безнең шулай үҗәтләнә-үҗәтләнә яшәргә омтылуыбыз кемнеңдер җанын кимергән, кемдер безне башкачарак итеп күрергә теләгән, ә без, киребеткәннәр, аларның өметен «акылый» алмаганбыз. Ләкин, әйткәнемчә, яфрак җил искәнгә генә селкенә бит ул. Бу – караклар иле. Монда угырылык көсеп дәрәҗәсенә күтәрелгән. Моңда түр башында утыручылар да, ишек төбен саклаучылар да урлаша. Алар бер-берсеннән үзләре урлаган мөлкәтнең күләме белән генә аерылалар. Әйтик, ындыр табагы мөдире белән ашлык җилгәрүче апалар кебегрәк. Ягъни мөмкинлекләренә карап. Бу илдә урлашмаган бер генә кеше дә юк, андый кешенең булуы мөмкин дә түгел. Хәтта кемдер үзенең карак икәнен белмичә дә йөрүе ихтимал әле монда. Без дә йоклап ятмадык, әлбәттә. Амбардан ашлык шудыра алмасак та, урманнан утынын ташыдык, болыннан печәнен чаптык, кышын чанага тояп эскерттән салам алып кайттык. Моны бөтен авыл шулай эшләде, шулай эшли алмаганы ачтан үлде, саладан салага йөреп хәер эстәде. Безне дә шулай хәерче итеп күрергә теләгәннәрдер. Брат братның көтү көткәненә рат, диләрме әле? Көнчелек, хөсетлек кешеләрнең зиһенен зәгыйфьли, кеше ышанмаслык хәлләрне бар итеп сөйли. Өченче Рейх идеологы Гиббельс әйтмешли, акылга сыймаслык ялганны бертуктаусыз кабатлый торсаң, ышанмаслыгына да ышана башлый ул кеше дигәнебез. Мисал эзләп ерак барасы юк. Күптән түгел генә фронттан кайтып, мәктәптә әдәбият укыта башлаган, үзенең шигырьләре белән бөтен тирә-якка абруйлы бер авылдашыбыз да

хәтта миңа: «Бүре баласын бүреккә салсаң да, урманга карар»,– дия торган иде. Нишләп мин, 9-10 яшьлек малай бу мәхтәрәм кешенең күзенә бүре баласы булып күрендем икән? Ул бу сүзләрне йөзен чытып, шундый бер чиркану белән әйтә иде ки, әйтерсең ул бер жирәнгеч хәшәрәт алдына баскан да, аннан укшыткыч сасы исләр аңкып тора. Ә бит ул минем әти-әниемнең кемнәр булуын яхшы гына түгел, әбик яхшы белә иде, чөнки без күршеләр дип әйтерлек идек. Минем атам тирә-якта дан тоткан балта остасы булган, шәһрәте сракларга таралган гармун остасы да. Үзенең ягымлы янгырашы, аһәңе белән туй-мәҗлесләрне, җыен-сабан туйларын моңга төргән тальян гармуны әле дә исән, әле дә безнең кулларда. Без аның балалары – дурт малай, бер кыз шушы тальян гармунда уйнарга өйрәндек, күпме мәҗлесләрдә яңгыратып, кунакларның күңелен күрдек. Ул гармун безне дә ихтирамга лаеклы кешеләр итте. Жаныбызда әткәйнең якты рухы, яныбызда әткәй гармуны яшәде.

* * *

Әнием дә Кылачы авылының иң ярлы кешеләреннән булган Шакиржан бабай кызы. Әле уналты яше дә тулмаган, күкрәге яңа калка башлаган Хәбибҗамалны Субаш Аты авылының ятиме Габдуллажанга димләп биргәннәр. Ярдәмгә мохтаж шушы ике яшүсмер авылдагы бер ташландык кара мунчага кереп тора башлаган. Кием-салым, савыт-саба, урын-жир дигәннәре бөтенләй юк. Икесенә бер иске бишмәт. Шуны жир идәнгә жәеп йоклаганнар. Әтиемнең әнисе Мәймүнә карчык ике китек чокырдан башка бернәрсә дә бирә алмаган. Рәхмәт инде авылдашларга, үзләреннән арткан иске-москыны әти белән әнигә биргәннәр.

Алтын куллы әтием шушы кара мунчаны хәйран гына рәтләп, карындыктан булса да тәрәзә уйган. Әнием дә тик ятмаган, кешелардән калган иске аяк киемнәрен үзләренә яраклаштырып теккән, иске-москыны ямаштырып яңартканы. Тора-бара читек- кәвеш, чүкләр тегәргә өйрәнеп киткән. Бу хәбәр бөтен авылга таралган. Тектерергә килүчеләрнең саны көннән-көн арта барган. Тырышкан табар, тапка кадак кагар, дигәндәй, әни бу читек-кәвешләрнең өстен тексә, әти аларга табан каккан. Шулай тырыша торгач, бер көждә бөтие дә алып жибәргәннәр. Шул рәвешчә тормышлары әкрен-әкрен үзгә төшә башлаган. Аларның бу кәсепләренә НЭПның да уңай йогынтысы тигән. Әтием Казаннан арзан бәягә өслеккә күн кисәкләре, табан аслыклары, кадак һәм башка кирәк-ярак алып кайта торган, әнием көне-төне читек-кәвеш каскан. Үзенең сөйләвенә караганда, утырган жирендә йоклаган, уянган да тагын эшкә тотынган. Көннәрнең берендә күтәрәмгә чыккан. Балаларын имезергә дә вакыты булмаган. Ул мескеннәргә әни чәйнәп биргән ипине марля аша суырып яту бәхете генә тәтеген. Бәлкем шуңадыр да егерменче елларда туган абый-апаларым бер-бер артлы якты дөньядан китә торганнар. Әлбәттә, аларны каһәр төшкән кызамык афәте дә кырган. 1928 елгы Фәрит абыемнан башлап без – дүрт малай, бер кыз – чагыштырмача гомерле булдык.

... Гомерләр үтә тора, әтием белән әниемнең тормыш хәлләре дә әкренләп яхшыра бара. Алар авылыбызның кыл уртасыннан кечерәк кенә йорт сатып алу бәхетенә ирешәләр. Әтием ул өйне сүтеп, үзенчә үзгәртеп сала. Ул бөтен сәләтен, осталыгын куеп эшли. Йорт хәйран матур килеп чыга. Аның яңа тәрәзә яңаклары, бизәкләр уеп ясалган кашагалары, фигуралап киселгән коймалар, рәсемнәр төшерелгән капка узган-барганны сокландыра. Кара мунчада уртак

тормыш башлаган әти-әниемә бу йорт хан сарае булып тоела. Ягам дисәң, акшарланган ап-ак миче бар, басам дисәң, калын такталардан җәелгән җылы идәне бар. Үз сәкеләрендә рохәтләнеп җәелеп йоклый алалар. Калдык- постык такталардан сөштырып корылган лапас та бүш түгел. Андагы ап-ак кәҗә янына, иш янына куш булыр, дип, күрше Гайнижамал карчык бер сарык бәтие дә кертеп бира Ул да зур гәүдәле сарыкка әверелеп, ишәйгәннән-ишәя барган. Төмле, мул сөтле ак кәҗәбез шул сарыкларны котүдән ияртеп кайта торган булган. Бер-бер артлы балалары туып торган ишле гаиләгә әниемә ничек тә ярдәм итәргә теләве булдымы икән әллә аның?

Әтиемнең осталыгын күргән-белгәннәр аны әле анда, әле монда йортлар салырга чакыра башлаганнар. Эшенә күрә сый-хөрмәт күргән әтием тазарып, матураеп китә Ул инде хәзер алама өс-башлы, чебиләп беткән яланаяклы, өй асларында, абзар-кураларда, печән-салам араларында йоклап тәмам бетерешкән, сукбайлыкта йөрен, төрле авырулардан интеккән арык малай түгел, шөһрәт казанган балта остасы, исеме телләрдән төшмәгән гармунчы, кешеләрнең ихлас ихтирамын яулаган мөхтәрәм Габдуллажан! Ә бераздан зур тәҗрибә туплаган әтиемне яңа оешып килгән колхозда балта осталары бригадиры итеп куялар, ул исәпхисапка да һәвәс кеше була.

Ишәйгәннән ишәя барган гаиләгә йортның да зуррагы кирәк. Мин туган 1935 елны теге курчак кебек кечкенә йортка алмашка зурысы күтәрелә. Төзелеш барган бу вакытта әнием төннәр буе читек-кәвеш тексә, иртә таңнан ипи-күмәч, башка кирәк-ярак алырга Казанга йөгерә Шуның өстенә берсеннән- берсе кечкенә дүрт малаен кararга да өлгерергә кирәк бит әле. «Тигез җирдә сортенеп егыла башладым», - дип искә ала иде әнием ул көннәр турында

сөйләгәндә. Утыз көн уразаның бер көне бәйрәм булган кебек, боларның тырышлыклары да берзаман шатлык алып килә. Ниһаять, йорт, каралты-кура төзелеп җитә. Безнең бу йортыбыз ике өйдән торып, икесенә дә мич чыгарылган иде. Ишегалды ягындагы тышкы ишектән коридорга килеп керәсең, аның аргы башына узып, уң яктагы ишекне ачсаң - зур өй. Ул үзе тагын ике өлештән тора. Ишектән кергән өлешен почмак як дип, э такта белән бүлеп алынган икенче өлешен түр як дип атый идек. Бу ике өлешне бүлеп, уң як стенадан бераз ара калдырып салынган зур мич утыра. Анда ипи һәм башка таба ризыклары, э казан аскан учак ягында аш-су пешерә идек. Зур өебезнең дүрт тәрәзәсе урам якка, ә ике тәрәзәсе ишегалдына карый иде. Зур елгага килеп кушылган инеш шикелле, коридорның сул ягыннан кечкенә коридор килеп тоташа. Ул тышкы ишектән керүгә сул якка таба сузылып, кечкенә өебезне һәм «Г» хәрефенә охшатып төзелгән йортыбызның ишегалдына таба чыгып торган өлешенә урнашкан дүрт бүлмәне берләштереп тора. Ул бүлмәләрдә артык кием-салым, урын-җир әйберләре, әтинең эш кораллары саклана иде. «Караңгы бүлмә» дигәннәренде он, ашлык белән тулы капчыклар, тагы да шуның ише әйберләр булыр иде. Без, малайлар, җәй көннәрендә шул бүлмәләрдә йоклый идек. Андагы тәрәзәләр көньякка, ишегалдына таба, «п» хәрефенә охшатып корылган каралты-кураларга карап тора иде. Кечкенә коридорның очында очырмага менә торган баскыч та бар иде. Зур һәм кечкенә өйләребезнең ишегә капма-каршы булып, берсен ябык икенчесен ачып булмас иде. Кечкенә өебезнең ике тәрәзәсе бәрәңге бакчасына карап тора. Анда карлы офыктагы басу-кырлар җәйрәп ята, елга ярындагы тау битләре күренә. Безнең як ярга сыенып, таш араларыннан йөгереп аккан инеш суы - үзебезнең челтерәвек чишмәләрдән

чыккан су. Шуңа күрә авылыбызны Субаш дип атаганнар да инде. Без шул суларда коенып, балыгын тотып, язгы ташуларын карап үстек.

Һай, күңелле дә иде инде ул ташу киткән көннәр! Олысы-кечесе – елга буенда. Без, малайлар, боз өстенә салам ягып агыза идек. Мактанып әйтүем түгел, мин агып барган боз-ларның берсеннән икенчесенә сикерә-сикерә саламга ут төртә идем. Берчак шулай сикергәләп йөргәндә, таеп китеп ташуга да актым. Ул кан өшеткеч кар суыннан ничек чыкканмындыр, әле дә гаҗәпләнәм. Әҗәл җитмәгән, ризык бетмәгән булган, күрәсең. Тырыша-тырмаша чыктым да, бакча башларыннан гына өбиләргә элдерттем. Салкын үзәккә үткән, эчемдәге бөтен әгъзаларым каядыр шуыша, сикерешә кебек тоела. Тешләр тешкә тими. Иякне куллар белән кыссам да, калтырануын һич туктатып булмый. Бөтен тән дерелди. Аяк-куллар тәннән ычкынырга теләгәндәй, тартыша, сикерешә, кинәт-кинәт каз тәне бүртеп чыга, агарынып китәм, бөтен гәүдәне көзән җыера башлый, нинди-дер көч аны эчтән хәрәкәткә китерә.

Әбинең өйдә юк чагы туры килде. Бабам тәнемне бер-туктаусыз уып, мине җылытырга тырыша. Чокырны үзе тотып кайнар чәй эчерде, чөнки үзем күтәрерлек хәлдә түгел идем. Бабам бөтен җиремне каз мае белән ышкып, кайры туныма төреп яткырды. Үзе бертуктаусыз: «Раббым, сихәт-лек бир улыма!» – дип кабатлый торды. Озак калтыран, дерелдәп газапландым мин җылы мич башында. Бераздан шабыр тиргә батып йокыга талганмын.

* * *

Бабам Галиулла искиткеч рәхимле, яхшы кеше иде. Аның кайбер ямьсезрәк гадәтләре булса да, ул үзенең гаҗәп

тә юмартлыгы, шәфкать-миһербанлыгы, кешеләргә һәрчак кулыннан килгәнчә ярдәм итеп, аларның хәленә хәлдәш була алуы белән авылдашларның ихтирамын казанган аб-руйлы зат иде. Озак еллар читтә йөреп, күпне күргән, ишеткән-белгән кеше буларак, аның янына киңәш-табыш-ка еш киләләр иде. Андыйлар өчен аның ишеге һәрвакыт ачык, күңеле иркен булды. Шушы күркәм сыйфатлары аңа дәрәҗә өсти, эреле-ваклы түрәләрне аның белән исәпләшергә мәҗбүрли иде. Ул, кайберәүләр кебек, бәласеннән баш-аяк, дип, башын яка эченә яшермәде, үз сүзен нык итеп, җеле-геңә төшәрлек итеп әйтте. Нахакка рәнҗетелгән, яла ягыл-ганнарны көнсәнең үзенә барып, район вәкилләре белән талаша-талаша яклады, күп кешеләрне төрмәдән йолып калды.

Шулай берчакны озын тәнәфескә чыккач, малайлар мәктәп коридорының бер башыннан икенчесенә йөгерешеп, ду килеп уйныйлар икән. Араларында минем мәрхүм Рәшит абыем да була. Шунда малайларның берсе аны ялгыш этеп жибәрә. Абыем йөгергән шәпкә сөртенә дә мәктәп коридо-рына куелган Сталин бюстына сөрлегә. Бөек юлбашчының гипстан әвәләнгән башы идәнгә тәгәри. Балалар өнсез кала. Бөген илне дер селкетеп, асасын асып, атасын атып үзенә табындырган Сталин башсыз калсын әле! Мәктәп аякка баса. Уникә яшьлек абыемны җилтерәтеп директор бүлмәсенә алып керәләр. Аның янәшәсенә ипташләре дә кереп урнаша. Куркуларыннан үкереп елаган балалардан сорау алу башлана. Ул арада әниемне чакыртып китертәләр. Авыл советы рәисе Садыйков, партоешма секретаре Ис-мәгыйлов та йөгереп килеп җита. Нишләргә? Бу бәладан ничек исән-сау котылырга? Әгәр югарыда утыручы түрәләр белеп алса, чебеннән фил ясаячаклар. Авыл җитәкчеләре-нең, бигрәк тә мәктәп директорының башы чабылмаса да,

себер китәсен көт тә тор. Малайларның әти-әниләре дә «елешсез» калмаячак, әлбәттә. Җитмәсә, «халыклар атасы» Сталинның дистәләгән Кавказ һәм Кырым халыкларын мал вагоннарына төяп сөргенгә олактырган 1944 ел бит ул. Шундый ук хәтәр язмыш безнең татар халкына да янаган бит. Гөнаһсыз балаларның саксыз шаярулары әнә шул мәкерле гамәлләрне тормышка ашырырга тагын бер сәбәп булса?

Мәктәпкә бабам да йөгереп килеп җитә. Балалар сыйныф бүлмәләренә дәрескә кереп киткәч, мәктәп директоры (аның фамилиясе истә калмаган) белән бергәләп Сталинның гипс башын һәм биленә кадәр булган өлешен яшереп куялар. Шул ук көнне директор һәм авыл советы рәисе колхоз рәисе Мансур абыйның трантасына утырып, каядыр китеп бардылар.

Мәктәп директоры, Казаннан килеп, гаиләсе белән мәктәп йортының беренче катында тора иде. Озын телләрнең әйтүенә караганда, әллә өйрәсе сыек булды, әллә мондагыларның җаен таба алмады, озакламый, берни дә майтармыйча, Казанына кайтып китте.

Трантаска утырып иртән китеп барганнар әйләнеп кайтканда кич җитеп, көтү кайтып таралган иде инде. Аларны дүрт күз белән көткән бабам, җәһәт кенә киенде дә, мәктәпкә юнәлде, ул төнне өйдә кунмады. Ниндидер тимер кисәкләре тутырган букчасын да үзе белән алган булып чыкты. Иртәгесен без укырга килгәндә бюст элеккедән дә матуррак булып үз урынында утыра иде.

— Сталин бабай ак күлмәк кигән! — диештеләр балалар.

Ә ана кадәр, көтү чыгып китүгә үк бабам безгә кердә. Мәктәп директоры янына баргач, хәлнең никадәр кискен икәненә төшенеп һушыннан язган әниебез йөрәк өянәге белән урын өстенә егылган иде. Ул елларда бездә фатирда

торып, балалар йортында шәфкать туташы булып эшләүче Диләфрүз апа әнинең яныннан китмәде диярлек. Галиулла бабай зур канәгатьләнү белән елмаеп:

— Килен, кайгырма! Сталинны үз урынына утырттык!— дигәч, әни әсәрләнеп урынныннан ук тормакчы иде дә, башы әйләнеп, янә ястыгына түнде.

— Аның кан басымы бик югары,— диде Диләфрүз апа.

Шулай да, бабай китергән шатлыклы хәбәрдән әнинең йөзе, кояш чыккандай яктырып, нурланып киткәндәй булды.

— Бик зур рәхмәт инде сиңа, кайнатай, Аллаһы Тәгалә әҗерен бирсен, рәхмәтеннән ташламасын,— диде ул.

— Шулай булсын, изге теләкләрең өчен үзеңә рәхмәт.

Бабай ул бюстны ни рәвешчә, нинди әфсеннәр өреп рәткә керткәндер, анысы безгә мәгълүм түгел. Ул турыда үзенең дә сөйләгәне булмады. Хәер, сөйләсә дә ул чакта без аны аңлый алыр идек мени? Ләкин аның кайчандыр завод-фабрикаларда эшләп бай тәҗрибә туплаган оста һөнәр иясе икәнлеге көн кебек ачык иде. Тагы да гаҗәбе шул: авылыбызның гайбәт сатып йөрүче иң әшәке әләкче куштаннары да бу вакыйганы йомып калдырдылар. Югарыдан килеп тикшерүче дә күренмәде.

...Галиулла карт беркайчан да теле чишелеп, үткән тормышын искә алырга атлыгып тормый. Шулай да үзеннән ара-тирә саркып чыккан сүзләргә, авылдашларның сөйләгәннәрсенә карап, аның хакында беркадәр мәгълүматым бар. Акыл дәрәҗәсе ягыннан кардәшләреннән бер башка өстен торган, сабан туйларында мәйдан тоткан бу чая егетнең сөйгән кызын башка авылга димләп биреп җибәрәләр. Мәхәббәт ялкынында өтәләнгән йөрәгенә урын таба алмагач, чит-ят якларга чыгып китәргә мәҗбүр була ул. Улларының өзгәләнгәнен күреп, ата-анасы да каршы

килергә базмый. Аллаһы сакласын, әллә нинди җүләрлекләр эшләп ташлар да, бәла-казага тарырбыз, дип куркалар алар. Жанында сойгән ярын югалту әрнүе көтырынган чабаталы егет Идел ярларына барып чыга, шунда бурлакка ялланып бай урыс купецларының баржаларын тарта-сөйри башлый. Урысча бер авыз сүз белмәгән авыл егете, җилкәсенә аркан салып, бөтен Рәсәйне әйләнә. Бөек рәссам Репинның мәшһүр картинасында бәлкем аның йөзе дә чагылыш тапкандыр. Тормыш арканы барлык милләтләрнең дә ярлы-ябагасы өчен бер үк дәрәҗәдә авыр бит ул. Бабамның бу чоры аркан белән генә түгел, язмышы белән дә тартышып уза. Чабаталы авыл малае тормышның ачысын-төчесен мул күргән. Берничә мәртәбә үлем тырнагыннан котылып, исән калып чын ир-егеткә әверелгән. Ул инде хәзер, беренче елардагы кебек, уң яңагына сукканда сулын куеп тора торганнардан түгел. Андыйларның арт сабагын үзе дә укытып җибәрергә күп алмый. Ләкин гомеренең асыл чоры, «Ашый калҗа, сөя маржа» дигәндәгедәй, тапканын кабып уза. Идел сулары сыман әле тыныч кына, әле ярларыннан ташып чыгардай булып яши зимагур. «Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырларсың», диләр ич. Ул да типтерү-җилкенүдә бурлак иптәшләреннән калышмый. «Бары — бергә, югы - уртак», дип яши бирә.

Елгалар буэ белән капланган кыш көннәрен Алафузов, Крестовников фабрикаларында эшләп уздыра бабам. Идел боздан арынган арада ялтыравыклы хром итекләр, яхшы киемнәрдән авылына кайткан чакларында эти-әнисе үз яннарында калырга үгетләп, кызлар да димләп карыйлар. Ләкин аның авылда калып, агач сука белән җир сөрәсе килми инде. Шул ук вакытта Казанда да төпле урыны юк. Өйләнгән исәптә, кәләшең белән яшәрлек үз оян кирәк. Ә Галиулланың куышы да юк. Хәер, ул үзе бу хәлгә әллә ни

борчылмый да кебек. К. Маркс әйтмешли, аның бит кулаяклары тышаулап торучы богау чыңнары гына бар. Ул — чеп-чи пролетариат! Большевикларның маевкаларында, эшчеләрнең забастовкаларында катнашудан да баш тартмый. Урам сугышларының берсендә уң күзен югалта. Заманында нык бәдәнле, мускулларында көч ташып торган сөлек кебек бу татар егетеннән тегесе дә, бусы да оста файдаланган. Большевикларның мавыктыргыч, әкияти матур тормыш вәгъдә итүләренә ышанып, революция ясаучыларның берсенә әверелә. Тик тормыш дигән бөек хәрәкәтнең үз кануннары бар: гомер үтә тора. Әлифне таяк дип тә белмәгән, үзлегеннән укырга-язарга өйрәнгән революция солдаты Галиулланың инде беркемгә дә кирәге калмый. Эшләнәсе эшләнгән, көлтә җыясы гына калган. Ул эш эзләп тегендәмонда сугылып карый. Дус-ишләре белән сөйләшеп, тормышын җайга салып җибәрергә бик теләсә дә, берәүнең дә аны үз канат астына аласы килми. Һәркемнең үз хәле үзенә житкән. Һәркайда ачлык, мохтаҗлык. Гражданнар сугышыннан соң ил, күтәрәмгә калган хатын кебек, көч-хәл белән сулап ята бирә. Гомер буе шәһәр тормышына күнегеп житә алмаган Галиулла гомеренең заяга узганын шунда гына аңлап ала. Терсәк якын, тик тешләп булмый, үткәннәр кире кайтмый. Берәр үзе шикелле ярлы хатын белән яңа тормыш корып җибәрергә дә инде үтә соң. Ә бай хатыннарга әле дәрте булып та, дәрманы сүнеп барган, иллегә якынлашып килүче ирнең хаҗәте юк.

Таланудан фәкыйрьлекнең аръягына чыккан илдә көтелмәгән үзгәрешләр башлана. Элеккеге кызыл авыз бәндәләр, байлыкларының бер өлешен яшереп кала алган сәүдәгәрләр, приказчиклар котырынып алыш-биреш итә башлый. Тормыш акрын-акрын элекке эзенә төшкән кебек була. Завод-фабрикаларның тырпаеп торган биек моржала-

рыннан яңадан төтен ургый башлый, иртә таңнан гудок авазы эшкә чакыра.

Галиулла, бер яктан, тормышның болай җанлана баруына, кешеләрнең эшкә урнашып тернәкләнә башлауларына чын күңеленнән куанса, икенче яктан, зур корбаннар бәрабәренә яулап алынган ирекнең көннән-көн кысыла-тараюына, демократия казанышларының берәм-берәм югалуына җаны-тәне белән борчыла. Кайчандыр сыйнфый көрәшнең алдынгы сафларында барганнарның янәдән дә хуҗа булып алган буржуйларга бил бөгүсез күреп, канәгатьсезлек хисләре кичерә. Большевиклар кылган гамәлләрне рухы белән кабул итә алмый. Сәясәттә белгеч булмаса да, яңа хакимиятнең милли мәсьәләдә демократиядән читкә тайпылуын, ил буенча татар телендә чыгып килгән гәҗит-журналларның советлар тарафыннан ябыла баруын күрү жанын рәнҗетә. Пролетариат диктатурасы түгел, ә власть диктатурасы урнаша баруын күреп, зур корбаннар булачагын тоемлаган кебек, куркып кала, егерменче еллар башында авылына кайтып сыена.

Инде ярты гасыр гомер кичерсә дә, әле тормыш авырлыкларыннан бөгелеп төшмәгән, үзен егетләрчә тоткан Галиуллага Беренче бөтендөнья, аннары гражданнар сугышларында ирләрен югалткан тол хатыннарның берничәсен димләп карыйлар. Тик ул, калган көтү калган диешме, өйләнергә ашыкмый, әти-әнисе белән торып, шыпырт кына, кабаланмый гына кешеләрне күзәтә, авылны өйрәнә. Ниһаять, аның күнеле җир җимертеп эшләп йөрүче, таза, зифа буйлы әбием Мәймүнәгә төшә. Әбием дә озак тартышып тормый. Ләкин бер шарт куя: Галиулла хатын йортына күчеп килергә тиеш!

Бабамның үз баласы булганмы, юкмы – ул кадәресе миңа мәгълүм түгел. Балкем булып та бер-берләрсез белмиләрдер.

Аның бу хакта беркайчан да әйткәне булмады. Әмма ул безне үлеп тә яратты. Бөтен назын, җан җылысын безгә бирде. Авыр туфрагы җиңел, урыны Җәннәттә булсын! Безнең йортлар арасында Гайнижамал апалар гына булганга, без, малайлар, һәрчак бабам янында кайнаштык. Мин бигрәк тә инде. Бабам алдыннан төшми, аның күзенә йоклап, иркәләнеп үстем. Әби-бабамның бездән башка ашарга утырганын да хәтерләмим. Өстәлгә ризык куелуга, бабам эшермәле тәрәзәсен ачып: «Малайлар, ашарга кайтыгыз!» – дип аваз сала иде. Вакытында кайта алмаганнарның өлеше мич алдында аларны көтеп торыр иде. Әгәр без сугышны һәм сугыштан соңгы авыр елларны исән-сау кичеп чыга алганбыз икән, моңда, һичшиксез, әби-бабамның тырышлыгы, аларның ярдәме зур булды. Аларның идән асларында һәрчак булып торган бәрәңгеләре коткарды.

Азмы-күпме белеме булган, пролетариат шулпасын да күп чөмергән Галиулланы авылда совет җитәкчесе итеп тә куярга уйлаганнар. Тик ул, бу эшнең хәтәрлеген сизептер инде, ризалык бирмәгән. Бабам җаны-тәне белән җиргә берегә, сукалый, чәчә тирләп-пешеп игенен игә. Әби-бабалары, әти-әниләренең гомер-гомергә каннарына сеңгән, геннар белән буыннан-буынга күчеп килгән игенче һөнәре бөтен ләззәте, мәшәкате белән аны бөтереп ала. Миләрне кайнатырлык җәйге челләдә дә урак урып рәхәтлек кичерә. Тиеш булып та, моңарчы үти алмаган вазыйфасын башкарудан күңеле тулып ташый. Өлгереп, менә-менә коелырга торган орлыклар аңа елмайган сыман тоела. Җир-ананың мәрхәмәтле игелегеннән тәненә сихәт керә, дәрте ташый, әле генә мичтән чыккан ризыкларның төме сихерли. Болыннарда каерып печән чапкан чакларында яшьлегенә кайткандай була. Кайчандыр тәүге мәхәббәтен югалтудан яраланып калган йөрәге иртәнге сафлыктан дәва ала, чишмәләрнең

тылсымлы сулары җаның дәвалый. Ул, госел коенган мәселман сыман, пакьләнеп кала. Матур өс-баш, ялтыравык күнитекләр киенеп буй-сынын бизәсә, әхлакый халәте, холык-фигыле аның күңелен күркәмли. Җан белән тәннең тәңгәл килүе - кешенең гомер буе ашкынган бәхет-сәгадәткә ирешүе. Нәкъ әнә шундый бәхет кочагында гомеренең алтын чорын кичерә безнең бабабыз. Ул әбинең олы яшендә кабынган мәхәббәт ялкыны биргән сихәтле җылыда рәхәтләнеп, аның кайнар кочагында хөрмәт-ихтирам тоеп яшәде. Илленең өске ягына чыккан кешегә шушыннан да кадерле нәрсәнең булуы мөмкин түгел ләбаса! Гомер буе зимагурлыкта йөреп, назга, сөю-сөелүгә сусаган иргә Мәймүнә әбием белән бергә-бергә тигезлектә үткән елдар хыялга тиң була.

Бабамның яратып йөргән бердәнбер урыны - тимерче алачыгы иде. Ул бирегә йомышы төшеп тә, төшмичә дә бигрәк тә эче пошканда, җаны уйнаган чакларында килә. Алачык аны металлны магнит тартакан кебек үзенә тартып тора. Мондагы тимер исеннән аның яралы күңеле тыныч ланып киткәндәй була, йөрәге майлаган сәгать сыман эшли башлый. Үткән гомер никадәрле генә фаҗигале, хәвефхәтәрле булса да, кадерле хатирәләр күңелдә әледән-әле яңарып тора шул. Чөнки анда, яхшымы, яманмы - син үткән юл, гомерең чәчәк аткан ин кадерле чорлары, син кылган гамәлләр, син кичергән кайгы-шатлыклар, уйхисләр, югалту һәм табышлар... Боларның барысы да кеше дигән акыллы затны тәрбияли, аны рәхмәтле-миһербанлы булырга өйрәтә, кыюлык-батырлыкка өнди. Кайчандыр Казан заводларында эшләп, тимерне корычка әверелдергән, аны су кебек кайнаткан, камыр кебек изгән, кирәкле формага салган чаклары сагындыра аны. Ул яшьлеге белән бәйле көннәрен юксына. Алачыкка килүгә җиң сызганып

эшкә керешә. Шул эшеннән канәгатьлек кичерә, тирләп-пешеп көч түгүдән төм таба. 1905 елларда революцион эшчәнлеге өчен безнең авылга сөргенгә серелгән, еллар дәвамында инде төмам үз кешегә әверелгән тимерче Федор дәдәй белән алар учакта кызган тимер кисәген сандалга салып, чүкечләрен уйната башлыйлар.

Әби бик үк өнәп бетермәсә дә, Федор дәдәй бабайларга еш килә иде. Әле татарча, әле русчага күчеп гапьләшергә яраталар иде. Әбинең тегендә-монда киткән чагы туры килсә, бабай, җәһәт кенә берәр чиләк бәрәңге сатып, «чәкүшкә» дә алып җибәрә. Федор дәдәй моның шулай буласын алдан ук белгән кебек, букчасыннан төзлаган гөмбә чыгарып куя. Шушы гөмбәләрнең төмен белеп, суыра-тешли каба-каба тегеч «чәкүшкә»дәге аракыны чөмерергә, һай, ничек ярата иде алар. Гапьләшеп сүзләре бетмәс иде. Икесенең дә төтеннән саргаеп беткән бармакларыннан төмәке төшмәс иде. Алар янына ип-иптәшкә Борһан абый да килеп кушылгалый. Ул да гомере буе читтә йөреп, Галина исемле маржага өйләнгән булган. Авыл кешеләре ул маржага Галия дип эндәшәләр иде. Татарчаны ватып-җимереп сөйләшсә дә, авыл халкына хөрмәт белән карый иде ул. Аларның да балалары булмады.

Шушы тәбәнәк буйлы, басынкы гәүдәле, көрәнсу тукмак борынлы, йөзеннән җәен-кышын шәфәкъ кызыллыгы китмәгән Борһан абзый чабата үрү остасы иде. Ул чорда аягына киярга башка нәрсәсе булмаган авыл халкы аның янына килде. Борһан абзый чабаталарның төрлесен: зурысын да кечкенәсен дә, күтәрмәлесен дә үрде. Әгәр Галия апа чабата ясаган өчен алган акчасын вакытында электереп кала алмаса, ул тиененә кадәрле, хәтта өстәп әҗәткә кереп тә, аракыга тотылып бетәр иде. Көннәр буе чәшле белән юкә каезлап утырып аргач, гәүдәсен бераз алга таба

сөреп, йөгергәндәге сыман сикерешле адымнар белән, абына-сөртенә бабайларга килеп керер иде. Теге тукмак борынын сөртәсөртә ялтырап беткән бияләйләрен өстәл өстенә ташлар да, авыл хәлләрен сөйләргә тотыныр. Ә мондагы тормышны бетен нечкәлекләренә кадәр белә иде ул. Чөнки чабата алырга килүчеләрнең һәрбере аңа сер итеп кенә нидер сөйләп китә иде булса кирәк.

Шунда Казан тирәсендә кайнашкан әбием почмак яктан чыга:

— Борһан, маңкана катып беткән бияләйләреңне өстәлгә куйма, дип ничә мәртәбә әйтергә кирәк сина?!

Борһан абый, үзен «культурный» кеше итеп күрсәтергә теләп, кат-кат гафу үтенгән була. Бияләйләрен кучкарга алып куя.

Үзләрен пролетариат дип атап, мал-туар тотмый, колхоз эшенә чыкмый яшәүче бу иш кешеләргә авылдашларның әледән-әле йомыш-үтенечләре төшеп торса да, аларны әллә ни хөрмәт итүче булмады диярлек. Аларга килмешәкләр итеп кырын карадылар. Йөзләренә үк бәреп әйтмәсәләр дә, эчләрендә ачу йөрттеләр. Чөнки башкалар ачлыктан шешенеп ятканда, үлем хәбәре урамның бер очыннан икенчесенә канлы күз яшьләре түктереп йөргән ул заманда, юклыктан, чарасызлыктан кая барып бәрелергә белмәгән халык алдында бу кешеләрнең исереп йөрүләре икеләтә рәнҗетә иде. Кем әйтмешли, тычканга үлем, мәчегә көлке, сыман чыга иде. Гәрчә алар сынганны ялгап, ватылганны төзәткәләп тапкан акчаларына эчсәләр дә. Шулай да ул елларда әби-бабаларыбыздан килгән күркәм гадәтләрне бозып, әдәп-әхлакъ кысаларыннан чыгып, эчеп-исереп йөрүче авыл сәрхүшләре бармак белән генә санарлык иде әле. Аларны да читтә йөрсп кайтканнардан булды.

«Кеше хәлен кеше белми, үз башына төшмәсә», ди бит

халык. Бу иш авылдашларның хәле дә ал да гөл булды дип әйтә алмыйм. Кайчак чыгырдан чыгып китүләре дә тикмәгә генә булмагандыр. Шушы гажәеп гүзәл дөньяга килеп тә, сагынып сойләрлек игелекле эш-гамәлләр кылып, үзеңнән соң хөрмәткә лаек, абруй-дәрәҗәле варислар калдыра алмау — заяга үткән гомер түгелме соң? Борһан абый, минем бабам кебекләрнең нәселе, нәсабе киселеп юкка чыкты ич. Алар бәхетне читтән эзләп, бәхетсез калган нәүмиз бәндәләр иде ләбаса.

...1933 елның язы һәм җәй башы матур гына килеп, явым-төшеме дә вакытында һәм кирәгенчә генә булып, авыл халкында зур өметләр уята. Алар гөрләп үсеп килгән иген кырларына карап шатланып туя алмыйлар. Аллаһы Тәгалә әвәлен-ахырын хәерле кылып, игеннәрне түкми-чәчми җыеп алырга насыйп булса, тегесен алырбыз, монысын юнәтербез, дигән планнар коралар. Әле колхозга керергә өлгермәгәннәр кирәк яракларның майлыйсын майлап, җайлыйсын җайлап, төзәтәсен төзәтеп, дигәндәй, көзге эшләргә ныклы әзерлек чаралары күрәләр. Колхозчылар да тик ятмый, әлбәттә. Алар да ат арбаларын, барлык эш коралларын күздән кичерәләр. Ләкин монда инде синекс дә, минекс дә түгел, хуҗаларча караш юк, эш миннән киткәнче, иясенә җиткәнче, дип кенә эшләнә Уртак малны эт җыймас, ди бит халык та. Шулай да һәркем ашлык уңышына зур өмет багълый. Яшьләр көзен кызыл туйлар ясарга вәгъдә бирешәләр.

Ләкин бу якты өметләр чәлпәрәмә килә. Июль аенда тоташтан яңгырсыз эссе көннәр башлана. Җир өсте коры туфракка әверелә, зур-зур ярыклар хасил була. Өлгереп җитмәгән орлыклар башакта куырылып кибәләр. Вакытыннан алда уракка төшкән халык зәңгәр күктән бөркелгән эсселектән, һава җитмәүдән интега Балалар берничә мәртәбә карга бот-

касы пешереп, су сибешеп тә карыйлар, тик болытлар гына күренми. Ботен халык Аллаһыдан ялварып яңгыр сорый.

Шундый көннәрнең берсендә зәңгәр күк йөзендә ястык кадәр генә болыт кисәге пәйда була. Өйлә ашыннан соң бераз ял итәргә чүмәлә астына кереп яткан кешеләр аны күрмиләр дә. Ә теге, зурайганнан зурая барып, берзаман коянны ук каплап куя. Күп тә үтми, ялт-йолт итеп яшен кылычларын уйната башлый. Ул да булмый, кара болыт аксыл төскә кереп, чиләктән орган кебек яңгыр яварга тотына. Шулкадәр көчле ява ки, чүмәләгә куелмый калган көлтәләр тигез җир өстендә ага башлыйлар.

Бу көтелмәгән хәлдән ыгы-зыгы килгән халык кайтыр юлга чыга. Ләкин ташу булып ыргып аккан су басма-күперләрне җимереп, агызып киткән. Елга аръягында киселеп калган кешеләр нишләргә белми аһ-ваһ киләләр. Ә яңгырның туктарга исәбендә дә юк. Ул әле бер, әле икенче яктан әйләнеп килә дә, йә боз, йә яңгыр булып ява да ява. Тели белсәң — теләк, тели белмәсәң — имгәк, дигәндәй, башта кечкенә, юаш кына булып тоелган болыт кисәге әнә шулай бәла-каза алып килә. Фаҗигалар да була. Төнгә аръякта калырга куркып, елга аша чыгарга маташучыларның байтагы суга агып китә. Безнең якын туганыбыз Нәгыйм абый да, елга уртасында арбасы капланып, хатыны, олы улы белән суга ага. Аларның үле гәүдәләрен иртәгесен яшелчә бакчалары янындагы таллыктан табып алалар. Ятим калган нәни уллары Фәйзрахман абый уналты яшенә кадәр бездә яшәде.

Баштанаяк лычма суга чыланган кешеләр нишләргә, кая барырга белми аптырап торган шул вакытта бабам, атын туарып әбигә тоттыра да, көлтә төялгән арбаны җилкәсенә салып аргы ярга чыгарып та куя. Бу хәлне күреп торган авылдашлар аһ итә. Бабам ташуны йөзеп янә кире чыга,

әбине атка атландыра һәм аты белән бергә тагын теге якка йөзеп чыга. Бу хактагы хәбәр, кеше ышанмаслык вакыйга булып, күрше авылларга кадәр тарала. Аны мин үземне белә башлаган елларда да сөйләп сөйлиләр иде әле. Шулай итеп, бабамның бурлак булып йөргәндә алган тәҗрибәсе эшкә ярап куя.

Бабабыз гомеренең соңгы елларын ашлык амбарларын, җәй көннәрендә яшелчә бакчасын саклап-каравыллап үздырды. Аның иң рәхәте безгә — көтүче малайларга иде инде! Маллар көндезге туплауда чакта берәм-берәм барып, аның үзе корып куйган шалашында кыяр, кишер, ә көзгә табарак искиткеч тәмле кып-кызыл помидорлар белән сыйлана идек. Ул без килүгә иң матурларын сайлап, юып әзерләп куйган булыр иде. Юк, бабабыз бу игелекле гамәлләрен бер безгә генә күрсәтеп калмады. Бөтен авыл халкы яшелчә бакчасыннан азмы-күпме файда күрде. Әйтик, түтәлләрнең чүбен утарга килгән хатын-кызларның итәк асларына кыстырып кишер, кыяр алып кайтулары гадәти хәл иде. Кәбестә бакчасына кергән кәҗәнең авыз итми калуы һич мөмкин түгел. Ул бакчага шуның өчен дип кергән ләбаса! Үзенең юмартлыгы, киң күңеллелеге белән хөрмәт казанган, кешеләргә булдыра алган кадәр ярдәм итәргә омтылып яшәгән бабам бу «кәҗә»ләрнең кыңгыр эшләрен күрсә дә күрмәде, белсә дә белмәде. Өенә ярдәм сорап килүчеләрне буш кул белән борып чыгармады. Аның бу гадәтләрен белгән авыл җитәкчеләре дә ду куптармадылар. Инде авылның ата әләкчеләре килеп: «Чара күрмәсәгез, югары оешмаларга җиткерәчәкмен!» — дигән очракларда гына шул кыңгыр эшләргә мәҗбүр булган кешеләрне яннарына чакыртып, мәсьәләнс ачыкларга, мөмкин кадәр йомшак чара күреп, рәнҗетми хәл итәргә тырыштылар. Югыйсә ул кыңгыр дип аталган эшләрнең нигезендә ачлык-фәкыйрылек яткаиы,

кая барып бәрелергә белмәгән мескен җанның парә-парә бәргәләнүе барысына да мәгълүм иде. Ләкин авыл куштаннары дип йөртелгән бу бәндәләр әләкләү, чагу кебек гамәлләрен нинди нияттән чыгып эшләсәләр дә, алар телиме моны, юкмы, кешеләрне кисәтеп, аларны бәла-казаларга тарудан йолып калдылар. Шуңа күрәдер авылдашларымның бер уч ашлык өчен хөкем ителеп, төрмәләргә эләккәнен хәтерләмим.

* * *

Мең газап-михнәтләр кичеп, ач-ялангач заманнарны үтеп, тормыш һаман алга барды. Без – әтиләребездән балачага булып калган малай-кызлар – үз аякларыбызга ныграк басарга тырыштык. Чәрәк бәрәңге кәлҗемәсс ашап, кычыткан, алабута шулпаларын гына чөмерсәк тә, олылар белән бер рәткә басып, әле ныгып та җитмәгән иңнәребезгә барлык төр эшләрне дә - авырын да, жиңелен дә салып, бергә тарттык. Инде яшүсмер булып житкәннәр, фронттан кайткан әти-абыйларына барлык хуҗалык эшләрен тапшыргач, вербовщикларга ияреп, сугыш вакытында жимерелгән хәрәбәләрне торгызу, яңа завод-фабрикалар төзү өчен, читкә чыгып китте. Шулар арасында минем өч абыем да булды. 1947 елда без бары тик өчәү: әнием, мин һәм Рәисә сеңлем генә калдык. Инде кече яшьтән көтү көтеп ияләшкән, аның җаен азмы-күпме белгәнгә күрә ул елны да хуҗалыкларның бозауларын көтәргә алындым.

Җәйнең нәкъ чәллә вакыты. Мыжлап торган явыз кигәвеннәрдән кая качарга, ничек котылырга белмичә койрыкларын болгый-болгый безләгән бозаулар артыннан чабып йөри-йөри тәмам хәлдән таеп, кичкә өйгә кайтып егылам. Башны мендәргә куярга да өлгермим кебек, кай арада

төн үтеп, иртәнге сәгать биш тә җитә. Янә Хәсән абыйлар тыкырыгына бозауларны җыярга йөгерәм.

Арып-талып кайткан кичләрнең берсендә әнием:

– Улым, бабаңның хәле бик авырдан. Әллә күрешеп, хәлен белеп төшәсеңме? Үлеп китсә, бәхилләшми дә калуың бар, – диде

Мин, ярар, дип вәгъдә бирсәм дә, йокы үзенекен иткән. Иртәгесен әнием янә яныма килеп:

– Улым, тор. Бабаң үлде,– диде.

Мин корт чаккан кеше сыман сикереп урынымнан тордым. Йокы дигән нәрсәнең эзе дә калмады. Соңгы вакытта бу минем беренче мәртәбә йокыдан айнуым булгандыр. Битемне аннан-моннан су белән сыпыргаладым да, бабам янына йөгердем. Әле иртә, тан яңа гына атып килгән чак. Кояшның төгә нурлары, офыкларны алсу-кызылга манып, күк йөзенең зәңгәр киндекләренә үрли. Тирә-як тып-тын. Бөтен җан иясе йоклый кебек.

Абына-сөртенә йөгереп, өйгә килеп кердем. Анда төн уздырган әби-апалар тәсбих тартып утыралар. Мине әбием каршы алды. Ул корыган агач кебек бөрешеп калган, җыерчыклы чандыр йөзеннән хәсрәт бөркелә. Ул, күз кабакларын әкрен генә күтәрә төшеп, бабам яткан якка ымлады. Мин дә сүз әйтер хәлдә түгел идем. Телем чатнап кипкән, гүя, аңкауга ябыштырып куйганнар.

Минем сөекле бабамның гәүдәсен, аякларын кыйбла якка каратып, сәкегә салганнар. Битен каплаган ак яулыкның бер читен күтәреп, аның йөзенә бактым. Эсселе-суыклы булып китте. Бабамның һәрчак үзенә каратып торган елмаюлы йөзенә мин моңынчы күрмәгән, мин белмәгән җыерчыклар сузылган, тирән сырлар уелган. Ике каш арасындагы ярасы кысылып, сызык сыман гына булып калган.

Каты авырулар, олы хәсрәт кичергәндә җан газабы, күңел тетрәнүләре булып йөзгә бәреп чыга торган галәмәтләр бабамның күз төпләренә, ирен читләренә кунган. Аның хәрәкәтсез калган маңгай сырларына, җыерчыкларына ниндидер серләр яшеренгән. Алар кемнедер өзелеп сагынудан, кемнедер юксынудан монсуланып калганнар кебек. Чак-чак кына турсайган иреннәрс кемгәдер үпкәләгән сыман менә-менә кыймылдап китәрләр дә, күңелендәге уйларын әйтеп салырлар кебек.

...Озын гомер юлы үтеп, барлык туганнарымны, бик күп якын кешеләремне Җир-Әнкәбез куенына индердем мин. Ләкин мондый үзәк өзгеч сагышлы, тетрәндергеч юксыну сирпелеп торган йөзне бары тик әнием һәм бабам белән мәңгегә хушлашканда гына күрдем. Минем өчен иң якын булган бу кешеләр дөньялыкта яшәгәндә үзләренең эчке кичерешләрен, кайгы хәсрәтләрен, хис-тойгыларын кеше күзеннән тирәнгә яшереп саклый белгәннәр, күрәсең. Һәм бу тирән эчке кичерешләр, газап-хәсрәтләр җан белән чыгып, йөз-кыяфәтләрендә чагылып тапкандыр, мөгаен.

Кара сары (бавыр рагы) белән авырып вафат булган бабабызны дини йолаларга, гореф-гадәтләребезгә туры китереп жирләдек. Бу минем беренче мәртәбә мәет күрүем, беренче тапкыр кеше җәсәден жир куенына индерүдә катнашуым иде. Ләхет такталарының кыска һәм юка булуы хәтергә уелып калган. Бабамның авыр туфрагы жиңел, урыны Җәннәттә булсын! Шулай булыр да, иншаллаһ. Чөнки ул, әбием шикелле намаз укымаса да, Аллаһы Тәгаләнең барлыгына һәм берлегенә чын күңеленнән ышанып, аңа иман китереп яшәде. Уразаларны калдырмый тотты, сәдакасын бирде. Белгән догаларын укып гамәл кылды. Гайбәт сойләп йөрмәде. Кем булуына карамастан, Аллаһы Тәгаләнең бәндәләренә этлек, яманлык явызлык кылмады. Күңелгел изгелекта, игелек кылуда булды. Хәләл хезмәтен куеп тапкан хәләл ризыклар белән көн күрде. Аның бу күркәм сыйфатлары безгә дә күчте. Аның рухы безгә намуслы, кешелекле, шәфкатьле, миһербанлы булып яшәргә кирәклеген һәрчак искәртеп торды. Бабабыз безне үз балалары кебек якын күреп, яратып, яклап-саклап үстерде, сугышта хәбәрсез югалган әтиебез бирәсе тәрбияне бирде. Мең рәхмәт аңа.

* * *

Әтиебезне сугышка 1942 елның март башында озаттык. Искиткеч матур көн иде. Күк йөзендә бер генә болыт әсәре дә юк. Бинихая зәп-зәңгәр җәймә офыкларны бер-берсенә тоташтырган. Урман артыннан елмаеп чыгып килгән кояш, әле йорт-жирләргә, әле абзар-кура тарафына якты нурларын сибеп, җылысын бөрки – дөнья белән күрешә. Кары көрәп төшерелгән салам түбәләрдән сизелер-сизелмәс пар күтәрелә. Түбә чабуларыннан сузылган боз сөңгеләреннән леп-леп итеп тамчы тама. Юл буендагы кар челтәрләрен төрле төсләргә бизәп, шаян нурлар тибрәлә. Юка боз элпәсе каплаган ермаклардан челтер-челтер килеп, кар сулары ага башлый. Аяк астында бозланган кар шыгырдый. Язның иртәнге һавасы борыннарны кытыклап, күкрәккә үзе агылып керә сыман. Тирәюньдә сихри тынлык. Аны әтием уйнаган гармун, аңа кушылып жырлаучыларның бер тынып, бер тагын ялгапып киткән авазлары гына бозып куйгалый. Мәктәпкә барасы балалар инде китеп беткән. Ә кечерәкләре әле урыныннан торып житмәгән, шау-гөр килеп урамнарга чыкмаган. Кешеләр, фронтка китүчеләр башка урамнарны әйләнеп, авылдашлары белән хушлашкан арада, үз хужалыкларындагы мәшәкатьләр белән мәшгуль.

Урамда шомлы тынлык, хәвеф көткәндәге кебек борчулы халәт.

Фронтка китүче ир-егетләр сап-сары салам түшәлгән чанага тезләнешеп, куллары белән бер-берсен билдән кочып, түгәрәкләнеп утырганнар. Урталарында үзенең яңгыравыклы гармуны белән әтиебез дә бар. Гармунның җиз теллә-реннән ургып чыккан моң, ирләрнең сагышлы, үзәк өзгеч җан авазлары белән аралашып, күңел түрләренә үтеп керә. Кайгы-хәсрәтен дә, шатлык-сөенечен дә бергә кичергән ир-егетләр белән күрешеп саубуллашырга дип, олысы-кечесе капка төпләренә чыгып баскан. Әбиләр, апа-әниләр мөлдерәп-мөлдерәп аккан күз яшьләрен яулык очы белән сөртә-сөртә: «Исән-имин илләргә әйләнеп кайтырга насыйп булсын, балакайларым!»– дип, изге теләкләрен теләп каршы алалар, кулларын болгап, хәер-догаларын биреп озатып калалар. Аллаһы Тәгаләдән үзенең яраткан адәм балаларын рәхмәт-шәфкатеннән ташламавын ялварып сорыйлар. Гадәттә арба, чана артыннан кирәксә кирәкмәсә дә өрә-өрә чабып барырга күнеккән маэмайлар да бүген чанада утырганнарны койрыкларын болгый-болгый каршы алып, башларын түбән игән хәлдә тын гына озатып калдылар. Әйтерсең, алар да бу көндә тавыш куптару ярамаганын сизенәләр иде.

Никрутлар югарочны әйләнеп, тыкрыктан күрше урамга борылдылар. Фронтка китүчеләрне инде күп мәртәбәләр тартып йөргән аклы-каралы айгыр да юл читенә чыгып баскан, әлегә өйләрендә калып торган ир-атларның яннарына килеп, үзеннән-үзе туктап кала. Балачактан бергә үйнап үскән, бергә кызлар озаткан ир-егетләр бер-берсен кочып күкрәкләренә кысалар. Күңел түрләреннән ургып чыккан күз яшьләрен яшереп, йөзләрен читкә боралар. Электә

булган ызгыш-талашлы вакыйгаларны гафу итешәләр, бәхиллек сүзләре әйтешәләр.

Кем өчендер бу, бәлкем, соңгы күрешү, дус-ишләренең тавышын соң мәртәбә ишетүдер. Язмышлардан узмышлар юк. Бәхил булыгыз, авылдашлар, туган-тумача, кардәш-кордашлар. Безгә рәнҗеп калмагыз! Илдә яшәп калганнардан үч-ачулар алмагыз!

Мең фронтка китүчеләрнең аты безнең капка төбенә килеп туктады. Монда һичшиксез килми калмаячакларын төгәен белгән күршe-күләң урамны тутырып, әйләнә-тирә-безне чолгап алган. Хатын-кызлар, читкәрәк басып, үзара сүз алышып, шыпырт кына елаша. Ир-атлар тамак төбенә утырган төерләрен көч-хәл белән йотып, куллар кысыша. Һәркайсының теләндә бер генә сүз, бер генә теләк:

– Исән-сау әйләнеп кайтыгыз!

Олырак яшьтәге агайлар китүчеләрнең гаиләләренә күзколак булырга, кулларыннан килгәнчә ярдәм итәргә вәгъдә бирешәләр. Бүген жаннарның ачык, күңелләрнең сафланып калган мәле. Кылынган үчлек-этлекләр, гөнаһ-ялгышлар күңелдә таш булып йөрмәсен, үпкә-ачулар инҗәрне басып тормасын. Теге дөньяда риза-бәхиллек сорау өчен бер-беребезне эзләп, тилмереп йөрерлек булмасын.

– Җәмәгать!– ди югары очның Хөснулла карт.– Хәер-догаларыбызны Аллаһы Тәгаләгә саждә кылып беркетик.

Ирләр рәт-рәт булып Хөснулла картның артына тезелешеп бастылар. Ул намазлыгын кар өстенә җәеп, укырга кереште. Берәүләр аның урнәгендә сәждәгә китсәләр, икенчеләр – билләрен бөгә төшү белән канәгатьләнделәр. Хөснулла карт: «Аллаһу әкбәр!» – дип, намазын тәмамлады. Ул тезләнгән хәлдә калып, җыендагы барлык кешенең күңелен дулкынландырып торган теләкләрен тезеп китте. Аларның һәммәсе дә ихлас күңелдән әйтелгән изге теләкләр бу-

лып, Аллаһы Тәгаләдән бу кайгы, үлем афәте китергән фажигале сугышның тиз көннәрдә тәмамлануын, ир-егетләрнең өйләренә исән-сау әйләнеп кайтуын сораудан гыйбарәт иде.

Ул янә Аллаһу әкбәр әйтеп, кыямга басты һәм үзенең яңгыравыклы көр тавышы белән тәкъбир әйтә башлады:

– Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр. Лә иләһә илләл-лаһу валлаһу әкбәр. Валлаһу әкбәр вә лилләһил хәмдү...

Ирләрнең ана кушылып бертавыштан әйтелгән тәкъбир авазлары авыл урамнарында һәр тарафтан кайтаваз булып яңгырады:

– Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр...

Бу илаһи авазларны тыңлап, кешеләрнең төннәре чемердәп китте, күңелләре тетрәнде, эчтән ниндидер тылсымлы көч бәреп чыкты. Алар барган җирләреннән туктап калдылар. Үзләре дә сизмәстән, мөлдерәп аккан күз яшьләрен сөртә-сөртә ана кушылып: «Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр», – дип кабатладылар.

Әтиебез гармунын алып чанадан төште. Барыбыз да өйгә кердек. Әби белән бабай да иярде. Әнинең ризыклары әзер иде. Әтинең оста куллары ясаган өстәл янына җыелдык. Берара берәү дә сүз әйтергә кыймый утырды. Сүзне әти үзе башлады.

– Минем кая китәсем барыгызга да мәгълүм. Тик Хак Тәгаләнең ни язганы гына мәгълүм түгел. Әйтер сүзем шул: тормыш булгач, төрле чагы була. Әнкәй, абзый, хатыным, кадерле балаларым, әгәр сезне урынсызга рәнҗеткән чакларым булса, зинһар, кичерә күрегез. Мин аларны үчлектән, ачудан эшләмәдем. Минем берегезгә дә үпкәм дә, дәгъвам да юк. Ходай сезне рәхим-шәфкатеннән ташламасын.

Аннары ул сүзен әни ягына карап дәвам иттерде:

– Хатын, синең белән без егерме бер сл гомер иттек. Өлешемә тигән көмешем булдың. Янымда син булганга мин һәрчак шатланып, үземне бик бәхетле тоеп, шөкерана кылып яшәдем. Сиңа Аллаһының рәхмәте яусын, ике дөньяның да рәхәте насыйп булсын...

Әтиебез үзеннән күзен алмаган әниебезгә тутырып-тутырып карады. Менә аларның күз карашлары кабат очраштылар. Никадәр ягымлылык, никадәр мәгънә бар иде аларда! Бу карашларда ике йөрәкнең бер-берсенә мәңгелек мәхәббәте чагылып үтте. Аерылышуның моңсу сагышы да бар иде бу карашларда.

Ул арада өйгә Рәхимҗан абый кереп: «Барысы да җыелып бетте, кузгалырга вакыт», – диде. Без дога кылып, юл ризыклары һәм банка кирәк-ярак салынган биштәрләрне күтәрешеп урамга чыктык. Кузгалыр алдыннан әти бабай янына килеп:

– Абзый, балаларны ташлама, бөтен ышанычым синдә, – диде.

– Габдуллажан улым, алар синекеләр булган шикелле үк, минекеләр дә. Гомерем барынча тырышырмын.

– Рәхмәт, абзый.

Урамда халык тагы да арта төшкән иде. Китүчеләрне гаиләсе, туган-тумачасы урап алган. Һәркемнең ин мөкатдәс сүзен әйтеп каласы килә. Кем белә, бәлкем бу соңгы күрешүләрдер. Һәркайсының хәсрәте үзенә җиткән. Хатын-кыз гына түгел, ирләр дә иркесездән бәреп чыккан күз яшен тыя алмыйча, йә йөзләрен читкә борырга, йә күз карашларын аска таба юнәлтергә мәҗбүрләр.

Әтиебез дә әниебезнең кулларын ике учына алып: «Хуш, җанкисәгем, сине бик сагынырмын инде», – диде. Аннан безне – дүрт улын, бер кызын берәм-берәм кочагына алып күкрәгенә кысты һәм һәрберебезгә үзенең теләкләрен теләде.

— Кара аны, әнисезне тыңлагыз! Яхшы, игелекле кешеләр булып үсегез. Кешеләр сезне мактап телгә алырлык булсын. Фәрит улым, син йортта олы кеше булып каласың. Нәниләрнең язмышы синең дә кулыңда, аларга яхшы яктан үрнәк бул! — диде.

Фәрит абый, ярар, дигән сыман башын кагып, сүзсез генә тыңлап торды.

Ул арада әби килеп әтине кочып алды. Башын аның иненә төртеп елап та жибәрде.

— Улым, жаным, бердәнберем минем! — дия-дия үкседе ул.

Без дә әтинең аякларына килеп сарылдык.

— Кузгалырга вакыт! — диде кемдер.

Фронтка китүчеләр якыннарының кочакларыннан аерылып, чанага утырдылар. Шуны гына көтеп торган айгыр җәһәт кенә кузгалып та китте.

— Бохил булыгыз, туганнар, сөйгән яр, авылдашлар!..

Бу әтиебезне соңгы кат күрүебез булды. Урта буйлы, чандыр гәүдәле, уңган-булган әтиебез үзенең буй-сынын, тоскыяфәген, йөз чалымнарын, сәләт-осталыгын балаларына өләшеп, мәңгелеккә китеп барды.

Әтине тагын ике мәртәбә күрү насыйп булды әнигә.

Сугыш бетеп озак еллар үтсә дә, әле дә телләрдән төшмәгән, матбугат битләрендә кайнар бәхәсләргә сәбәпче булган Суслонгер дигән жирлә хәрби әзерлек үтәргә жибәрәләр әтине. Белмим, монда аларны нәрсәгә өйрәткәннәрдер, әмма ачлыктан чиксез газапка дучар ителгәннәрен әйтеп тә, сөйләп тә бетерерлек булмаган. Әни ике тапкыр әтигә азык-төлек, кием-салым илтә барды. Ул анда үз күзләре белән күргән кәгәчкыч хәлләрне слый-елый сөйли иде. Ач-ялангач хәлсез солдатлар көч-хәл белән тирә-як авылларга барып, чүплектә казынып, кар-бозга укмашып кап бөрәнге кабыкларын пешереп ашаганнар. Юкә кайрысын кимерергә мәжбүр булганнар. Сбордагы солдатларның күбесе фронтка да барып житә алмыйча ачтан үлгән.

— Шулай берчак,— дип сөйләде әни, — берничә хатын ирләре янына ризык төяп килгәннәр. Болар белән күрешергә чыккан ирләре, хәлләре китеп, тәгәри башлаганнар. Үрмәкчедән күрмәкче дигәндәй, хатыннар да, капчык-биштәрләрен читкә куеп, ирләренә таба тәгәрәшеп киткәннәр. Хатыннар ирләренә таба тәгәри икән, ә ирләре — капчык-биштәрләргә таба.

Ачлык-ялангачлыктан шулкадәр интеккән, газапмихнәтләргә тарыган, беткә батып төмам хәлдән тайган солдатларны Волхов фронтына илтеп тыгалар. Әти сугышка керүенең беренче көннәрендә үк хәбәрсез югала. Хәер, аның белән бер чанага утырып киткән авылдашларымның берсенә дә әйләнеп кайтырга насыйп булмады. Шәһит киткән барча якташларның авыр туфраклары жиңел, урыннары Жәннәттә булсын!

* * *

1950 елның башында Нәжип абыйның фидакарь тырышлыгы белән һәм әниемнең көне-төне түгәләр артыннан йөрүе нәтиҗәсендә без Казанга күчеп килә алдык.

Сугыш елларын ачлы-туклы килеш бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр баш күтәрми эшләп үткәргән, аннан соңгы елларда кайгы-хәсрәт, мең төрле борчулар кичергән, йөрәк авыруы, тагын әллә никадәр хастасы булган 46 яшьлек әниебезнең, шәһәрнең завод-фабрикаларына эшкә керен, күз күрмәгән, колак ишетмәгән яңа һөнәрләр үзләштереп, ике-өч сменалы эшләргә йөреп маташасы килмәде. Бәлкем булдыра да алмас иде. Чөнки хокүмәт агай аның

сыгарга мөмкин булган көч-куәтен сыгып бетергән иде шул. Калдык постыгы тавыклар да чүпләп бетерә алмастай өй эшләренә таман гына калган иде. Өч улын иртән уятып, ашатып-эчертеп, вакытында эшкә озатып җибәрү, безнең өс-башларыбызны юып-карап тору кебек мәшәкатьләре дә башыннан ашкан. Өстәвенә бакча эшләре дә бар иде әле. Ләкин аның кул кушырып, абыйлар кайтарып бирәсе акчаны кәтеп утырасы килмәде. Гомер агышында туплаган бай тормыш тәҗрибәсе, көннәрдән бер көнне, моңынчы үзе дә сиземләп кенә белә торган сәләтләрен ачуга сәбәп булды. Бер очраклы хәлдән соң янына баштарак тирә-юнь кешеләре, аннары республиканың ерак районнарыннан ук килә башладылар. Табибларга күренеп, хастаханәләрдә дәвалаиып та, чирләреннән котыла алмаган, һаман да авыртудан интеккән кешеләр аның даими пациентлары булдылар. Ул авыру кеше белән икәүдән-икәү генә калып, аның шешеп чыккан әгъзасының әйләнә-тирәсен нәфис бармаклары белән капшап, сыйпап-сыпыргалап алгалар. Аның гомер буе сәнәк, көрәк тотып та нәзакатьле булып калган куллары шулкадәр сизгер ки, рентген күзеннән качып-яшеренеп калган тайпылыш-үзгәрешләрне дә тиз һәм төгәл тоя иде. Гадәттә, сынган сөякләре дөрес ялганмаган яисә тайганары үз урынына кереп утырмаган булып чыга. Сынган һәм дөрес ялганмаган очракларда ул үзенең киңәшләрен генә бирә алды. Әгәр теге, йә бу җире каегып, кичектерми килсә, андыйларны «эһ» дигәнче төзәтеп җибөрде. Әгәр инде вакыт күп узган булса, авырткан урынның әйләнә-тирәсен атланмай белән сак кына уып, оешкан канны әкренләп тарата башлар. Әни бу эшне «тәнне кыздыру» дип атый иде. Шул рәвешчә уа-уа имгәнгән урынның үзәгенә якыплаша, «аны кыздыра» башлый. Шеп йомшарып, организмның әзер булуын сизгәч, ипләп кенә тарта. Ниһаять, таеп чыккан сөяк

шырт итеп урынына кереп утыра. Әлбәттә, бу зур осталык һәм төгәллек белән бергә тәвәккәллек тә таләп итә торган хезмәт. Кайчакта әнигә «кыздыру»ны кат-кат кабатларга туры килә торган иде. Тик аның эшен җиренә җиткермичә ярты юлда туктап калган чагы булмады. Мондый игеклекләрнең күбесен, бигрәк тә карт-карчыкларга рәхмәткә эшләде ул, әле чәен күеп, сыйлап та җибәрә иде.

Әниебез сөлек салуда ла үзен оста белгеч итеп күрсәтте. Аны әле монда, әле тегендә чакырып кына тордылар. Пыяла банкада йөзеп йөргән сөлекләре һәрчак әзер иде. Ул аларның суларын вакытында алыштырып, бөтен шартын китереп тәрбия итте. Еш кына үзенә дә сала иде. Бозык канны суырган сөлекләрен вакытында «сыгып» куярга да онытмады. Балага уза алмаган яшь киленнәргә ана булу бәхетен бирде. Бик күп бәбиләрнең кендек әбисе булды. Дөньядан кичкән дус-ишләренең, туган-тумачаларның юу, көфинләү кебек хөстәрләрен күреп, соңгы юлга озатты.

Әниебезнең иң зур мактауга лаек эш-гамәле, аңа мәртәбә-дәрәҗә алып килгәне — изге Коръәнебезне моңлы, дөрес итеп укый һәм укыганнарын тәфсилләп аңлата белүе булды. Ул Хак Тәгаләнең барлыгына һәм берлегенә бернинди икеләнүсез, җаны-тәне белән, фанатик рәвештә ышанып, аңа ихлас күңеленнән гыйбадәт кылды. «Аллаһының барлыгына ышанмыйм», диючеләргә ул: «Хак Тәгалә синең ышануышанмавыңа һич тә мохтаж түгел. Син аның ышанычын аклауга мохтаж», — дия торган иде.

Ул халкыбызның дини йолаларын, гореф-гадәтләрен яхшы белде. Коръән уку мәҗлесләренә һәрчак хөрмәтле абыстай сыйфатында чакырулы иде. Ураза һәм мәүлит айларында аның вакыты минутына кадәр язылып куелган булыр иде. Аны бер мәҗлестән икенчесенә машинага утыртып алып китәләр, мең рәхмәтләр әйтеп, ихтирам белән

кайтарып та куялар иде. Чонки егерменче гасырның икенче яртысыннан алып, туксанынчы еллар башына кадәр мондый мәҗлесләрдә Коръән укырга җөрьәт иткән абыстайлар бик аз булды. Укый белгәннәренә кыюлык, тәвәкәллек җитенкерәмәде. МВД, КГБ дигән дәһшәтле органнардан куркып, читтә торуны кулай күрделәр. Ул каһәр төшкән органнар әниемне дә күп тапкырлар бимазалады. Чакыртып та, өйгә килеп тә кисәтүләр ясадылар, төрмә белән янадылар, аңлатмалар яздырып, Коръән уку мәҗлесләренә йөрүдән тыймакчы булдылар. Ләкин ул мең еллар буе буыннан-буынга күчеп килгән күркәм гореф-гадәтләребез турында сойләп, аларны үтәү әби-бабаларыбыз әйтеп калдырган мокатдәс аманәт икәнен искәртүдән туктамады.

Һәр кешедә ущай сыйфатлар белән берәәттән тискәреләре дә булмый калмаган кебек, әниемнең холкында да җитешсезлекләр юк түгел иде. Ләкин хикмәт бу сыйфатларның кемдә күпме микъдарда булуында. Шушы төшенчәләр аның чын йөзен билгели. Тормыш бит ул яхшы белән яманның бертуктаусыз көрәшеннән гыйбарәт.

Берәүләрдән оят, намус дигән сыйфатлар бөтенләй качкан була, андыйларның зәһәре чыраена бәреп чыга, күз карашлары кешеләрне өтеп алгандай итә. Бу иш бәндәләр башкаларга явызлык кылудан рәхәтлек кичереп, яманлык кылудан ләззәт алып көн күрәләр. Әйе, әйе, яшәмиләр, фәкать көн күрәләр. Үзләре дә яшәми, башкаларга да рәтләп яшәргә ирек бирми.

Икенче берәүнең яшәү мәгънәсе — кешеләргә игелекле булуда, аларга мөмкин кадәр изгелек кылуда. Андый кешенең йөзендә иман нуры балкып торыр. Бу олы җанлы, кин күңелле, мәрхәмәтле, шәфкатьле кешеләр, якты дөньяга юкка гына килмәгәннәрен белеп, башкаларга бәхет-сәгадәт

бүләк итеп, шатлык-куанычлар китереп, Аллаһының чиксез рәхмәтен тоеп яшиләр.

Әнием әнә шундыйларның берсе иде. Шушы изге гамәлләре бөрабәренә Хак Тәгалә аны илаһи рәхмәтеннән ташламады, аңа көч-куәт иңдереп, илһам биреп торды. Шуңа да ул партия басымына да, МВД органнарының туктаусыз янап торуына да түзде. Раббыбыздан сабырлык сорады. Чонки аның холык-фигыленә халкыбызның күркәм сыйфатлары тупланган иде. Кешеләргә файдалы булу теләге ташып торды. Инде якты дөнья белән хушлашырга җитешкән чаклары да аз булмады аның. Ниндидер тылсым аны яңадан аякка бастырды, дәрт өрде. Ул тырышатырыша сихәтләнү чарасын тапты. Яшәүнең никадәр кадерле булуын, аның өчен ничек көрәшергә кирәклеген күрсәтеп, үрнәк гомер итеп, сиксән атлы яшен тутырып якты дөньядан китеп барды. Безгә хәер-догасын, риза-бәхилләген биреп, мең-мең рәхмәтләр әйтеп калдырды.

Әниебезне димләп тә, сорап та караучылар аз булмады. Алар арасында дин әһелләре дә, хөрмәт-ихтирамга лаек башка затлар да бар иде. Ләкин ул берәүгә дә ризалыгын бирмәде, әтиебезгә мөнгс тугрылыклы булып калды, безне кемнеңдер куенына алыштырмады.

Әнинең тагын бер гадәте бар иде. Ул бәрелеп-сугылып, иртәгесе көн өчен хафага төшеп яшәмәде. «Көн биргәнгә юнь бирер», — дип әйтә иде. Шуңадыр ул искиткеч юмарт булды. Соңгы кисәк икмәген дә мохтаҗларның кулына тоттырды, әҗәткә кергәннәрнең берсен дә буш кул белән борып чыгармады. Басынкы холыклы, үтә итагатьлс бу татар хатыны ялганны, алдашуны, яла ягып, гайбәт сатып йөрүче икейөзле бәндәләрне һич тә яратмады.

Аллага шөкер, аның бу күркәм сыйфатлары безгә — балаларына да мирас булып күчте.

АВЫЛНЫ КАЗЛАР УЯТТЫ

Сүз дә юк, җир сорү, иген игү — изге һәм дәрәҗәле хезмәт. Үзенең җаваплылыгы, авырлыгы ягыннан көтүче эше дә алар белән бер үк дәрәҗәдә ихтирамга лаек. Моның шулай икәнлеген иңенә чыбыркысын асып иртә таңнан кичкә кадәр кыр-болыннарда көзге яңгырларда тубыктан пычрак ярып йөргән көтүче үзе генә беләдер. Хәтта минем кебек каз көткән малайлар да...

Каз ул сыер, сарык, кәҗә кебек, чыбыркы-чыбыгыңны бик үк санга сугучылардан түгел. Алар «как-как-как» дип, башларын иген кырына таба борырга гына торалар. Елга буенда, аланнарда чемченеп, күлләрдә су коенып тыныч кына ятарга риза түгел бу озын муеннар.

Казларның иген кырына кергәнен басу каравылчысы Сәлахи абый күрсә, беттем диген. Озын, шома таягы белән муен тамырына кундырырга да күп сорап тормас. Һай, усал иде соң каклаган кебек чандыр, озын буйлы бу кеше. Без, малайларның күз яшьләрен күп түктерде ул үз гомерендә. Никадәр аналар бер уч арыш бөртеге өчен хөкемгә тартылды, балалары ятим калды. Әгәр кырда өлгереп килгән арыш-бодайларны башкалар кебек учларында уып ашасалар, бик күп сабыйлар, бәлки, ачтан шешенеп үлмәгән дә булырлар иде. Бар иде заманалар, бар иде... Шөкер, уздылар.

Колхоз идарәсе игеннәрне урып, кибәннәргә куйгач кына коелып калган башакларны казлардан чүпләтергә рөхсәт

бирә иде. Бу инде – көз көннәре җитеп, бәпкәләр зурайган чак. Алар һавада очып барган кардәшләре – кыр казларына иярмәкче булып, очарга талпыналар. Кайбер оялар хәйран еракка очып та киткәлиләр. Нишләмәк кирәк, артларыннан йөгерәсең, ялан аякларыңны без кебек тырпаеп торган камыллар каната. Ул чакта кияргә чабатасы да юк иде бит аның.

Бервакыт көтүне урып-җыеп алынган ясмык җиренә алып мендек. Төне буе ач яткан казларыбызның тыпырчы да чыкмый. Умыралар гына ясмыкны! Ашый торгач, берзаман боларның томшыклары ачылды, күзләре акайды. Сусаганнар икән мескеннәр. Ава-түнә елгага таба йөгерделәр. Гөнаһ шомлыгына каршы диимме, шунда берничәсе текә ярдан мәтәлде бит. Без Көрим белән абайлап алганчы, өчесе жан тәслим кылып та өлгергән. Күмдек инде боларны ярның яшерен бер җиренә.

Һай, никадәр тавыш-гауга купты ул бәбкәләр аркасында безнең капка төбендә! Тегелә-болай итә күрмәсеннәр тагын, дип, әнием мине лапаска ук ябып куйды. Төлке буды дип ялганлап карасак та, бәбкәләрнең бәясен түләтергә дигән карар чыгардылар.

Хак Тәгалә барысын да күреп тора, барысын да гадел хөкем итә шул. Икенче көнне казларны зират буендагы басуга җибәрдек. Әбиләр чуагының искиткеч матур бер иртәсе иде. Кояш, зират өстеннән күтәрелеп, мәрхәмәтле җылысын кыр-болыннарга бөрки. Һава тын һәм саф. Кайдадыр тургай сайрый. Без Кәрим белән юл чатына басып, җирдә калган орлыкларны кинәнеп чүпләүче казларыбызны күзәтәбез. Башларын да күтәрмиләр, ачыккannнар кошкайлар!

Көтмәгәндә давыл, зилзилә купты диярсең. Казлар моңнычы без ишетмәгән ачы кыргый тавышлар чыгарып

кычкыра башладылар. Ул да булмады, алдагы рәтләре диңгез дулкыннары кебек умырылып, безгә таба ябырылды. Без моның нәрсә икәнен аңларга тырышкан арада, ниндидер соры җәнлек күзгә чалынып узды. Мин аны яраткан эте-без Сарбай дип белеп, таягымны селти-селти куып киттем, казларны шулай куркытып йөргән өчен кирәген бирергә исәп бар иде.

Без кара-каршы очраштык. Күзләрен кан баскан «Сарбай», юлымда торма әле, дигәндәй, янымнан томырылып чабып үтте. Мин аның арт аягы аксак икәнен генә шәйләп калдым. Ул көтүне урап әйләнде дә, бер-берсенә сыланышып беткән казларның өстенә сикереп, берәм-берәм буа да башлады. Муеннарыннан чәйни дә ата, чәйни дә ата. Ул моны шулкадәр тиз һәм оста башкара ки, каз башларының берсе артыннан икенчесе очып кына тора. Әйтерсең ул алар белән уйный-шаяра иде.

Баксаң, бөтен тирә-якка дәм салып торучы аксак бүре шул үзе икән. Аның берничә мәртәбә көтүләргә ташланып, кәҗә-сарыкларны буып киткәнен, кешеләргә зур зыян китергәнен ишеткән бар иде. Мин куркуымнан казларны да узып, авылга элдерттем. Үземнән дә биек зират коймасын бер сикерүдә очып үтеп, кабер ташларына абына-сөртенә йөгердем дә йөгердем. Бүре авызыннан котылып калган казлар очып килеп, шап-шоп итеп зират коймасына бәрелделәр. Тыным бетеп, авылга керә торган юл читенә килеп аудым. Никадәр кычкырырга теләсәм дә, тавышым чыкмый. Ниһаять, бераз тын ала төшкәч:

– Кә-кә-кәрим! – дип көч-хәл белән аваз салдым.

Бөтен тирә-якны ачыргаланып кычкырган каз тавышлары басып китте. Аларның кайсылары очып, кайсылары ашыга-чаба урамнарга кереп тулды. Көтүнең бер өлеше авылда, икенче өлеше – басуга таралды. Күпмесе буылып таш-

ланган, ничәсе зират коймасына бәрелеп имгәнгән? – әлегә билгеле түгел.

Бу тавышка авыл аякка басты. Кешеләр нәрсә булганын да белми, анда йөгерә, монда чабыша. Барысы да үз казларын барлый. Менә алар көтүне җыйнарга азапланган Кәримне урап алдылар. Китте кычкырыш, китте талаш. Кешеләрнең акыру-бакырулары, каз тавышлары белән буталып, тоташ улауга әверелде. Казлар бер-берсен эзләп аваз салсалар, кешеләр зәһәрле укларга тиң җан өшеткеч сүзләре белән бер-берсенән ераклаштылар, авызлары нәрсә әйткәнен колаклары ишетмәде.

– Без казларыбызны Хәбибҗамал белән Фагыйләгә ышанып тапшырдык. Кайда алар? Ник үзләре көтми көтүне? Бу малай-шалай нинди көтүче булсын ди? Аларның үзләрен көтәргә кирәк бит әле!

– Кичә дә өч казны харап иттеләр...

– Балаларымның өс-башларына алырмын дип кенә асрый идем...

– Минем дә бөтен омтсм шул казларда иде, насыйп булмаган, күрәсең...

Бигрәк тә ирдәүкә Лениза апа дулады:

– Бу эшне болай гына калдырырга ярамый, имза җыеп, судка бирергә кирәк!

– Түләсеннәр казларның бәясен, алар безнең карап торган малларыбыз иде бит!...

Халык шулкадәр кызды ки, без Кәрим белән каршыдагы ташландык йортның ишегалдындагы кычытканлыкка кереп яшерендек.

Кәримгә унөч, мина унбер яшь, нәрсә эшли ала идек соң без? Әниләрнең өй эшләре дә җитәрлек, юасы, ямыйсы бар. Юк ризыкларны бар итеп ашарга да хәстәрләргә кирәк. Җитмәсә әни йөрәк авырулы.

Ул арада трантасына утырып колхоз рәисе Мансур абый да килеп җитте.

– Җәмәгать, туктагыз, шауламагыз! – дип тынычландырды ул халыкны. – Бу хәлләргә мин үзем шаһит, үз күзләрем белән күрдем. Районга барышым иде. Көтүгә тиге явыз аксак бүре ташланды. Монда малайларның бернинли дә гаебе юк. Алар урынында, әнә разведчик героебыз (Мансур абый күкрәгә орден, медаль белән тулы кешегә күрсәтте) Габделхәй булса да, берни дә эшли алмас иде. Һөҗүм күз ачып йомганчы булды. Бер казны бүре сыртына күтәреп китте, буылып ташланганнары кырда ята булыр.

Халык дәррәү килеп басуга таба кузгалды.

Бу хәлләр кичә ясмык ашап, ярдан мәтәлеп үлгән бәбкәләрне дә онытгырды. Аларның хуҗалары казларының исән калганлыгын күреп, шөкерана кылыптылар. Бераздан бүре буган казларның бәясен түләтү дигән гауга да тынды. Бу хакта бүтән беркемнен дә сүз кузгатканы булмады.

Гыйбрәте шул: сабырлыгың жуеп, нәни генә бер казадан дөнья кубарсаң, Хак Тәгалә, зуррак каза китереп, акылга утыртыр.

БАТЫР ШАЙТАН

Сугыш вакытында һәм сугыштан соңгы елларда бүреләр шулкадәр үрчегән иде ки, өерләре белән йөреп, кешеләргә бик күп бәла-каза китерделәр. Кыш көннәрендә түбә саламын актарып мал абзарларына үтеп керделәр, иртән сафәрчеләрнең каршыларына чыгып утырдылар. Һөҗүм иткән очраклар да булгалады. Таң алдыннан сузып-сузып улаган бүре тавышы күңелгә шом салып, якында гына куркыныч барын искәртеп торды. Фәлән кешеләрнең кәҗә-сарыкларын буып киткәннәр, төгән авылның көтүенә ташланганнар, дигән хәвефле хәбәрләр әледән-әле ишетелә иде.

Апрель урталарында мине колхоз идарәсенә дәштеләр. Моңа кадәр минем белән бергә каз һәм бозау көткән Кәрим дустым анда иде инде. Тәжрибәгез бар, көтүлек җирләрне беләсез, дип, безгә янә авыл көтүен көтәргә куштылар. Ни генә әйтсәң дә, колхозда бушка эшләп йөрү түгел инде бу, бозавыңны көтүгә чыгаргансың икән, кем әйтмешли, күңеленне киң тот: килешенгән хакны чыгарып сал! Димәк, үзең дә, гаиләң дә ач-ялангач булмый дигән сүз. Үз авызларыннан өзеп булса да, бирәчәген бирә иде ул чор кешеләре. Тагын шунысы да мөһим: көтүдә син үзеңә үзең хуҗа. Берәү дә, тегене тегеләй ит, монысын болай ит, дип өстеңдә тормый. Иртәнге салкынчада бозауларны бер кат чыклы үлән белән сыйлагач, көтүне күләгәгә куасың. Гадәттә без аларны аргы яктагы ташландык фермада ял иттерә идек. Өйгә кайтып килергә дә якын – бакча башында гына. Тик шу-

ныcы бар: син һәрвакыт авылдашларның күз алдында. Ә кеше дигәнең гаеп эзләргә генә тора. «Нигә бозауларны ашатмыйча ябып яткырасыз?»— дип теңкәгә тияләр иде. Ашатып кара син аларны көндезге челләдә!

Әлбәттә инде, тамак турында да онытмыйсың. Табында — өлеге дә баягы дулкынланып тибрөнгән иген басулары сые. Монда син хужа! Ә хуҗа кешегә акмаса да, тамгалый ул! Әйтик, авыл малайларының берсе дә сәбәпсез-нисез борчак, арыш, бодай басулары тирәсендә йөрми. Ә көтүче йөри. Аның эш урыны шунда. Бу инде басу ризыкларыннан авыз итәргә мөмкинлек бирә дигән сүз. Борчакның әле орлыгы җитешкәнче үк без аның сусыл кузакларын чәйнәп суыра идек. Бераз өлгерә башлагач куырып ашауларны әйтеп тә торасы юк инде. Арыш-бодайның сөтле яралгыларын берәмләп чүплибез, өлгерә төшкәч, учта уып ашыйбыз. Һай, ул орлыкларның тәмлелеге! Куе сөт белән ипи ашаган кебек буласың. Аларның хуш исе әле дә хәтердә. Кузгалак, кукы һәм башка ашарга яраклы үләннәр дә табыныбызның түрендә иде. Кыскасы, көтүче — кулай кәсеп иде ул елларда, ул безне ач үлемнән саклап алып калды.

Һәр нәрсәнең пары булган кебек, бер рәхәтнең бер михнәте дә булмый калмый. Безнең ой күршесендә генә ятимнәр йорты эшли иде. Аның директоры булып тәбәнәк буйлы, иңбашлары өскә калкыбрак торган, башын шул калкулыкка кырын салып йөрүче Хан абый бар иде. Ул һәрвакыт чиста-пөхтә киенгән булыр, галстугына кадәр зәвык белән бәйләнеп, пинжәгенә иш килеп торыр иде. Авылда шулай матур итеп киенеп йөрүче бердәнбер кеше ул булгандыр. Аларның йорты да урам башындагы зур куышы бина иде. Хатыны Наһар апа колхоз эшенә катнашмады, авыл тормышында да гаме булмады, аның үз дөньясы дөнья иде. Аларның бозавы да безнең көтүгә йөрде. Ул башкалардан

гәүдәсенең зурлыгы, көрлеге белән аерылып торды. Көтүчеләре без булсак, ул — шул көтүнең башлыгы, бөтен шуклыкларны оештыручы иде. Шуңа күрә аңа «Шайтан» дигән затлы кушамат тактык. Әгәр шушы Шайтан эссе көннәрдә койрыгын чәнчеп көтүне бер әйләнеп чыксамы, беттең! Сыйраклары тизәккә катып беткән, арт саннарын кочкомочкә сойрәп йөрүче йолкыш бозауларга кадәр җанланып, койракларын сыртка сала башлаячак. Күзләрен акайтып кая чапканнарын да белмәгән бу мәхлукларны машина белән дә куып җитеп булмас иде. Сортланып егылганчы чабачаклар алар. Шуңа да кигәвенле эссе көннәрдә без Шайтаннан күзебезне алмыйбыз. Ул башын чөеп, койрыгын сыртына күтәрә башлауга, бозауларны куа-кузгатырга тотынабыз. Шулай иткәндә кигәвеннәр дә тузгый, булачак бунт та сүрелә.

Көннәрдән беркөнне бозаулар эсседән качып, яр астындагы күләгәгә сыендылар. Без Кәрим белән ашарга хәстәрли башладык. Учакта күмерләр өлгереп, бәрәңге төгәрәтергә генә торганда, Сарбай ярсый-ярсый өергә тотынды. Ул арада Рәхимҗаннарның бер читтәрәк утлап йөргән бозауларына таба ниндидер соры җанварның умырылып килүен күреп алдык. Нәкъ шул мизгелдә, менә инде ярты гасырдан артык вакыт үтеп тә, мин әле һаман аңдап җиткерә алмаган гаҗәеп бер хәл булды. Шайтан тыныч кына яткан җиреннән җәһәт сикереп торды да, чатыр чабып, теге жанварга таба ташланды. Башын бераз аска ия төшеп, әле яңа гына борнап килгән яшь мөгезләрен тырпайтып, арт аякларын ныгытып җиргә терәгән хәлдә киерелеп, тегенең алдына килеп тә басты. Мондый кыюлыкны көтмәгән эткыч бер мәлгә югалып калды. Ул, бөтен гәүдәсе белән тыелып, туктарга тырышты, ләкин булдыра адмый, мәгәлән үк китте. Шуны гына көткәндәй, Сарбай аның өстенә си-

керде. Без йөгереп килеп житкәндә Сарбайның авызында йолкынган бүре йоннары гына калган иде. Ерткыч, ук кебек атылып, арыш басуына кереп югалды.

Бу хәлне ишеткәч, Наһар апа Шайтанны көтүгә чыгармас булды. Ул атна-ун көн абзарда ябылуда ятты. Ләкин көне-төне акыруына түзә алмагач, көтүгә китерергә булдылар. Шайтан шат иде. Ул күптәнге дус бозаулары белән иснәшеп күреште. Көтүне әйләнеп чыгып, барысына да сәлам бирде.

Көннәр бер-бер артлы уза торды, җиргә көз инде. Бозаулар да үсеп, көрәеп китте. Сыйраклары тизәккә катканнары да «кеше» булды. Без дә рәхәткә чыктык. Учак ягып борчак куырабыз, ботказын пешерәбез. Тамак тук, өс бөтен!

Гадәти бер көн иде ул. Көтүне туплауга куып керткәч, без, гадәтебезчә, үз җаебызны җайлый башладык. Җыйган башакларны учларыбызда уып, җилдә җилгәрдек тә, ботка пешерергә тотындык. Көз җитүгә карамастан, кузгалакның да иге-чиге юк. Ул әле дә ямь-яшел. Шулар янына тагын башка үләннәр дә өстәп, кәстрүлне ялкын өстенә элдек. Майсыз булса да, көмештәй саф чишмә суында пешкән ботка үзе дә телләрне йотарлык була бит ул!

Бер кат ашап-эчкәч, Кәрим үз күләгәсен үлчәп алды. Алтынчы киткән. Ипләп кенә кайтырга җыенганда Сарбаебыз ярсуыннан буыла-буыла, әле анда, әле монда ташланып өрә башлады. Карасак, көтүгә таба берничә бүре якынлаша. Түшләренә ятып, шуыша-шуыша килләр ерткычлар. Менә алар кинәт сикереп тордылар да, артка-алга, унга-сулга сикерголәп, уйнаклаша башладылар. Бер күздән югалдылар, ул арада тагын әллә каян пәйда булдылар. Без аларның ничәү икәнен тәгаен генә белә дә алмадык. Чөнки алар уктай атылып чыгып, көтүгә һөҗүм иткәндәй булалар да, кай арада качып югалалар. Без чыбыркыларыбызны шарт-

лата-шартлата ары йөгердек, бире чаптык. Әйтерсең, алар безнең белән качыш уены уйныйлар иде. Ләкин бу һич тә риясыз уен түгел, ә мәкерле хәйлә булган икән. Сарбай бүреләрнең берсен куа китте, калганнары япереңгән урыннан чыктылар да, томырылып көтүгә ташландылар. Алар дүртәү иде. Арадан зуррак гәүдәлесе туп-туры чабып барып, Шайтанга сикерде. Ул аның бугазына тешләрен батырып, турникта атынучы гимнаст кебек, үзен югарыга чөйде һәм бозаунын икенче ягына әйләнеп төште. Шайтан дәп итеп җиргә ауды. Бүре, алгы аякларын җиргә терәп, аның муен итен умырып та алды. Бу хәл күз ачып йомган арада булып үтте. Без йөгереп килеп җиткәндә бозаунын җәрәхәтле ярасыннан шаулап кан ага иде инде. Торырга тырышып караса да, булдыра алмады. Соңрак муенын бераз алга суза төшеп, тынып калды, үзен тәкъдир кочагына тапшырды. Аның бер ноктага төбәлгән күзләреннән мөлдерәп яшь ага. Кояш нурларында төрле төсләргә кереп, энҗе бөртекләредәй ялтыраган бу яшьләрдә Шайтанның горурлыгы да чагыла иде сыман. Ул үзенең көрәштә җиңеп корбан булуы өчен горурлана иде кебек.

Бүреләр, үзләренең канлы эшләрен башкарып, минуты белән юк та булдылар, Аларны башка бозаулар кызыксындырмаган да, күрәсең. Чөнки калган бүреләр көтүгә килеп җиткәнче үк кире борылдылар.

— И мәлгуньнәр, бөтенләй котырындылар, чак кына бәреп екмадылар,— дип басу каравылчысы Сәләхетдин абый килеп чыкты. — Андый-мондый зыян салмаганнардыр бит?

Без булган хәлне сөйләп бирдек. Ул бозау янына барып, аның әле тере икәнен күргәч: «Пычагыгыз бармы?» — дип сорады. Аңа чалгы пычагыбызны бирдек.

— Бисмиллаһи Аллаһу әкбәр!

Бер кат эшен бетереп, кулларын югач: «Ярар, егетләр,

мин авылга кайтып, булган хәлне идарәгә җиткерермен, ә сез ташлап китмәгез, бүредән калса да, ит ләбаса»,– диде.

Шайтанны ат арбасына салып алып киттеләр. Без дә кайтырга кузгалдык. Бозаулар башларын иеп тын гына авылга таба атладылар. Ләкин берсе дә алга чыгарга базмады. Әйтерсең якыннарын соңгы юлга озатулары иде.

ӘҮЛИЯ

Кешелек дөньясын гасырлар буе хәйран калдырып килеп, әле бүген дә ачылмаган серләр бар бу дөньяда. Шуларның берсе, һәм бәлкем иң гаҗәбедер – әүлиялек.

Безнең нәселебездә дә булган андый кеше. Юк, ул теге дөньякүләм мәшһүр Нострадамус кебекләрдән түгел, аның әүлиялек сыйфатларын авылдашлардан гайре белүче дә булмагандыр. Ул – гап-гади сала агае, минем әниемнең өтисе Шакиржан бабам. Әби-бабалары, әти-әниләре шикелле үк, ул да гомере буе Арча районының Кылачы авылында тормыш көтеп, шундагы зиратка җирләнгән. Мин аны күреп кала алмадым, чөнки ул мин туганчы күп еллар элек мәрхүм булган. Аны бары тик әниемнең сөйләгәннәреннән чыгып кына күз алдына китерә алам. Һәм бу язмамда сезгә нәкъ әнә шул әнидән ишеткәннәрне җиткерәм дә.

Әйткәнемчә, Шакиржан туган авылында гомер сөргән. Чәчкән, урган, балалар тәрбияләгән. Холкы исә бик тә йомшак табигатьле булган. Диндарлыгы сәбәпле, гайбәт сөйләү, ила ягу кебек гөнаһлардан ерак йөргән. Кеше эшенә тыгылмаган, күпне күрмәгән, кирәкмәгәнне ишетмәгән. Инде очраклы рәвештә күргә, йә ишетергә туры килсә, күңеленә бикләп куйган, сер саклый белгән. «Ир-атның сер сандыгына пар-ат та сыярга тиеш», – дип исәпләгән. Ул бик намуслы, үтә кешелекле, риясыз Аллаһы бәндәсе булган. Беркемнең дә өлешенә кермәгән, хәрам ашамаган, хәмернең нинәрсә икәнен дә белмәгән.

Бу күркәм сыйфатлар безнең геннарга салынган, күрәмсең, алар нәсел традициясенә әверелеп, буыннан-буынга күчеп, бүген дә шулай дәвам итә. Бераз тыйнаксызрак тоелса да, әйтми булмый: нинди генә авыр хәлләргә тарысак та, бүгенгенең яңа урысы-татары кебек кеше алдап, талап акча эшләргә, баеп яшәргә омтылмадык. Андый мөмкинлек туган очраклар аз булмады, югыйсә. Безнең гаиләдән берәүнең дә кыек-тайгак, намуссыз юлга басып, әби-бабайларның якты исеменә тап төшергәне булмады. Нәсел агачыбызның тамырларыннан ук күтәрелгән сафлык, инсафлылык – бүген дә уллarымның, оныкларымның иң зур хәзинә-байлыклары.

Шакиржан бабамның да тискәре яклары булмый калмагандыр, әлбәттә. Ул да фәрештә түгел бит. Бәлки әле холыксызланып, кызып, жикеренеп тә киткәләгәндер. Тик болары хакында мин хәбәрдар түгел.

...Көннәрдән беркөнне гаиләнең өмет баганасы булган Гарафетдин абый үлеп китә. Күпме генә им-том итсәләр дә, аны аякка бастыра алмыйлар. Берепче бөтендөнья сугышында алган яра-жәрәхәтләреннән озак газапланa торгач, вафат була ул. Бу үлем бабам, әбием, минем булачак әнием һәм гаиләдәге башкалар өчен дә зур югалту. Чөнки ул – бердәнбер малай. Тарихтан беләсездер, жир иманасы бары тик ир балаларга гына бирелгән. Бабам инде хәйран картайган, шуның өстенә гариплеге дә бар. Бу бәхетсезлеккә ул Арча тавын төшкәндә дучар була. Тиктомалдан аты дулап китә һәм бабам, аны тынычландырырга теләп, тәртә башына барып ябыша. Тик ярсынган атның йөгән сабагын кулыннан ычкындырып жибәрә. Бабам ат астында калып, муенын сындыра. Еллар үтеп, имгәнгән урын бераз төзәлсә дә, бабам муенын туры гына тота алмый торган булып кала. Шуңа күрә ана «Кылый Шакир» кушаматы тагыла.

Гарәфетдинен күмеп, тиешле дини йолаларны үгәгәч, бабам кабер янындагы ир-атларга болай ди:

– Улымны зурлап, безне хөрмәт итеп килүегез өчен сезгә Аллаһының рәхмәте яусын, һәрберегезгә әжерен бирсен. Аяк-кулларыгыз сызлаусыз булып, изге теләкләрегезгә ирешергә насыйп әйләсен.

Авылдашлары Гарәфетдингә изге теләкләр теләп, көрәкләрен иңнәренә салып кайтыр юлга жыенганда бабам янә телгә килә:

– Жәмәгать, бүген минем дә яфрагым өзелеп төште. Гарәфетдиннең кырыгы тулган көнне мин дә гүр иясе булырмын. Менә монда – улым каберенең уң ягына жирләрсез. Минем жиназа намазына да килсәгез иде.

Әлбәттә, бу көтелмәгән сүзләрдән аптырашта калган кешеләр: «Шакиржан абый, булмасны сөйләмә, авызыңнан жил алсын! Нинди үлү ди ул, туам дип кенә туып булмаган кебек, үләм дип кенә үлеп тә булмый, Хак Тәгаләнең генә кодрәтеннән килә торган эш ул»,– диешеп таралышалар.

Бабамның сүзләренә беркем дә ышанмый. Улының кайгысыннан төшенкелеккә бирелгәндер, дип фараз кылалар.

Зиратта әйткән сүзләрен бабам өйдәгеләргә дә кабатлый. Бу хәбәр барысына да аяз көнне яшен суккан кебек ишетелә. Барысы да борчыла, кайгыра, елаша. Күңелсез хәбәр бөтен авылга тарала һәм халык, эчке бер киренкелек белән, Гарәфетдиннең кырыгы житкәнне көта.

Тормыш мәшәкатьләре белән көн артыннан көн үтә тора. Бабам, һәрвакыттагыча, иртүк торып таһәрәтен ала, намазын укый, малларын карый. Күп вакыт ауган-сынган каралты-курасын төзәтү белән шөгыльләнә. Буш вакытларын сөкедә карындык тәрәзәгә багып уздыра. Никадәр генә тыныч булырга тырышса да, санаулы көннәр, санаулы сәгатьләр аны хафага салмый калмагандыр. Гомер иткән

хатыныңны, сөекле балаларыңны, туган-тумачаңны, кешеләрне мәңгегә ташлап китү - пәйгамбәрләргә дә җиңел булмагандыр.

Ниһаять, Гарафетдиннең кырыгын үткәрәсе көннең таңы да ата. Өйдәгеләр никадәр генә табигый булып калырга тырышсалар да, күңелләрен нидер борчый, һавада ниндидер шом зыңгылдап тора кебек. Бер караганда, хәсрәтләнергә сәбәп тә юк шикелле: барысы да үз урынында, һәркайда тәртип, бөтенесе дә исән-сау.

Бабам, иртәнге мәшәкатьләрен башкарып, берәр чокыр чәй эчкәннән соң, мәчеткә юнәлә. Намазга җыелган авыл картлары әле таралып өлгермәгән була. Бабам аларның һәрберсе белән кул биреп исәнләшә, уң якка авышкан башын сакалыннан тотып турайтып куя да, итагать саклап кына сүз башлый:

– Җәмәгать!– ди ул. – Бүген Гарәфетдин улымның үлеменә кырык көн тулды. Барыгызны да Аллаһының ризалыгы өчен аның рухына багышланган аш мәҗлесенә чакырабыз. Хәзинәдә бары, гаеп итмәссез. Үземне дә Хак Тәгалә хозурына озатырсыз, Аллаһы боерса. Әгәр бу изге йортта соңгы тапкыр күрешүебез икән, риза-бәхил булышыйк. Дөньяныкы доньяда калсын. Минем берегезгә дә дәгъвам юк. Әгәр хаталык белән берәрегезнең хәтерен калдырган булсам, түбәнчелек илә гафу сорыйм...

Бабам авылдашлары алдында башын ия төшә. Алар да үз чиратларында, риза-бәхиллекләрен белдереп, аны берәм-берәм кочакларына алалар. Тик әле һаман бабамның әйткәнцөренә генә ышанып җитә алмыйлар. Ничек инде, алдында исән-сау басып торган кешегә тагын берничә сәгатьтән жиназа укырга кирәк булсын ди? Беркем дә үзен алда ни көтәсен белә алмый, безнең тәкъдирләр фәкать Аллаһы Тәгалә кулында ләбаса.

Туган авылы, таныш йортлар, аларда гомер сөргән дуслары, якыннары, туган-тумача белән бәхилләшә-бәхилләшә, бабам әкрен генә өенә кайтып житә. Һай, бу тормыш дигәнең! Никадәр авыр, кайгы-хәсрәтле, мәшәкатьле булса да, мәхәббәтле-ләззәтле, татлы-шатлыклы да шул ул! Шушы өермәле капма-каршылыклар арасында йөрү яшәү дип атала да инде. Яшисең икән, димәк, син бәхетле. Хәер, Аллаһы кушканча яшәп, бу дөньядан Аллаһы кушканча китеп бару да – бәхет, уйлап баксаң.

Шакиржан бабам гомере буе берлегенә һәм барлыгына иман китереп, табынып яшәгән Аллаһыдан бары бер нәрсәне - Гарәфетдин улының кырыгына багышланган мәҗлескә кадәр үзенең исән булуын, борынгыдын килгән йола кушканча Коръән укып, улы рухына догалар, изге теләкләр багышлап, җиренә җиткереп үткәрергә соңгы мөмкинлек бирүен үтенә. Үлем салкыны күз алларын каранғылап, вакыт-вакыт тынын куырып алса да, бабам аңа игътибар итмәскә тырыша, беркемгә дә сиздермәскә тырыша, беркемгә дә сиздерми. Хәер, аның үләсенә, әйткәнемчә, беркем дә ышанмый әле. Үз аягында йөргән, теге җирем авырта, бу төшем әрни, дип, шыңшымаган, сыкранмаган кеше тик торган җирдән ятсын да, кипәт кенә үлеп тә китсен, имеш. Алай булмый, ләбаса. Әнә, кәҗә Сабиржаны ничәнче елын инде урын өстендә ята. Үлсә, ул үләр иде. Юк шул, әҗәлне чакырып китереп тә, куып жибәреп тә булмый, һәр жан иясенең үз вакыты бар. Аласы сулышың, җыясы ризыгың бетте исә, бер минут алга китеп тә, бер минут артка алып та булмый. Әҗәл дигәнең үз вазыйфасын гаҗәеп зур төгәллек белән башкара.

Мәҗлескә барысы да чакырылган вакытка килә. Мулла абзыйның чамасын белеп кенә үтемле итеп сөйләгән вәгазеннән соң, мәҗлес халкы аш-суны мактый-мактый эшкә керешә. Шакиржан бабам да үз өлешеннән валчыгын да

калдырмый. Ул ахирәт сәфәренә чыгар алдыннан тамагын туйдырып куя. Тик табынга чәй бирелер алдыннан шыпырт кына юкка чыга. Аш белән мавыккан кунаклар аның торып китүен сизми дә калалар. Карт, ашлыктан бушап калган келәткә кереп, идәнгә яңа гына чабып алып кайткан хуш исле печән түшәк, баш очына үзенең бик озак еллар киеп йөргән чикмәнен сала. Бөтен хәстәрлеген күреп бетергәч, чыгып таһарәтен ала, өс-башын алыштыра. Өйлә намазын укыгач, хатыны Минсафаны чакыра.

– Әй, дим, – аларның бер-берсенә якын итеп эндәшүләре шулай була. – Без синең белән бергә утыз өч ел гомер иттек. Бу озын юлны узганда төрле чаклар, хата-гөнаһлар да булгандыр, саксызлык белән рәнҗеткән чакларым булса, гафу ит. Мин синең белән гомер кичерүемә бик канәгать, син дә мине хөрмәт итеп яшәдең. Барысы өчен дә Аллаһының рәхмәте яусын, әжерен бирсен, урының Җәннәттә булсын. Мин риза-бәхил.

– Шакиржаным, әллә син чынлап та...

– Мине алырга килделәр инде....

Әбием гомере буе сөеп яшәгән ире янына чүгәләгән арада, бабам инде дөнья белән мәңгелеккә хушлашкан була.

Йа, Раббым, рәхмәт-шәфкатеңнән ташлама!

Әгәр бабам белән әбиемнең туганнарыннан берәрсе аларның каберләрен күрсәтә алса, мин бик рәхмәтле булыр идем.

ҖЕНЛЕ КИЧӘЛӘР

Без әле кара мунчаларга йөрмәгән, кызлар озата белмәгән чакларда, кучкарда жиделе лампа янган вакытларда апажиңгиләр, әни-әбиләр көзге караңгы-яңгырлы, кышкы карлы-буранлы кичләрдә ямый-тегәсе, эрли-бәйлисе күл эшләре белән әле берсенә, әле икенчесенә җыелышып утыралар иде. Хуҗабикәнең әлләни сые булмаса да, такта чәе янына бәрәңгенең мичтә тәгәрәткәнеме, казанда ярмаланып пешкәнеме һәрвакыт табылыр иде. Ул кич утыруларда соңгы хәбәрләр, әлбәттә инде, сөйләнми калмый иде. Кем ниләр күргән, кайсы егет кем кызын озаткан, кем кемне үпкәнкочкан, кемнең кесә төбеннән күпме урланган арыш чыккан? Һәм башкалар, һәм башкалар. Кыскасы, авылдагы шылт иткәннән алып, фронтта шартлаган снаряд-бомбаларга кадәрле бәйнә-бәйнә сөйләнеп, булган һәм булырга бөреләнгән һәрбер хәл үзенә лаек бәяне ала иде бу «парламентта. Улларын, ирләрен, туганнарын фронтка озаткан бу хатын-кызларның ишетмәгәннәре, күрмәгәннәре, белмәгәннәре, кем әйтмешли, Бохарадагы таз гына булгандыр. Алар дөньядагы вакыйгалардан азмы-күпме хәбәрдар булып, һәр хәбәрне күңелләре, йөрәкләре аша үткәреп, кайгы-хәсрәтләрен, борчу-мәшәкатьләрен, хәтта соң телем икмәкләрен бер-берсе белән бүлешеп көн күрделәр. Сугыш вакытларындагы тормыш авырлыкларын, ачлык-яланғачлыкларны, якын кешеләренең үлем хәбәрләрен, мәхәббәтләрен мәңгегә югалту ачысын яралы-сыкраулы йөрәкләре аша

үткәреп, ил язмышын, ир кайгысын үз җилкәләренә алдылар алар. Ул чорда яшәгән әби-бабаларыбыз, әти-әниләребезнең башкайларыннан кичкән фәкыйрьлек-ялангачлык, ачлыктан һуштан язулар, гарип калуларны моңа кадәр Җир йөзеннән үткән бер генә буын да күрмәгән, кичермәгәндер. Ил-Ватан өчен үзен фидакарь корбан иткән бу буынга һәйкәлнең иң бәеген, затлы-кыйммәтлесен кую да аз булыр.

Бала чагалары белән өелеп калган, барлык йорт мәшәкатьләрен сылу иңнәренә салган, бер караңгыдан икенчесенә кадәр колхоз эшендә булган бу батыр йөрәкле хатын-кызлар кайчак уен-көлке сөйләшеп, уйнап-шаярып алырга да вакыт табалар иде. Ир-егетләрдән калган тальян гармунны шыңгырдатып кына булса да, биеделәр дә, күңелләрен бушатып елап та җибәрделәр. Шулай итеп кайгы-хәсрәтләрен юдылар, сары сагышларын кудылар.

Мондый кич утыруларда, сүз иярә сүз чыгып, каз тәннәре бүрттереп, жанны өшетеп, куырып ала торган җеннәре, пәриләре дә булгалый иде. Әле абый-апалар белән ат чанасына төялеп тау шуарга җитлекмәгән, аулак өйләргә йөреп, гыйшык уены уйнарга дөрте уянмаган, ямаусыз күлмәк-ыштаны да булмаган күрше малай-шалайлар да керә бит кич утыруларга. Алдан ук тамакларыбызны туйдырып куябыз да, җылы мич башында әниләребезнең сөйләгәнен тыныбызны да чыгармыйча, шыпырт кына тыңлап ятабыз. Бу вакытларда күзләребез акайган, йокы качкан була.

* * *

Безнең өйдә узган кич утыруларның берсендә әнием сөйләгән маҗаралы-гыйбрәтле бер вакыйга күңелгә сеңеп калган.

Мина, күп булса, алты-җиде яшьләр булгандыр, дип баш-

лады әни сүзен. Ата-аналар берәр-яры китеп, без – нәниләр үзебез генә калдык исә, мич астының табагачтыр, кисәү таягыдыр куя торган җиреннән сарык кадәр генә ат сыман нәмәрсәкәй чабып чыгар иде. Аның куршы яллары матур итеп таралган, көлтәдәй койрыгы идәнгә кадәр сибелеп төшкән. Ул чабып килеп безнең сәке янына туктала, исәнләшкән сыман итеп салмак кына кешнәп тә куя. Без аны һәрвакыт сагынып көтеп ала идек. Ул чыкса, шатлыгыбыз эчкә сыймый, шулкадәр рәхәт булып китә. Аны сыйларга, кочакларга керешәбез. Зәйнәп сеңлем белән ялын үрергә тотынабыз. Ә Гарәфетдин абыебыз койрыгына тәти чүпрәкләр эләә. Тегс нәмәрсәкәй рәхәтләнеп басып торуын белә, үзе дә безгә сырынып, башын иңнәребезгә куя. Шунысы гаҗәп: аның ялы да, койрыгы да, чын атларныкы кебек чәнечкеле-каты түгел, ә бәлки сфәктәй йомшак, елык-елык килеп ялтырап тора. Тәне дә бармакларыбыз батып керердәй йомшак, гүя аның кабыргалары бөтенләй дә юк. Атыбыз һәр чыгышында төсен үзгәрткән була. Аның төсенә карап, кемнеке икәнен беләбез. Әйтик, аклы-каралы икән, ул Гарәфетдин абыйныкы, мондый төскә кергәндә аның гәүдәсе дә зуррак, холкы да басынкы. Минем атымның түше алсу-кызыл, аяклары көрән, калган җире аксыл иде. Зәнәпнең аты ап-ак булып, маңгаенда кызыл калфагы бар иде

Атның йөгәне дә бар. Лөкин ул беркайчан да аңа кагылдырмады. Үрелә башладың исә, үрле-кырлы сикеркеп китеп тә бара. Ләкин үпкәләми, яңадан яныбызга килеп баса. Башын бертуктаусыз селкеп тора башласа, бу аның: «Атланыгыз!»– дигән ишарәсе була. Һәм безне өстенә утыртып, ипекле-түрле йөртә башлый. Һәр әйләнеш саен туктап, икенчебезнең атланганын көтеп тора. Безне шулай чират белән әйләндерә дә әйләндерә. Бу күңелле уенны тышта берәрсенең тамак кырганы, яки әти-әниләр кайткан тавыш кына

бүлдерә иде. Атыбыз мондый авазларга бик сизгер булды. Шылт иткән ят тавыш ишетелсә дә, мич астына кереп юк була иде.

Гарәфетдин абый бу турда әтиләргә сөйләгәч, атларыбыз берара күренми торды. Бу гажәп хәлне ишеткән авылдашлар: «Сез аның ничек тә йогәненнән эләктерергә тырышыгыз!» — дисәләр дә, әти катгый рәвештә каршы килде, йөгәненә кагылырга кушмады.

Без зурая төшкән саен атлар да безнең белән күрешүне сирәгәйтте. Һәм көннәрнең берендә бөтенләйгә үк юк булдылар. Уйнар вакытларыгыз узды, дип әйтүләре булгандыр бахбайларның...

Хатын-кызлар, әнием сөйләгәннәргә ышанырга да, ышанмаска да белми, тынып калды. Күңелләренә курку хисе үрмәләгән иде, булса кирәк. Һәрберсе башын түбән иеп, үз эпен дәвам иттерде. Тынлыкны күршe малае Рәшит бозды.

— Эх, үзем булсам, йөгән сабагыннан барыбер эләктергән булыр идем!

— Сиңа тоттырырлык булса, мич астыннан чыкмый да ул.

Безнең арада кызу бәхәс китте. Һәркем үз сүзен сүз итәргә тырышты.

— Тотсаң нишләр идең?

— Әткәйне сугыштан кайтар!— дияр идем.

— Мин ипи сорар идем...

— Ә мин, яңа өй салып бир, дияр идем.

— Эх-ма!

Апалар бераз тынычлана, безнең бәхәс бераз сүрелә төшкәч, әнием:

— Әллә чәй эчеп алабызмы?— дип тәкъдим ясады.

— Әйдә соң, җен атларына атланып йөри-йөри, иреннәр дә кипшереп китте,— дип шаяртып алды күрше Әминә апа.

Табада сөт белән кыздырылган бәрәңге ашап, чәйләр эчкәч, без тагын мич башына менеп кунакладык. Никадәр генә әтәчләнсәк тә, тышка үзебез генә чыгарга курка идек. Әни һәммәбезне дә киендереп тышка чыгарып керде. Урамда көзге салкын җил исә, яңгыр сибәли иде.

— Әгәр чүп өстенә чүмәлә димәсәгез, мин дә берне сөйләр идем,- диде югары очтан Гайнекамал апа.

— Атың арбалы булса гына, ату атланып йөреп күт авырта башлады,- дип шаяртты Әминә апа, арт санын анда-монда боргалап.

— Авыртса, астыңа мендәр сал.

Мендәр димәктән, ул һәр өйнең сәке түрендә дистәләгән булып, төрле чәчәкләр белән бизәп чигелгән, кырыйлары чуклап эшләнгән, зур җәймә белән бөркәлгән булыр иде. Бездә алардан тыш берничә ястык та бар иде әле. Чөнки ул елларда каз-үрдәкне берничәшәр оя асрыйлар иде.

* * *

Хәбибҗамал килен әйтмешли, дип башлады кыйссасын Гайнекамал апа (әнине килен дип атавының сере шунда: ул әнидән шактый өлкән кеше һәм безгә чыбык очы гына булса да, туган тиешле иде), безнең дә әти-әниләр берәркая китеп, өйдә балалар гына калсак, ишек янын биләп торган зур мичебезнең аралыгы ягыннан үзе юан, үзе йонлач бер кул асылынып төшәр иде. Аның бармаклары сыер имчәкләре кебек шома, йомшак. Без ул бармаклар белән сыер савышлы уйный идек. Энебез Фәтхрахман мич башына әллә ничә тапкыр менеп караса да, кулның гәүдәсен таба алмады. Нинди кул булгандыр ул, белгән юк.

– Йа, Аллам, йа, Раббым, ярдәмеңнән үзең ташлама,– диештә апалар.

Сүзне уң як күршебез, чалгыдай үткен телле, әйтәсе сүзен һәрвакыт турыдан бәреп яра торган, кайчак ирләр дә тотынырга курыккан эшләрне җиренә җиткергән чая һәм төвәккәл Рокыя апа ялгап китте:

– Мин дә юлыктым бит ул серле җан ияләренең берсенә, башы беткере! Тик миңа безнең Сабиржан шикелле котырганы туры килде. Ул көнне ишегалды тутырып болын печәне киптердек. Болай мул итеп ул җәйдә беренче тапкыр киптерүебез иде. Көн бүе шуларны әйләндереп-кабартып йөреп, тән сыекланган. Печән шундый кибеп-күпереп тора мең, әйтерсең яңа пешкән күмәч инде, валлаһи. Һай, аларның хуш исләре! Йолкымый гына, бик селкеми генә печәнлеккә менгереп өйдек. Бөтен лапаска болын исе таралды. Ә кичен әнә шул хуш искә кызыгып, улым Фәрит белән печәнлектә йокларга булдык. Фәрит ятуга ук йоклап та китте. Ә мине йокы алмый гына бит, каһәре. Тәнем изрәгән шикелле, ә башым аек. Чигә тамырларым молотилка мени, дөп-дөп итеп суга. Күңелдә әллә нинди шом бар, менә-менә нинди дер хәвеф булыр сыман.

Инде караңгы төшкәнгә дә байтак вакыт үтте. Йокы дигәнең һаман юк та юк. Шулай хәйран интеккәч, инде черем дә итә башлаган кебек тойган идем. Бервакыт абзардагы сарыкларның әрле-бирле бәргәләнүләренә сискәнеп киттем. Чабып атлары мени, ду киләләр. Ни булыр икән бу, дим. Бүре мәлгунь җәй көннәрендә абзарга кереп маташмый торган иде. Ул инде сарыклар белән куышлы уйнап та тормас иде. Караңгыда күренмәсә дә, шыпырт кына сузылып, абзарга күз ташладым. Барысы да тәртиптә кебек. Сыер да үз урынында. Тик ара-тирә тыпырчынгалап ала, койрыгы белән, нәрсәнедер куган кебек итеп, сыртына суккалый,

башын анда-монда селкеп, тирән итеп пошкырып та куя. Берара бу сәер авазлар бетеп, абзардагы ыгы-зыгы тынып калды. Мин дә тынычланып урыныма яттым. Ләкин күп тә үтмәде, инде тавыкларыбыз кытаклаша, гаугалаша, кунакчаларыннан атылышып төшә башлады. Әтәчнең аллә тәпиләреннән тоттылар инде, ул канатлары белән бәргәләнә-бәргәләнә, шар ярып кычкырырга тотынды. Тагын шау-шу купты. Тик бу юлы да ул беразга тынып алды. Бу әле башы гына булган икән. Бераздан янымда гына печән кыштырдап киткән шикелле тоелды. Бөтен тәнем буйлап калтыранну йөгереп узды. Эсселе-суыклы булып китте. Гәүдәм чымырдып-чымырдап ала. Озак та үтмәде, кулга охшаган йонлач бер нәрсә башымнан тотынып, аска таба сыпыра башламасынмы. Бераз сыйпаштыра да туктый, сыпыра да туктый. Котым очты инде, җаным чыга дип торам. Кычкырмакчы булам, тавышым чыкмый. Әйтерсең, өстемә албасты менеп утырган. Куркуымнан аңымны ук җуйганмын. Берзаман һушыма килсәм, бөтен җирем лычма су, әллә астыма да җибәргәнмен инде. Көчкә торып утырдым. Башым зыңгылдап әйләнә, йөрәк чыгардай булып кага. Тирә-як тып-тын. Таң да беленә башлаган. Уяныр-уянмас Фәритемне җитәкләдем дә, баскычтан ничек төшкәнемне дә белми, ойгә кереп киттем.

– Нәрсә булды?– ди әйдәгеләр.

Сүземне әйтә генә алмыйм бит, телем аңкауга ябышып каткан мени. Бөтен тәнем дер калтырый. Төс-кыяфәтеңне танырлык түгел иде, диделәр. Зәп-зәңгәр булганмын. Юрганга төренеп, кайнар чәй эчкәч кенә адәм рәтенә керә башладым.

Җәй буе кузгала алмый яттым урын өстендә. Менә бу чәчләрем шул чакта агарды. Исемә төшсә, әле дә аңымны

жуярдай булам. Җеннең менә ниндис очрады миңа, Аллаһының каһәре төшкере!

Рокыя апа яулыгы белән битен каплап, елый ук башлады. Барыбызга да уңайсыз булып китте. Югыйса үзебез дә куркудан бер-беребезгә сыланып-сыенышып беткән идек. Күршеләре буларак, бу фаҗигане ишетеп белсәк тә, Рокыя апаның үз авызыннан ишетү бөтенебезне дә тетрәндерде.

– Рокыя җаным, өннәребезне алдың, өйгә кайтырлыгыбызны да калдырмадың.

– Аллаһы Тәгалә сине рәхмәтеннән калдырмасын инде, терелергә, сихәтләнергә насыйп булсын,– диештә апалар.

Әнием аннан җен-пәриләр турында сүз кузгатканы өчен кат-кат гафу үтенсә дә, эш узган иде инде. Аның кәефе киткән, кич утыручыларның тынычлыгы беткән иде.

– Аллаһым, мондый бәла-казалардан, хәвеф-хәтәрләрдән үзең сакла?! – дип кабатлый-кабатлый, кайтырга кузгалдылар.

Бүтенге күзлектән чыгып фикер йөрткәндә, мондый хәлләр кеше ышанмаслык фантастика кебек тоелса да, алар булган. Димәк, әле егерменче гасырның башларында да серле җан ияләре кешеләр белән янәшә яшәгән, адәм балаларына игелек кылырга тырышканнар. Ә соңрак исә кайберләре, кешеләр кебек үк үзгәреп, азып- тузып йөри башлаган, күрәсең.

Бүтенге кешеләр белән янәшә була алырлар иде микән алар?

КОРЧАҢГЫ

«Ялгышны төзәтеп, язмышны үзгәртеп»,– дип җырласалар да, аны һич үзгәртеп тә, төзәтеп тә булмый икән шул. Ул, бормалы-сырмалы, менәле-төшәле, чокырлы-сикәлтәле юл сыман, ерак-еракларга сузылып яткан. Кеше дигән җан иясе әнә шул язмыш сызган юл буйлап михнәт-газаплар, шатлык-куанычлар кичереп, гомеренең ахыр чигенә таба бара да бара. Юл газабы – гүр газабы, диләр. Кеше дә әлеге юлда афәт-фаҗигаләргә тап булып, үлем-югалту хәсрәтләрен газиз башкайларыннан кичерә.

Дөрес, тормышның мең төрле көтелмәгән вакыйгалары аны язмыш сызган юлдан тайпылдырган чаклар да булгалый. Монда инде янәшәндә яшәгән, дустанә мөнәсәбәттә булган кешеләрнең йогынтысы да тими калмый. «Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырларсың», «Дустың үзеңнән яхшы булсын» дип әйткән бит безнең борынгы бабаларыбыз. Хәтта өйләнә-тирәндәге кешеләрнең үз-үзләрен тотышлары да сиңа күпмедер дәрәҗәдә тәэсир итә. Аларның әнә шул йогынтысына карап теге яки бу якка үзгәрүең дә бик табигый.

Бу тайпылыш-читләшүләргә кешенең балачагында алган әдәп-гадәте, тәртип-тәрбиясе һәм башка шундый бик күп факторлар да сәбәпче була. Шуңа күрә «аттан ала да, кола да туа». Телисеңме, теләмисеңме, синең тәкъдирең башкалар язмышы белән дә багланышлы...

Мин – Арча районының Субаш Аты авылында дөнья-

га килгән сугыш чоры баласы. Ул заманнарда бездә тирәяктагы салалардан да килеп, югары сыйныфларда укучы яшүсмерләр белән шаулап-гөрләп торган урта мәктәп һәм әти-әнисез калган үксез балаларны үзенең җылы кочагына сыендырган ятимнәр йорты бар иде әле. Якын тирәләрдә иң эре авыллардан саналган Субаш Атының үзендә дә яшьжилкенчәк ишле иде.

Сугыш тынып, әгиләр, абыйлар фронттан кайта башлагач, тормыш йөгән үз жилкәләрендә күтәреп килгән әлеге тырыш, тәвәккәл яшьләрнең бер ише Донбас шахталарына чыгып китте. Ә тагын бик күбе ФЗӨ дигән мәктәпләрдә һөнәр алып, сугыш харәбәләрен төзәтергә керештс. Шулар арасында минем уиҗиде яшьлек Нәҗип абыем да бар иде. Ул Казан училищеларының берсендә балта остасы һөнәрен өйрәнде. Ләкин аның һич кенә дә анда торасы килмәде, авылны сагына иде ул. Шуңа күрә, җае чыккан сасн, качыпмы шунда, сорапмы кайта торган булды.

«Түзәр хәлем калмады, ничек кенә булса да, мине авылга кайтартыгыз!», — дия иде әнигә. Әни, мескен, бу хәлнең мөмкин түгеллеген аңлатып, кат-кат үгетләп тә карады. Тик абыйның үз туксаны туксан. Белмим, ашарына да катыкоты булган хәерче авылны ник шулкадәр сагынгандыр ул? Укыган жирендә итле аш, туйганчы ипи, май, шикәр бираләр дип сөйли иде үзе. Шунда рәхәтләнеп ашап кына ятасы инде югыйса. Юк, сагына имеш. Әни берничә мәртәбә кулыннан җитәкләп Казанның үзенә кадәр илтеп тә куйды. Тик, әни кайтып берничә көн үтүгә, көгүдән качкан кәҗә сыман, ул да кайтып җиткән була. Туган җирнең тарту көче бернәрсә белән дә исәпләпмы, күрәсең. Ач-ялангач булса да, кешегә кендек каны тамган туган туфрак кирәк. Адәм баласын үз жиренә әнә шул кан тарта.

Өебез ятимнәр йорты белән күрше генә булганга, анда

тәрбияләнүче малай-кызларның бик күбе безгә дә керә иде. Өебез зур, берничә бүлмәле. Колхоз идарәсенә дә, клубка да якын гына. Шуны истә тотып, әледән-әле килеп торган район вәкилләрен, концерт куярга килгән артистларны гел безгә кунарга җибәрәләр. Хәтта Ленинград блокадасыннан качып килгән марҗалар да бездә берничә ел яшәп китте.

Ятимнәр йортында шәфкать туташы булып эшләүче Диләфрүз апа да, фронттан кайткан Габделхәй абыйга киявгә чыккапчы, бездә торды. Ул чыгышы белән Балтач районыннан иде. Шул елларның бөтен авырлыгын безнең белән бергә бүлешеп, бер гаилә кешесе кебек яшәде Диләфрүз апа. Без үзебез дә аны бертуган апабыз кебек яраттык. Аның сүзе ныклы, тәрбиясе ипле булды, кирәк чагында кыздырып алырга да күп сорамады. Әлбәттә, кыш чыгарлык утының кайтарткан, азмы-күпме фатир хакын да биреп барган бу апаның колхозда таяк хисабына эшләп йөргән эписбезгә ярдәме зур булды. Шул барлы-юклы акча белән әни биш баласын ялангач итмәде.

Көннәрнең берендә, гадәттәгечә, Нәҗип абый кайтып керде. Бу юлы аның күңеле күтәренке, йөзе көләч иде. Әйтерсең, аны бөтенләйгә кайтарып жибәргәннәр. Ул тиз генә хөкүмәт биргән формасын салып, авылның кырык ямаулы киемнәрен киде дә, үзе чалгыдан ясаган пәкесен алып кайрый башлады.

Нәҗип абый алтын куллы кеше иде. Аның белмәгән һөнәре, эшли алмаган эше булмагандыр. Нәрсәгә генә тотынса да, җиренә җиткереп, менә дигән итеп башкарып чыкты. Ул бу яклары белән әтигә охшаган диләр иде. Безнең әти дә, тирә-як авылларда йортлар салып дан казанган оста иде, җитмәсә кулларында былбыл сайрата торган гармунчы да әле. Без дә, дүрт улы, бер кызы, аның тальянында өйрәнеп, гармунчы булдык. Ә Нәҗип абый барыбыздан

да остарак уйный иде. Аның Вараксин дәдәй үз куллары белән ясап биргән ундүрт телле гармуны Казан урамнарында бик озак еллар яңгырады. Бу хәлләр инде без Казанга күчеп килгәч булды. Ә хәзергә Нәҗип абый, йөзен тырнак очына каптырып үткенләгән карый-карый, пәкесен кайрый.

– Ничә мәртәбә әйттем югыйсә, кагылмагыз минем кырына торган пәкегә, дип. Тәки шуңа каныктылар. Хәзер йөзен чыгарып газапланырга кирәк...

Ул арада төшке ашка Диләфрүз апа да кайтып керде.

– Ә-ә, кунак бар икән! Бер дә сагындырып тормыйсың тагын үзең. Нәҗип энем, нихәл?

– Сине күргәч, бетте хәл.

– Егылып китә күрмә тагын!

Шулай сүз уйнатып алганнан соң, Нәҗип абый җитдиләнә төште:

– Детдомда башлары корчаңгылы малайлар бармы?

– Бар. Андыйлар җитәрлек,– дип көрсенде Диләфрүз апа.

– Пәке белән кырып төшерсәң, корчаңгы бетә икән дип ишеттем. Дөрес микән шул?

– Әллә пәкеңне шуның өчен кайрыйсыңмы? Кырып кына түгел, көне-төне дәвалап та бетереп булмый ул каһәрне. Җитмәсә үзе йогышлы да. Берсен дәваласаң, икәве авырый башлый.

– Әйдә, берәрсенең башын кырып карыйбызмы?

– Юкны сөйләмә, аларны дәвалау минем эш. Бик кулың кычытса, син, әнә, кышка утын әзерләү хәстәрен күр. Ярый ла үзең Казанда өзергә бөзер булып ятасың, анда мичең ягылган, ашарыңа пешкән, ашау байдан, үлем ходайдан.

– Мин ул әзерләрдән менә болай гарык...

Нәҗип абый үз дигәнен эшләми калмый торган үҗәт һәм бик тәвәккәл кеше иде. Ул ятимнәр йортына кереп башына саргаеп беткән марля бәйләгән бер корчаңгы малайны алып та чыкты. Аның сасыган йомырка исе аңкыган, ян-якларын кутыр баскан җәрәхәтле пеләш башын әкрен генә кырып, пәке йөзенә ябышып калганын бер кәгазьгә саклык белән генә җыя барды. Эшен бетергәч, малайны Казаннан алып кайткан күчтәнәчләре белән сыйлап, чыгарып җибәрде. Аннары көзге каршына басып, шул пәкесе белән үз башын да кыра башлады. Кәгазьгә җыйналган теге чирканыч нәмәрсәне каны саркып торган урыннарына сылап, чүпрәк белән бәйләп тә куйды.

«Уфалла» арбасы тартып, без урманга чыгып киттек.

– Нигә болай эшләдең?– дип сорадым кыяр-кыймас кына.

– Их, энекәш, белсәң иде сезне шашар хәлгә җитеп сагынуымны! Үзебезнең шушы басу-кырлар һич кенә дә истән чыкмый. Кайчак төннәр буе шулар белән саташып ятам...

Нәҗип абый кулларын җәеп онытылып әйләнергә кереште. Әйләнә торгач, юл буенда үскән үләннәр өстенә барып ауды. Яткан хәлендә шул тузанлы үләннәрне сыйпый башлады.

– Мин төннәр буе шушы кырларда йөрим, шушы үләннәрне ятып кочам ич. Һич тә күз алларымнан китмиләр шул. Туган җирне сагыну, аны ярату уен эш түгел икән ул, энекәш...

Безнең авылның табигатен яратмаслык та түгел шул. Йа, Хода, нинди искиткеч манзара! Тирә-якта урман-кырлар, елга-бүлыннар җәйрәп ята. Алда - арыш басуы дулкынлана. Аның саргылт сабакларында тибрәнгән башаклар инде серкә уйнатырга да өлгергән. Тиздән йомшак, сөтләч орлыкларын берәм-берәм чүпләп, тамак ялгарга да мөмкин булачак. Шушы яшь бөртекләр менә ничә ел инде безне ач үлемнән саклап килә. Бер якта бодай басуы. Аның ямь-яшел өслеге урман буена барып тоташкан. Иген кырлары җанлы

келәм сыман. Алар талгын җилдән дулкынланып, уелып-уелып китәләр. Кыр-басулар кочакларын җәеп, бер-берсенә таба йөгерәләр шикелле. Аларны кояшның шифалы нурлары иркәли. Ә башаклар, бу наздан башларын иеп, рәхәтләнеп пышылдашалар кебек. Арырак бәл кортларын үз табынына җыйган карабодай басуы күренә. Кырларның чәчелми калган урыннарында зәңгәр, сары, алсу һәм башка барлык төсләрне җыйган кыр чәчәкләре чайкала. Алар бу манзарага үзләренчә ямь өстиләр. Басуларның кысыр калган урыннарында үскән бу чәчәкләр янына, каравылчы Сәләхетдин абыйдан кача-поса, игеннәрне имгәтмәскә тырышып кына керә идек тә, кул арбасына төяп өйгә ташый идек. Киптереп печәнлеккә менгереп салгач та алардан исерткеч хуш исләр бөркелеп торыр иде. Җанга рәхәтлек биргән, күңелләрне җилкендергән бу сихри ис, хәтта кыш көннәренә кадәр сакланып, ямьле җәй айларын хәтерләтә иде. Аларны маллар да аерым бер ләззәт белән ашый иде. Утрау-утрау булып үскән бу кыр чәчәкләре иртә таңнан кояш батканчы урак урган әни-апаларыбызга да игелек күрсәтте. Ачлы-туклы уракчылар, ул чәчәкләрне урып, өсләренә ятып сихәт алдылар, ял иттеләр. Соңыннан көлтә-көлтә бәйләп, өйләренә күтәреп кайтырлар иде. Бар иде заманалар, бар иде алар. Шул көлтәләрне дә сүттереп, эченә ашлык яшерелмәгәнме дип тикшерүләр, чишендереп тентүләр, соңыннан шул чәчәк көлтәсен дә бирмичә, колхоз фермасына алып китүләр.

Кешенең кешелек дәрәҗәсен кимсетә торган бу хурлыклы-мәсхәрәле гамәлләр авыл советы активистлары, район вәкилләре катнашында оештырыла иде. Ялгыш кына бер-ике башак эләксә, Аллаһы сакласын! Иртә таңнан торып, караңгыга кадәр эшләп йөргән хезмәт кешесенә нинди генә гаепләр тагылмый, нинди генә пычраклар өелми иде. Шул

бер-ике башак өчен актлар төзелеп, бер гөнаһсыз кешенең язмышы «органнар»га тапшырылды. Ата-аналар төрмәләргә озатылды, балалар ятим калды.

Һай, түзсә дә түзә икән бу адәм баласы! Чыдаса да чыдый икән кеше дигәнең! Буыннан буынга, гасырлар буе, коллар да күрмәгән газап-михнәтләргә дучар итеп, изәләр дә изәләр аны, соңгы сынык икмәгенә кадәр тартып алып, булыр-булмас мал-мөлкәтен талап, ачка интектерәләр; ул мескен көне-төне бушка эшләсә дә, аңа кадер-хөрмәт тә, рәхмәт тә юк. Әйе, Русия хокуксызлар иле, ач-ялангачлар дәүләте шул. Бу михнәтләрнең бер чиге булырмы икән? Халыклар, шул исәптән рус кешесе үзе дә, иркенләп, тир түгеп тапкан малының игелеген күреп, байлык- муллыкта кайгы-хәсрәтсез кайчан яши башлар икән? Нигә бу кадәр игелексез, Аллаһы каргаган ил соң бу? Кан-яшь түгеп, гөнаһсыз жанларны кыеп, ут һәм кылыч белән басып алынган җирләрнең бәрәкәте булмый шул. Бетмәс-төкәнмәс табигать байлыкларының да рәхәтен күрә алмыйсың. Алар череп исраф була бара. Бөекдержавачыл даирәләрнең уйлау рәвеше, холык-фигыльләре үзгәрми торып, Русия халкы рәхәт яшәр дигән өмет юк.

Ярар, сәясәтне шушы урында туктатып, авылыбызга кайтыйк. Үзләренең табигате, басу-кырлары, елга-тугайлары белән бер-берсенә бик нык охшасалар да, һәр авылның үзенә генә хас үзенчәлекләре булмый калмый. Мисалга безнең Субаш Атын алыйк. Беренче карашка шул ук табигать. Түбәләрен салам белән япкан йортлар да, каралты-кура да шул ук кебек. Ләкин бу беренче карашка гына шулай. Әйтик, безнең авылның исеме җисеменә туры килеп тора. Су башы, димәк, чишмәләр иле. Авылны челтерәп аккан эреле-ваклы елгалар, инешләр урап алган. Кай тарафка гына чыгып китсәң дә, агач улаклардан агып яткан чишмәләргә юлыга-

сыц. Аларның һәрберсенең үз төме. Тау башларын ертып та, таш асларыннан ургып та бәреп чыкканнар ул чишмәләр. Тирә-якларын камышлар уратып алган кечкенә-кечкенә күлләребез дә бар. Су өсләре кара кучкыл булып тора, димәк, тирән. Дилбегә очына таш бәйләп төшереп карасалар да, төбенә җитә алмадылар. Аларны төпсез диләр. Нәкъ шушы күлләрдән башлана да инде суның башы. Шуңа күрә дә без – Субаш Аты!

Дәрес, бездә сусыз коры елгалар да юк түгел. Аларның яссы үзәнлекләрендә ишелеп печән үсә. Печәнен чабып алабыз, авыл көтүе йөри.

Һәркемгә үзенең туган авылы сөйкемле, аның җир-сулары кадерле. Шулай булмаса, кеше аны шашып яратмас та иде. Хәтта басу уртасында берьялгызы үсеп утырган агачы да якын бит аның. Тирә юныгә ямь биреп, авылның визит карточкасы булып тора ул.

Юк, безне табигать рәнҗетмәгән, үз байлыкларыннан олешсез калдырмаган. Авылыбыз кешеләренә утын, печән биргән, тәмле җиләк-җимешләре белән сыйлаган юмарт урманыбыз да бар безнең. Аның гүзәллеге хакында бөек Тукаебыз да язып калдырган әле.

Урманында кып-кызыл кура җиләк тә җир җиләк;
Күз ачып йомганчы, һичшиксез, җыярсың бер чиләк.
Бик хозур! Рәт-рәт тора, гаскәр кеби, чыршы, нарат;
Төпләрендә ятканым бар, хәл җыеп, күккә карап.

Әйтерсең лә шагыйрь безнең урман агачлары төбендә яткан, гүя ул бу юлларны аның гүзәллеген мактап язган! Хәер, урман кайда да бер инде ул. Тик исемнәре генә үзгә. Анда Кырлай урманы, бездә – үзебезнең Субаш Атыныкы. Хәзинә-байлыклары да бердәй. Нинди генә агачлар, җиләк-җимешләр юк аларда! "Күз ачып йомганчы, һичшиксез, җыярсың бер чиләк!"– дигән бит әнә. Өз дә ал, өз дә кап.

Җаныңа сихәт җый, тәненне ныгыт. Нинди мәрхәмәтле, мул ризыклы безнең Җир-Әнкәбез!

Ләкин бу дөньяның шушы нигъмәтләреннән файдаланырга, аларның ләззәт-рохәтен күрергә ирек бирмәүче, кешеләрне рәнҗетеп яшәүче, күзләреннән нәфрәт уты бөркеп торган мәрхәмәтсез залимнәр дә юк түгел шул. Шундыйларның берсе ул заманда урман каравылчысы булып торган Сафа исемле бәндә иде. Инде күптән гүргә кергән кешене начар итеп искә алу килешмәсә дә, таш белән атканга аш белән ат, дисәләр дә, мин аны хәтта кеше дип атарга да базмыйм. Намусым кушмый. Бер гаепсезгә никадәр балачаганың, әби-бабайларның канлы күз яшьләрен түктерде ул явыз. Урманнан сынып төшкән агач ботакларын, корыган кураларны җыйган өчен генә бит, кайәр төшкере. Бер уйлаганда, урманны бу чүп-чардан арындырган өчен безнең үзебезгә түләргә, һич югында рәхмәт әйтергә тиешләр иде кебек. Юк шул, чересә, чересен, бетсә, бетсен, тик кешегә генә файдасы тимәсен. Шушы адәм актыгы карт-коры, бала-чага янына жиңел арба җигелгән туры атын чаптырып килер иде дә, чыбык-чабык төялгән, инде күптән ирләр кулы тимәганлектән көч-хәл белән чатын-чотын килеп әйләнгән арба көпчәкләрен ватып,тәртәләрен сындырып китәр иде, мәлгунь. Арбасыз да, утынсыз да калып, үксеп елый-елый интегеп бетә идек. Башка чарабыз юк иде шул. Ул хәтта бездән олыракларны да мылтыгыннан атып туктата һәм үзенең кабәхәтлеген эшли иде. Андый чакларда аның ничек тантана иткәнен күрсәгез икән! Болай да каракучкыл чырае тагын да каралып, бүртенеп киткәндәй була. Кысынкы күзләренең утлы карашы бәгырьләргә үтеп, өтеп-көйдереп алгандай итә Ватасын ватып, сындырасын сындырып, изәсен изгәч, зур эш башкарган кеше сыман, биленә таянып, канәгатьлек кичерер иде. Ул күп еллар тирә-

юнь авылларының халкын куркытып, котларын очырып торды. Бу кадәр мәрхәмәтсез, оятсыз бәндәне Җир ничек күтәрә алды икән, әле дә аптырыйм мин. Шайтан таягын кырау сукмаган кебек, каргыш, бәддога да тимәде бит үзена..

Бу хәлләрдән соң мөнә инде 60 елдан артык вакыт узды. Мин дә озын гомер юлы үттем. Шушы гомер юлында нинди генә милләт кешеләре белән янәшә торып эшләргә, кемнәр белән генә күрше булып яшәргә туры килмәде. Ләкин урман каравылчысы Сафа кадәр явыз, әдәпсез, аның кебек денсез, имансыз кешене, Аллаһыга шөкер, очратмадым. Бу бәндә минем күңелемдә явызлыкның классик образы булып, яклаучысыз, саклаучысыз калган көчсез кешеләр, ятим балалар өстеннән көлү, аларны изүдә эш урынныннан үтә оста файдалануның ачык бер мисалы булып калды.

Әйткәнемчә, бу бәндә инде күптән гүр иясе. Ләкин аңа, авыр туфрагы җиңел булсын, дип әйтергә, рухы шат, урыны Җәннәттә булсын, дип теләк теләп дога кылырга тел әйләнмәс кебек. Хак Тәгаләдән аның бәндәчелек белән бәлеп вә белмичә кылган гөнаһларын ярлыкавын никадәр генә үтенсәк тә, безнең дога-гозерләребез барып ирешмәс, ирешсә дә, кабул булмас сыман. Чөнки ул нахакка күп рәнҗетте, күз яшьләрен күп койды. Хәтта көне буе урак урып намазын укыган, уразасын тоткан әниләр өчен дип җыйган җиләкләребезгә кадәр алып кала иде бит. Моннан да зур оятсызлыкның, кешелексезлекнең булуы мөмкинме? Без аларны урлап алмадык ич.

Бүген, олыгайган көнемдә шул хәлләрне уйлап, күзаллап хәйран калам. Ирексездән сорау туа: аның бу чыгырыннан чыккан законсыз кыланышларына карата район җитәкчеләре исеменә юлланган шикаятьләр булгандыр бит инде? Югары органнарга дәгъвасы да, үтенече дә язылгандыр югыйсә? Язылгандыр. Алайса нигә чарасы күрелмәгән,

нилектән мондый башбаштаклыкка чик куелмаган? Әллә ул чордагы район җитәкчеләренең вәкаләтләре шул Сафаны да жиңәрлек булмаганмы? Югыйсә ул нибары урман каравылчысы гына иде бит. Маршал кадәр маршалларның башларына җиткән ул заманда Сафа кебекләр чебен бәясе дә тормагандыр. Әллә соң ил җитәкчеләренә кешеләрне куркытып, өннәрен алып тору өчен Сафа кебекләр кирәк булдымы икән? Бәлкем хактан да урман чүп-чары, утынсыз яши алмаган халыкны буйсындыру коралы гына булып хезмәт иткәндер ул? Дәүләт урманын саклап югарыдан килгән күрсәтмәләрне үтәүче генә ниһаять. Алай гына да түгел, тырыша-тырмаша шул күрсәтмәләрне күп тапкырларга арттырып үтәүчеләрнең берсе. Димәк, мылтык тоткан бу иш бәндәләр хөкүмәтнең нигез ташлары, ян терәүләре булганнар. Аның барлык бозрыкларын үрә катып, сукырлырча үтәүчеләр. Башкача мөмкин дә булмаган. Чөнки бу "халыклар атасы" Сталинның ил халкын меңләп түгел, миллионлап кырган, репрессияләгән чор иде. Хуҗасы нинди - эте шундый. Тешләмәсәң, талый белмәсәң, үзеңне теткәләп ташлауларын көт тә тор. Изелсәң дә, тапталсаң да, тыныңны чыгарырга бернинди хокукың булмаган колльк чоры, кыргый заманнар иде шул.

Хәер, тырышсаң, Сафа абыйның кыланмышларын башкачарак та бәяләп буладыр. Бер уч ашлык өчен биш-ун елга төрмәләргә утырткан, халыкны концлагерьларда чебен урынына кырган еллар иде бит. Шушыларны һәм башка коточкыч җәбер-золымнарны искә төшерсәк, Сафа абыйның безне рәнҗетүләре усал шаяру гына булып кала түгелме? Аның безнең юлга киртә булып төшеп, зыян салулары безне шушы афәтләрдән, төрмә газапларыннан саклап-аралап калу өчен булмадымы икән? Бәлкем бераз артыграк кына кылангандыр? Җәбер-золымнарны йомшаграк та эшли

алгандыр? Ләкин аның да исән каласы, яшисе килгәндер. Бу шайтан таягына кырау тимәүнең сәбәбе, бәлки, шулдыр. Кем белә, бәлкем Сафа абый Аллаһы Тәгалә каршында кулыннан килгән кадәр игелек эшләүче, рәхимле бәндә булып калгандыр. Район җитәкчеләре дә, югаррак утыручылары да, бу чордагы вәзгыятьне дөрес аңлап, аек фикер йөрткәннәр, башкача эшләү һич мөмкин түгеллеген тәгаен төшенгәннәрдер, мөгаен. Зур бәланың кечкенәсен сайлаганнар булса кирәк.

Әйдәгез, шәфкатьле, миһербанлы булып, бу туганнарыбызның авыр туфраклары җиңел булсын, Хак Тәгалә урыннарын Җәннәттән әйләсен, дип дога кылыйк, бәхиллегебезне юллыйк, аларның хәер-фатихаларын алыйк.

Тик шунысы борчый, шундый ук кыргый гамәлләр бүген дә дәвам итә түгелме соң? Хәзер инде алар "демократия" дигән тәти сүзгә төреп бирелә. «Террорга, ваһһабчылыкка, ислам экстремизмына каршы көрәш» дигән мәкерле хәйләгә яшеренеп, нечкә сәяси алымнар кулланып башкарыла.

Бүген дә Мәскәү үз конституциясен үзе үк тупас бозып, ничек тели шулай кылана, илдәге вак милләтләрнең мәнфәгатен исенә дә аласы килми, алар белән аз гына да санлашмый. Аның җитәкче даирәләре, Сафа җәбер-золымыннан иза чиктергән Сталин хөкүмәте кебек үк, бөекдержавачыл шовенистлар, милли мөртәт маңкортлар кулы белән үзенең колониаль сәясәтләрен үткәрә. Русия, явызлык империясе буларак, һаман да мәхшәр мәйданы булып кала бирә.

... Менә бит, уйлана торгач, әллә кайларга кителгән. Без Нәҗип абый белән әнә шул каравылчы Сафа саклаган урманга утынга менеп бара идек бит әле. Ләкин куркып-нитеп түгел. Абый Сафага Казаннан ниндидер бик зәһәр спирт кайтарып биргәннән соң без урманда үз өебездәге кебек ир-

кенләп, күкрәк киереп йөрибез. Сафа безгә хәтта корыган агачларны да кисәргә рөхсәт итте. Тик башкалар сизмәсен дә, төбе күренеп калмасын, диде. Аларны балчык белән күмеп китәргә кушты. Ләкин бөген бәла шунда: кисеп аударсаң да, алып кайтып булмый. Ярый ла ул өең авыл кырыенда булса, безнеке кыл уртада шул. Кеше күрмәслек итеп яшерен генә эшләү һич мөмкин түгел. Дус бар, дошман бар, дигәндәй, кыңгыр эшең шундук фаш ителәчәк. Ул чагында, Аллаһы сакласын, төрмәгә эләгүең дә ихтимал. Икенчедән, ул кадәр утынны «уфалла»га төяп булмый, арба ватылачак. Ат жигеп бару турында уйлыйсы да юк, төртә арасына кертеп, колхоз эшенә барырлык атлар бармак белән генә санарлык. Ул вакытларда бүгенге кебек машина-тракторлар юк иде шул әле. Утын, печән һәм башка кирәк-ярак кул арбасы белән ташылды. Үзенә дигәндә кеше аттан ким тартмый ул. Төяп ташырлык әйбере генә булсын.

— Әгәр минем башыма,— дип дәвам итте Нәҗип абый,— бу каһәр суккан корчаңгы йокса, мине ФЗӨ дә бер минут та тотмаячаклар. Ул чагында өйгә кайтам була. Тик инде корчаңгы Нәҗип булып. Бу кушамат егет кешегә килешеп бетми инде бетүен. Башка чарасы юк бит аның, шайтан алгыры...

Ул тынып калды. Кырысланган йөзенә караганда, уйлар өермәсендә бөтерелә иде кебек.

— Әй, төзәлер әле бер!— дип, бераздан ачылып киткәндәй булды.

Язмыштан узмышлар юк, дипмс, әллә шагыйрә ханым әйткәнчә, ялгышны төзәтеп булуын расланмы, урманга керер алдыннан Нәҗип абыем башына бәйләгән чүпрәкне йолкып ташлады. Урман аланында үскән ниндидер үлән яфракларын өзеп, теге корчаңгы йоктырасы урынга бәйләп куйды. Язмышына бу каһәрле авыру белән авыру язылма-

ган булган, күрәсең. Ул башка юлны сайлады. Теге зәһәр спиртын күп итеп алып кайтты да, авыл советы рәисе Садыйковны, колхоз җитәкчесе Мансур абыйны берничә мәртәбә шыпырт кына чакырып, яхшылап сыйлады. Майлагач, эш тә хутка китте. Алар кирәкле кәгазь-документлар язып бирделәр һәм без зур йортыбызны, олы яшьтә булуына карамастан буйдак гомер иткән физика укытучысы Габдрахман абыйга сатып, Казанга күченеп киттек.

Бу вакытта Диләфрүз апа да Габделхәй абый белән бик күркәм гаилә корып җибәргәннәр иде инде.

Телгә алынган бу кешеләрнең инде берсе дә якты дөньяда юк. Урыннары Җәннәттә булсын!

Бу язманы очлаганчы тагын шуны да әйтим әле: Нәҗип абысым корчаңгы вакыйгасын әледән-әле исенә төшереп, оялып яшәде. Җае чыккан саен яшьлегендәге бу хата-ялгышын башка берәү исеменнән сөйләгән кебек итеп: «Әнә, хәзер шул җүләрлеге өчен үкенә, вөҗдан газабы кичерә. Намус дигән нәрсә бар икән ул, егетләр!» – дия торган иде.

МИНЕМ ДӘ ЭШ КӨНЕМ БАР

Буласының буыннарыннан билгеле, диләр. Юк, төткән жиреннән өзеп ала торган гайрәтле егет, житмеш төрле һөнәргә ия төвәккәл ир чыкмады миннән. Әнә яшьтәш малайлар кышын кара мунчаларда кәрт сугып, әтиләренең фронтта ничек сугышып йөргәнен көзгеләрдән карыйлар, буразнада махра пыскытып, көч-хәл белән сука өстерәгән күтәрәм атларның сыртын сигездән үргән каеш чыбыркы белән каезлыйлар. Ындырга көлтә кертү, эскерткә салам тарттыру кебек эшләр дә алар кулында. Бигрәкләр иртә өлгерде шул ул сугыш чоры малайлары. Фәһим, Рәфкать кебекләребез «Кызыл олау» илтүдә катнаша. Алар инде кызлар белән хат алыша, хәтта очраша да дип сөйлиләр. Ә мин һаман авыл көтүен көтәм. Аңа кадәр икс сл каз көтүчесе идем. Боларга сигездән үргән каеш чыбыркы кирәк түгел, сүстән бәтергәне дә бик житкән. Оят валлаһи! Бозауларын көтүгә китергән сылукайлар миңа игътибар да итмиләр. Малларын куып жибәрәләр дә, чебиле аяклары белән чыклы үлән аралап, өйләренә элдертәләр.

Жиденче сыйныфны тәмамлаган елны беркөнне, ничектер, минем урынга көтүгә әнием чыгып китте. Мәктәптә сынаулар биргәннән соң туйганчы бер йокласын дигәндер инде. Чынан да, мин торганда тугызынчы киткән иде. Сөт белән чәрәк бәрәңге кәлҗемәсе ашарга гына утырган идем,

өйгә бригадир Салих абый килеп керде. Ул фронтта сул кулын югалтып кайткан иде.

– Рәис энем,– ди бу,– җитәр сиңа егет башың белән бозау койрыгы борып йөрергә! Анда ат караучы Габдуллажан абыең кәтеп тора. Ул сиңа үгез җигәргә булышыр, фермадан тирес түгәрсең.

Нишлисең, әйткәч бармый булмый. Тиз-тиз генә капкаладым да, киттем. Могҗиза бит, валлаһи! Ун яшеннән бирле иненнән көтүче чыбыркысы төшмәгән, «пешмәгән», дип үчекләнүдән башы чыкмаган малай колхоз эшенә барсын әле! Эшсең дә ниндиенә диген! Үгез җигеп тирес түгәргә! Бу инде эскерткә салам тарттыру, яки конвеер тасмасына көлтә салып тору гына түгел. Андый вак-төяк эшләрне малай-шалай да башкара аны! Бәлкем әле, кайбер класстаплар кебек, басудан көлтә дә ташый башлармын, «кызыл олау»ларга утырып ашлык та илтермен. Аннары инде кызлар миңа да мәхәббәт хатлары язмый калмас. Белмәссең, белмәссең...

– Бар,– диде Габдуллажан абый,– алып кил үгезенне фермадан!

Үгезне эзләп азапланасы булмады. Ул анда берүзе калган икән. Башына йөген салып өстери торгач, иярде бу минем арттан. Габдуллажан абый аны көч-хәл белән тәртә арасына кертеп, кырык ялгаулы, җитмеш төйнәүле баулар белән җигеп тә куйды.

Аллаһыга тапшырып, фермага таба киттем. Ундүрт яшемә җитеп, гомеремдә беренче мәртәбә дилбегә тотуым иде. Майланмаган көпчәкләр як-якка ава-түнә пыгырдаса да, аптырамыйм, чүтеки кулда дилбегә. Ә дилбегәне теләсә кемгә тотырмыйлар аны! Дөрес, җаным бик үк тыныч түгел, түгелен. Горурлык хисе күңелне лөззәтләп кытыкласа да, аны шом-шөбһә дә тырнап тора. Ул нәрсәдер сизенә кебек.

Ат абзары белән ферма арасы күп булса, 40-50 адым чамасыдыр. Тирес төяүче апалар сәнәкләренә сөялеп, арба килгәнен көтәләр. Мине күргәч, кайберләре сизелер-сизелмәс кенә елмаешып куйды кебек. Булдыра алырмы бу, янәсе.

– Куй арбаңны монда! – диде Кадрия апа, ишек янын күрсәтеп.

Арбаны ул әйткән урынга куярга берничә мәртәбә маташып карасам да, барып чыкмады, әле килеп җитми кала, әле узып китә.

– И-и, пешмәгән егетләем, менә болай итәләр аны! – дип, Кадрия апа үгезне, йөгәненнән җилтерәтеп, кирәкле урынга китереп тә бастырды.

Мин ары-бире каранганчы, арба тирес белән тулган да иде инде.

–Тарттыр үгезеңне!

Дилбегәне тарткалап, үгезне кузгатмакчы булам, ә ул кымшанмый да, нәләт төшкере.

Кадрия апа янә үгезнең башына тотынды.

– Халисә, тарт әле шуңа берәрне!

Сыртына сәнәк сабы төшкән үгез, әле уңга, әле сулга тайпылып, авыр итеп бер пошкырып алды да, киерелеп алга ыргылды. Кырык ялгаулы бауларын өзеп, тәртә арасыннан чыгып та чапты.

Бауларны ялгап, төйнәп бу киребеткәнне тагын тәртәгә керттек. Арбадагы тиреснең шактыен кире бушатып, җыйнаулашып этә-төртә торгач, ниһаять, коры җиргә чыгып бастык.

– Бар тегермән артына, анда тирес өемнәрен күрерсең, – диделәр апалар.

Киттем. Үгезем як-якка чайкала-чайкала әвеш-тәвеш килеп, әкрен генә атлый бирә. Тегермән арты дигәннәре күп булса ике чакырым арадыр. Якын гына кебек. Ләкин

миңа хәтта шунда җитәргә дә язмаган икән. Йомшак басуга кереп бер-ике адым атлауга үгез тагын коллыктан азат булды. Дилбегәгә икс куллап ябышып, аякларны җиргә тери-тери туктатырга тырышып карасам да, ул башын аска иеп, өстерәде дә, өстерәде. Нигә тыңларга теләмәгәндер, белмим. Үзем көтүдә йөртеп үстергән бозауларның берсе иде бит, югыйсә. Әллә, димен, ул чакларда үпкәләттем, хәтерен куалдырдым микән?

Хурлыклы хәбәр көне-сәгате белән бөтен авылга таралды. Үземнең «пешмәгән»легемне тулысы белән расладым. Бу вакыйгадан соң авылда калу оят иде. Озакламый кирәкле кәгазь-документларны барлап, Казанга китеп бардым.

Бу хәлдән соң ярты гасыр вакыт үтте. 45 еллык тоташ эш стажы белән лаеклы ялга чыктым. Бүген хәләл хезмәтемнең игелеген күреп яшим. Әллә, минәйтәм, авылга кайтып, белешмә-мазар алып килим микән? Минем анда да ярты хезмәт көнем теркәлмичә калды ләбаса. Бәлки пенсиямне арттырып куярлар?..

КАВАЛЕРИСТ

«Һөнәрле үлмәс, һөнәрсез көн күрмәс», дисәләр дә, тормыш кайвакыт бу мәңгелек хакыйкатьнең киресен дә бик дәлилле итеп исбатлап бирә икән ул.

Хәрби хезмәтемне мин Кыргызстан республикасының Памир таулары тарлавыкларында урнашкан Мургаб шәһәрчегендә башлап җибәрдем. Нәрсәгә кирәк булгандыр, икенче көнне үк взвод командирына гражданкада чакта радистлар курсын тәмамлавымны сайрап ташлаганмын. Җитмәсә әле таныклыгымны да күрсәттем.

– О-о, син коеп куйган радист икән инде! – диде ул.

Мунча кереп, солдат киемнәрен киеп алгач, командир мине үз бүлмәсенә чакыртты.

– Сине элемтәче радистлар өзерләү отделениясенә күчердек. Менә бу өлкән лейтенант Калганов. Ул бүгеннән синең командирың булыр, – дип, янәшәсендә утырган чандыр гәүдәле кешегә күрсәтте.

Безнең отделениегә ачлы-туклы елларда җиде сыйныф тәмамлап, чорына күрә укымышлы булып саналган егетләр тупланган иде. Ләкин аларның берсе дә «морзянка»ның ни икәнен дә белми әле. Ә мин беләм! Эштән соң йөреп, алты ай буе укыдым. Тәҗрибәле радистлар кебек асс булмасам да, шактый ук тирәннән үзләштердем.

Взвод командирының элемтәчеләр отделениесе буенча ярдәмчесе ефрейтор Киреенко – кечерәк буйлы, тулы гәүдәле, иягенә таба очлаеп килгән түгәрәк йөзле, ана үрдәк кебек

авып-түнеп йөри торган кеше. Ятсак та, торсак та, ул гел безнең белән. Дөресрәге — без аның белән. Монда ул үзен тулы хокуклы хуҗа итеп сизә. Бер иптәшенең сержант формасын киеп, фоторәсемгә төшкән дә, шуны, мактанып, туганнарына, йөргән кызына салган дип тә сөйлиләр иде. Булгандыр, дан-дәрәҗәне, башкалардан өстен булуны үлеп ярата иде бу хохол егете. Аның канаты астына кергән берничә «сөекле» солдаты исә ялагайлыкта, куштанлыкта үзеннән дә уздырып җибәрәләр иде. «Рыбак рыбака видит издалека» дигәннәре шушы буладыр инде.

Гадәттә, бу иш кешеләр, акылга бай булмасалар да, үзләрен күрсәтергә мөмкинлек чыккан бер генә очракны да кулларыннан ычкындырмыйлар. Командир күзгә чалынганда арт аякларына баскан ялагай маэмайга охшап калалар. Үз вазифаларын тыныч кына акыл-зиһен белән башкаручы сәләтле кешеләрдән көнләшүчән булалар. Төрле юлларга белән алардан өстен чыгарга омтылалар. Кирәксә, көндәшләрен жыйнаулашып тукмап ташларга да күп алмыйлар. Һәм үз араларында бердәмлек тә юк түгел. Ни гажәп, андыйларны командирлар да үз күрә.

Менә шул ефрейтор тәмам каныкты бит мина, каһәре. Әй, татарин, сиңа башкалар кебек укып торасы юк, болай да беләсең, дип, мине көнаралаш кухняга эшкә жибәрә. Аннан бушаган көнәрне казарма идәнен юып, ишегалды себереп үткәрәм. Кыскасы, тәмам эш аты ясап бетерде бу миннән. Солдатлар үзара пышылдашып, миңа бармак төртеп көлешә үк башладылар. Менә сиңа мә, армияга алдан ук һөнәрле булып килгән өчен җәза алам булып чыга. Инде нишләргә? Шикаять белән взвод командирына барсаң, бу отделениедә миңа бөтенләй көн калмас, өстәвенә «жалобщик» дигән ярлык та тагып куюлары бар. Ә командир дигәнем бу хәлне әллә белми, әллә белеп тә, күз йома.

Ләкин, ничек кенә булса да, бу хәл мәңге шулай дәвам итәргә тиеш түгел бит инде!

Кавалерия взводында хезмәт итүче Казан егетләре белән сөйләшеп карадым, алар да төпле генә киңәш бирә алмады. Әле кичә генә гимнастерка киярга өлгергән солдат үзе дә сукыр тычкан кебек бит ул, кая кусалар, шунда чаба.

Озак уйлый торгач, келт итеп башка бер фикер килде. Аллаһыга тапшырдым да, киттем санчастька. Аның начальнигы Надыйров фамилияле татар капитаны булуын ишеткән бар иде. Таныштык. Ул Азат исемле Казан кешесе булып чыкты. Бераз алга китебрәк әйтим, Азат Надыйров гомеренең соңгы көннәренә кадәр Казан поликлиникаларының берсендә баш табиб булып эшләде. Без аның белән еш кына күрешеп, бергә үткән хезмәт елларын искә алга идек.

... Сүземне кыяр-кыймас кына башлап, үземнең моң-зарымны тукми-чәчми сөйләп бирдем.

— Да-а...— дип сузды якташ капитан.— Ефрейторның синең татар булуыңа бәйләнүе сагайтты бит әле. Кем өчендер без һаман да бүкәй икән, ә? Ул бит сине генә түгел, мине дә, гомумән, без – татарларны рәнжетә булып чыга. Нишләргә соң?

Капитан уйга чумды. Мин дә, нишләргә белми, уңайсызланып утыра бирдем.

— Мин, әлбәттә, лейтенант Калганов белән сөйләшермен,— диде ул, ниһаять.— Күршe Мари республикасыннан ул, акыллы егет кебек күренә. Хәлне аңлар дип беләм.

— Ул аңлар да бит, ләкин өлкән лейтенант безнең белән бер казармада тормый шул. Анда ефрейтор һәм аның куштаннары хуҗа. Солдатларның күбесе миңа теләктәшлек белдерсәләр дә, берсенең дә кухняга нарядка барасы, йә ишегалды себерәсе килмәс...

Шунда башыма тагын бер уй китереп сукты.

– Булмаса, әллә Мургабның диңгез өсте тигезлегеннән 3600 метр биеклектә торуын сәбәп итикмс?

– Ничек?

– «Рядовой Сафин климат шартларына ияләшә алмый, башы авырта» кебегрәк белешмә сыман нәрсә әмәлләсәгез, ничегрәк булыр икән?

– Шуннан?

– Шуннан кавалерия взводына күчәрмен. Үзебезнең Казан егетләре дә шунда.

– Мондый очраклар элегрәк тә булгалады. Ләкин бу беткә үч итеп тунны ягу кебек килеп чыга бит. Ә Памирда туннан да кирәк нәрсә юк, туган!

– Әгәр ул тун тәнеңне җылытмаса, ниплисең инде?

– Бүген җылытмаса, иртәгә җылытыр. Әллә кавалериядә җинел дип беләсеңме?

– Үзе егылган еламас, диләр, ничек тә түзәрмен.

– Ярар, әвәл Калганов белән сөйләшим әле, аннары күз күрер.

Берничә көннән мин тагын санчастька бардым.

– Өлкән лейтенант отряд командиры белән сине кавалерияга күчерү турында киңәшләшеп карарга булды,– диде капитан.– Тагын ике айга түзсә, өч ел буе җылы бүлмәдә радист булып үткәрер иде, дип тә өстәде. Тик үзенең ефрейтор белән каршылыкка керергә теләге юк.

– Гаделсезлеккә чик куярга теләми, димәк.

– Ул синең күзлектән караганда гына шулай кебек. Бер кешенең мәнфәгатьләре коллектив мәнфәгате белән туры килмәскә дә мөмкин. Армиядә хәрби тәртип дигән нәрсә дә бар бит әле, ул һәркемнең көен көйләп бетерә алмый. Аннары Калгановның үз стратегиясе һәм тактикасы булуын да онытмыйк, аның да үсәсе, погонына яңа йолдызлар

тагасы килә. Ә инде Киреенко кебекләр – бу эштә аның уң кулы.

Мин инде китәргә җыенган идем. Капитан янә сүз башлады:

– Бер уйлап карасаң, өлкән лейтинант хаклы бит. 40-45 градус салкыннарда, күз ачкысыз буранларда чик буенда унар сәгать сакта тору уен эш түгел. Монда зур чыдамлылык, физик ныклык кирәк. Ә мин сине бу таләпләргә җавап бирәсең дип әйтмәс идем. Радист булып җылы бүлмәдә утыру – өстендә җылы туның бар дигән сүз инде ул. Әллә тыпырчынмыйсыңмы соң?

... Мине кавалерия взводына күчерделәр. Мин Киреенконың бетмәс-төкәнмәс нарядларын үтәп йөргән арада яшь кавалеристлар уку-өйрәнү, ат өстендә күнегүләр ясау буенча хәйран алга киткән булып чыкты. Аларны куып җитү өчен гөрләвек-гөрләвек тир агызырга туры килде.

Ат өстендә катлаулы күнегүләрне цирк артистлары дәрәҗәсендә диярлек башкара алуын күнелдә горурлык уятса, «конная подготовка»дан соң ике сәгатькә сузылган тактика дәресләре жанны ала инде. Бәлкем ат корсагы кочып, камыштай бөгелеп катқан аякларны турайту өчен ул шулай кирәк булгандыр да. Ләкин ияр каешына ышкылып чиләнгән ботлар, бәрелгән-кырылган күт битләре белән стройда йөрү, бигрәк тә хәрби дирбияне иңбашына асып, бил каешына тагып йөгерүләр, ай-һай, бер дә җинел эш түгел иде шул.

Әйе, кавалерист булу, ат менеп кукыраеп йөрү генә түгел икән. Моның өчен башта гажәп зур гырышлык белән күнегүләр ясап, осталыгыңны камилләштерү мөһим.

Җайдакның уңышы атыңны яхшы һәм дөрес итеп иярләүдән башлана. Атның сыртында бернинди дә сыдырылган, күпкән җәрәхәтләр булырга тиеш түгел, аны чиста,

коры итеп сөртеп, иярне җайлап-уңайлап саласың. Өзәңге кирәгеннән артык тарттырып бәйләнгән булса, атның тыны кысыла, бу хәлдә ул рәхәтләнеп йөри дә, иркенләп чаба да алмый. Монда инде аның сыртын сержантның каеш чыбыркысы каезлаячак. Әгәр инде киресенчә, каеш-баулар бушрак итеп бәйләнсә, ат өстеннән иярең-ниең белән бергә шуып төшкәненне сизми дә калырсың. Мондый хәлләр булмасын өчен үз атыңның холкын-характерын белү кирәк. Кайбер ат өзәңге каешын бойләгәндә, хәйләгә керешеп, корсагын кабартып куя. Тиктомалдан бөтен тәнеңне будырып йөрү кемгә рәхәт инде ул?!

Атны иярләгәч, тезгененнән алып, аны матур сүзләр белән мактый-мактый, җайлап кына абзардан алып чыгасың. Атыңның сул ягында торып, стройга басасың. Командирның "По коням!" дигән командасы ишетелүгә ияргә уктай атылып менәргә тиеш буласың. Әлбәттә, тиеш булганны төгәл үти алсаң. Нәкъ шушында башлана да инде ыгы-зыгының зурысы. Берәүләрнең аты хуҗасы менеп атланганчы ук кузгалып китә, икенчеләренеке атландырасы килмичә борсалана. Әнә Макаровның кылычы өзәңге арасына кереп кысылган. Әгәр шулай эшләргә кирәк булса, син аны анда кертә дә, пушылай чыкмаслык итеп кыстыра да алмыйсың. Ә ул ниндидер могҗиза белән кергән дә кысылган. Аны алганчы вакыт уза, башкалардан артта каласың. Димәк, арт саннарын күтәрә алмый калганнар һәм әлеге дә баягы кылычларына абынып соңарганнар белән берәттән атка атлану күнегүләрен кабатларга мәҗбүр буласың. Мен дә төш, мен дә төшләр күз алларың караңгыланганчы дәвам итә. Чөнки чын кавалерист атка «Эһ» дигәнче атланырга тиеш. Баста! Билендә кем утырганнын, өзәңгене нинди куллар тоткынын ат бик яхшы тоемлый. Үзеңне аның хуҗасы итеп таныта алмасаң, ул сине санламый, кушка-

ныңны үтәми башлый. Син аңа карата ягымлы да, шул ук вакытта таләпчән дә булырга тиешсең. Шундый җайдакларны ярата, тыңлый атлар. Взводның калган өлеше манежга юнәлә. Аны берничә тапкыр әйләнеп, атларны «кыздыргач», уртага баскан командир озын чыбыркысын уйнатып, "Учебной рысью ма-а-арш!" дигән әмер бирә. Бу инде, җанкисәгем, синнән чын кавалерист ясауның мөһим бер этабы башланды дигән сүз. Җайдак, аякларын өзәңгедән чыгарып, туп-туры утырган хәлдә, үз авырлыгы белән арт санын бәрә-бәрә иярдә сикергәләргә тиеш була. Егылып төшүдән куркып, иярне кочып алган ботлар ышкылып сыдырыла. Шул рәвешчә манеж тирәли әйләнәсең дә әйләнәсең. Артын төя-төя чапкан җайдакның бер-берсенә бәрелә-сугыла биешкән эчке әгъзаларыннан бөтен шлаклары коелып, тәне чистарып кала.

Күнегүләрнең бу өлешен җенем сөйми иде. Чөнки әле кичә чиләнгән күт битләре, суелып беткән ботлар төзәлеп тә җитмәгән. Син аларның кипшерә башлаган элпәләрен сертып, кутырларын куптарырга тиеш буласың. Шулай берникадәр вакыт изалангач, юка, нәфис бот тиреләрең эт каешына әверелә.

Бу сырхауның ни дәрәҗәдә булуы атыңа да бәйле. Әгәр ул песи кебек йомшак, яшь киленнәр сыман сак, җайлы йөрешле булса, син бәхетле, аттан уңдым дип әйтә аласың.

Минем атым үзем шикелле тәбәнәк, көрән төстә, халкыбыз әкиятләрендә мактalган кырыкмыш тайга охшаган иде. Төс-кыяфәте, буй-сыны кеше кызыгырлык булмагач, хуҗа табылмыйча, абзарда ята биргән. Монгол токымына тартым шушы атым шулкадәр сак, йомшак чаба иде ки, әйтерсең ул йөзеп бара сыман. Читтән карап торышка шыксыз үрдәк бәбкәсенә охшаган булса да, күнегүләрне ул җаныгәне белән бирелеп, зур тырышлык белән башкарды. Миңа

калса, башкалардан көнләшеп, кечкенә булсам да, эчем тулы төш кенә дигән сыман йөри иде атым. Аның шушы күркәм сыйфатлары миңа кушаяклап томырылып чапкан чагында корсагы астыннан өзәңге бавы буйлап икенче якка үрмәләп чыгарга һәм янәдән ияргә менеп утырырга, чабып барган шәпкә ат остендә «кайчы» ясап, артка борылырга һәм мишеньга төбәп мылтыктан атарга мөмкинлек бирде. Ин авырлардан саналган бу күнегүләрне җиренә җиткереп үтәүчеләр сирәк иде. Монда инде үземнең дә кечкенәдән үк агач башына оста үрмәләвем, спорт белән шөгыльләнүем файда биргәндер.

Әлбәттә, күнегүләрнең берсе дә җиңел түгел, һәрберсенең үзенә хас катлаулы ягы бар. Шул кыенлыкларны егетләрчә үтәр өчен түземлелек тә, максатчан кылык та, ихтыяр көче дигәне дә кирәк.

Менә без атларыбызны янәшә куеп, иптәшләребезнең киртә-чокырларны сикереп үтүләрен күзәтәбез. Алардан ерак түгел, чыбыркысын тотып, сержант Ростәм Яушев баскан. Ул үзе бу күнегүләрнең барысын да зур осталык белән башкара. Горнизонда аңа тиңләшерлек кеше юк. Аның көч-куәте ургып торган тимер мускуллары хәтта гимнастеркасы аша ташып чыккан. Алар һәрвакыт биеп торалар кебек. Ятимнәр йортында тәрбияләнеп үскән бу татар егете борынгы грек сыннары кебек үзе бер сөнгать әсәре иде. Без күнегүләрне яхшы итеп башкарсак, аның какча йөзе ачылып, кыйгач иреннәре җәелеп китә. Әгәр инде булдыра алмасак, утырган аты өстендә үзенә урын таба алмый башлый. «Колбаса ты ливерная!» – дип орыша безне. Бу аның эчке бер әрнү белән әйтә торган сүзе.

Ниһаять, чират миңа килеп житте. Атымның муеныннан сөеп алдым һәм без алга ыргылдык.

– Повод, отпусти повод!

Сержантның бу сүзләре аңыма барып житкәндә мин инде сикереп үтәсе киртәнең теге ягында тәгәрәп ята идем.

– Колбаса ты ливерная! Син аңгыра түгелдер бит, тагын кабатлыйм: атың сикерер алдыннан йөгән сабагын бераз бушата төшәргә кирәк. Югыйсә атның алга сузылган муены сине иярдән йолкып, үзе белән ияртәчәк. Нәтиҗәсен үзең күрден. Аңладынмы?

Мин жирдән күтәрелгәндә монгол атым, гаепле сыман башын түбән иеп, янымда басып тора иде. Без күнегүне кабатларга тагын чиратка бастык.

Чират Казан егете Олег Кардашовка килеп житте. Аның аты минекенең нәкъ киресе инде: зур гәүдәле, адымнары эре, һавалы. Чапканда тоякларын лап-лоп басып, жайдагын сикертә-чөя. Шуңа да Олегның сыдырылмаган жире юк иде. Тәбәнәк буйлы бу егет үзенең айгыры өстендә чүрәкәй генә булып тоела. Бу күнегүләрне жаны-тәне белән сөймәгән Олег, атының ялына чытырдатып ябышкан хәлдә киртәгә якынлашып килә. Хужасының өстенлеген санламаган айгыр кинәт алгы аякларын терәп туктап калды. Жайдак, ат сикерәсе киртә аша очып, жиргә барып төште. Сыртында сержантның зәһәр камчысын татыган айгыр да «эһ» дигәнче Олег артыннан сикерде. Ничек әле аның өстенә басмады, хайван.

– Колбаса ты ливерная! – дип пысылдады сержант.

... Очларына талчыбыклар беркетелгән казыклар алдына килеп бастык. Бу күнегүне башта сержант үзе күрсәтеп бирде. Аңа карап торсаң, сокланмый мөмкин түгел. Ул ике кулына ике кылыч алып, өзәнгегә басты һәм үзе кебек елгыр кара атын кушаяклатып чаптырып китте. Аның яшен тизлеге белән ялт-йолт иткән кылычлары казык башларындагы талчыбыкларны кисеп тә төшерде. Алар өстән аска таба кыеклап шулкадәр оста киселгәннәр иде ки, әйтерсең

моны кеше түгел, ә шушы эш өчен койлөнгөн махсус станок башкарган. Ә мин бу күнегүне үти алмыйча изаланам. Йә атым казыклар рөтен узып киткән була, йә кылыч кулдан төшеп кала. Хәтта талчыбыкка суккан очракта да ул киселми, кәһәр. Инде өзәңгегә дә дөрес басам шикелле, тезгенне дә атның башы бераз күтәрелебрәк торырлык итеп кыска тотам. Юк, булмаса булмый бит ул. Кабатларга, тагын, тагын кабатларга туры киләчәк. Минем ише булдыксызларны манежга көндезге йокыларыннан өзеп алып чыгалар. Башкалар ял иткәндә без, пешмәгәннәр, күнегүләр өйрәнеп интегәбез.

«Конная подготовка»дан соң, әйткәнемчә, тактика дәресләре башлан. Тешне кысып булса да түзәсең инде.

— Запевай!— дип команда бирә командир.

По долинам и по взгорьям
Шла дивизия вперед...

Җыр күңелләрне күтәреп җибәргәндәй итә. Кан саркып торган яраларның әрнүе онытылгандай була. Ул арада яңа фәрман ишетелә:

— Га-а-зы!!!

Противогазларны киеп, чокырларга төшеп яшеренәбез, таш артларына посабыз. Ул да булмый, «В атаку ма-а-арш!» дигән команда килә Без, противогаз кигән йөзсез солдатлар, тауга ташланып, өскә үрмәли башлыйбыз. Противогазның ян-яктагы керешләре тир белән биткә чәпелдәп ябышкан, күз турындагы пыяласыннан эре-эре тамчылар тама, алда ни барын һич күреп булмый. Болай да 38 процент кислород җитешмәгән бу Мургаб җирендә противогаз бугазы аша саркып кергән һава гына көч бирә алмый. Тын кысылудан күз аллары карангылана, аңны югалткан кебек буласың. Противогаз керешенияк астыннан умырып, берничә йотым саф һава сулап аласың. Моны командир күрсә, чираттан тыш наряд алдың дигән сүз. Ул, гадәттә, бәдрәф чистарту була. Анысын да әле солдатлар йокыга яткач эшлисең.

Ниһаять, тыннарыбыз бетеп, таш өсләренә авабыз. Чалгы белән кыркып ташлангандай түнгән хәлсез солдатлар тау өстеннән йә корсакларында шуышып, йә тәгәрәшеп, аска коелалар. Аларның күзләре акаеп, тонып калган, йөзләреннән ермак-ермак тир ага.

Бераз ял итеп, хәл алгач, кайчандыр, бездән күп еллар элек хезмәт иткән солдатлар казый башлаган окопларны чокырга керешәбез. Әйе, әйе, без аны фәкать чокый гына алабыз. Чөнки монда корәк батырып казырлык җир юк. Һәр тараф тау-ташлардан гыйбарәт.

Төшке аштан соң бер сәгать йокы ялы бирелә Тагын конная подготовкага алып китмәсәләр, әлбәттә Бу инде хәтере калмасын өчен генә йокы дип әйтерлек бер нәрсә була. Әле генә сеый башлыйсың, ул арада дневныйның «По-одъем!» дип кычкырган тавышы ишетелә Кургашындай авырайган күз кабакларын сержантның «Выходи строиться!» дигән сүзләре ачып җибәра Ике-өч минут үтүгә син инде командир билгеләгән урында сафта басып торасың. Әгәр аяк чолгауларын рәтләп урарга өлгермәсәң, үзеңә үпкәлә Шунда ук ике сәгатьлек «Выше ноги, шире шаг!» дәресе башланачак. Устав кушканча йөрергә, гәүдәңне төз тотып, кулыңны уң як чигәгә куеп честь бирергә өйрәтәчәкләр. Әгәр шап-шоп итеп атлый алмасаң, бу дәреснең синең өчен дүрт сәгатькә сузылуы да бик ихтимал. Инструкторларең рәхәтләнеп ял иткәндә гарнизон ишегалдын аркылыга-буйга «раз-два»га атлап йөрисең дә йөрисең. Армияда шулай: белмәсәң — өйрәтәләр, теләмәсәң – мәҗбүр итәләр. Шулай булмаганда, дошманыңны жиңү шатлыгы тәтемәячәк.

Ләкин солдат томышын ниндидер устав кысаларына

гына кертеп бетереп буламы? Юк, һич тә юк! Чөнки тормыш дигәнең гажәп катлаулы, бихисап киң төшенчә. Әллә нинди устав-кагыйдәләр язсаң да, аның үз тәртибе, үз кануннары бар. Юк, мин боларны кемнедер куркыту, гайрәтен чигерү өчен язмыйм. Солдат хезмәтен һич кенә дә каралтып күрсәтәсем килми. Иза-газаплар, кыенлыклар кичеп, авырлыкларны шыңшымый-зарланмый гына җиңеп чыккан яшь егетләр әнә шулай ирләр булып чыныгып җитә. Андыйларны тормышның зилзиләләре, җил-давыллары да куркыта алмас. Безнең бабайлар юкка гына:

Әй, нужалар, нужалар,
Безнең баштан узалар.
Нужа күрмәгән егетләр
Нужадан да хуже алар,— дип җырламаганнардыр.

Җылы, иркен бүлмәләрдә «морзянка» тукылдатып утырган «армия интеллегенциясе» — радистлардан һич кенә дә көнләшмим. Тормышта һәр кешенең үзенә баеклынган урыны бар. Аны үз вакытында сиземләп, шул үзеңә тиешле урыныңда кешеләргә яхшылык кылу – һәр намуслы бәндәнең бурычыдыр.

Шулай ук һәр нәрсәнең уңай һәм тискәре яклары була. Радистлар кичләрен дә һаман шул «морзянкалары» белән баш катырсалар, без, якташлар, бергә җыелышып гармунда уйнаштык, биештек, көлештек. Әйе, солдат дигәч тә, ул да туктаусыз эшләп торучы механизм түгел, аның да ял сәгатьләре бар, ул да, башкалар кебек үк, уйный-шаяра, көләкүңел ача. Андый ял сәгатьләре, гадәттә, кичке аштан соң була. Көндезге тузаннарны кагып, күнитекләрне көзгедәй ялтыратып, чиста гимнастерка киеп, казарма алдындагы эскәмияләргә чыгып утырабыз. Памирда кичләр салкынча булса да, әлегә яшьлек дәртен сүндерә алырдай көч тума-

ган! Шушы күңелле җыенда сөйгән ярлардан килгән хатлар укыла, кадерле хатирәләр искә алына, барысы да уртага салып сөйләшең, хәл ителә. Монда солдат та, командир да бер дәрәҗәдә калып, якын кешеләргә әйләнә. Шуңа күрә политбүлек офицерлары мондый чакларда безнең арада буталып, үзләренә кирәкле мәгълүмат җыя иде.

Безнең взводтта Сарман якларыннан Ильяс Ибәтов дигән егет хезмәт итте. Урта буйлы, нык бәдәнле, чуерташтай шоматыгыз тәнле, һәрвакыт көләч йөзле, бик тә ягымлы кеше иде ул. Аның күзләренең зәңгәрлеге шулкадәр саф, карашы якты иде ки, шул күзләрен тутырып бер караса, офыклар киңәеп киткәндәй була иде. Ильяс гарнизонның рухы булды. Гомерлек юлдашы хромкасын бер сайратып жибәрсә, бөтен гарнизон аякка баса. Татар егетләре бигрәк тә инде. Мин дә бит кечкенәдән үк тальян гармунда уйнап үскән малай. Икешәр тәүлеккә сузылган туйларның башыннан ахырына кадәр туктаусыз күрек тарткан чаклар да булгалады. Лекин минем уйнау белән аның уйнавының чагыштырмасы – җир белән күк арасы. Ул һәр көйнең бормалы яперакларын почмакларына кереп, аның асыл мәгънәсен гажәеп аһәңгә төреп яңгырата. Шуның өстенә ул көйләрне үз ягының үзенчәлекләре, башка төбәкләрдә булмаган аерым бормалар-мелизмнар белән дә оста итеп бизи белә. Ул «Шахта көе»н сызып җибәрсәме? Көйгә салынган моң-зарлар, сагыш-сагынулар бөгырьләрне телгәләп үтә. Ильяс бу авазларны шахталарның караңгы, тирән базларына төшеп, кешеләрнең үги-ятим күңелләреннән алып менә кебек. Ә инде дәртле бию көйләре уйный башласа, сикергәләп биеп киткәнеңне сизми дә каласың. Без атта йөреп кырылган-сыдырылган җирләребезне онытып, күмәкләшеп биибез, сикерешәбез. Шунысы гажәп: теге, «армейская интеллегенция» безнең бу

тамашада катнашмый иде. Килгәннәре дә читтән генә карап торудан ары узмады.

«Армияга барсаң иде

Сөйгән ярларың белән», – дип җырласалар да, анда күзләрен төрәзәдән алмый, кайнар ашын суытмый көтеп торучы кадерле әниең дә кочагын җәеп каршы алучы сөйгән ярың да юк шул. Әзергә-бәзер булып, «ашау – байдан, үлем – Ходайдан», дип кенә ята алмыйсың. Бөтен эшне дә үзеңә башкарырга туры килә Ашарына да пешерәсең, керен дә уасың, ертыгын да ямыйсың, төймәләреңне дә тагасың. Казарманы да, кунак көткән хуҗабикә кебек, ялт иттереп юып куясың.

«Әллә каян күренеп тора,

Солдатта булган диләр», – дип язган бит, әнә шагыйрь дә

Бу бигрәк тә чик сакчыларын күздә тотып әйтелгән кебек. Чөнки безнең эшебезне кемдер килеп эшләр дип өметләнергә урыныбыз юк. Чик сакчыларының хезмәте – үзләре генә белергә тиешле серле хезмәт. Монда чит-ятларның булуы мөмкин түгел. Без тәүлекнең теләсә-кайсы вакытында чик сакларга китәбез. Күктән таш яуса да, сакта булабыз. Бездә – катгый хәрби тәртип, аптектагы кебек төгәллек. Хәтта ат абзары да зур тырышлык куеп, вакытында чистартылган булыр. Без ул якын дустыбызны вакытында ашатабыз, эчертәбез, тәннәрен кыргычлый-кыргычлый чистартабыз, юабыз. Командирның ап-ак чүпрәге ат төненә ышкып алганда аз гына тапланып китсә дә, бу кыру, чистарту, юууларны кабат-кабат башкарырга мәҗбүр булабыз. Атланып йөрисең икән – тиешле хәерен дә бир, рәхмәтле дә була бел. Һәм белә дә идек. Ашханәдә бирелгән шикәребезнең бер өлешен аңа каптырдык, кесәләребезне тутырып ипи сыныклары алып килергә дә онытмадык. Үткән-барганда,

урлап булса да, солы салып чыгу – гадәти күренеш иде. Ә инде үзеңне ат абзарына дневальный итеп билгеләсәләр, Такташның Мохтар карты кебек, солыны да, печәннең йомшак, хуш ислесен дә үз атыңа күбрәк саласың. Бу көнне ул синең кунагың була.

Мин дневальный булган көннәрнең берсендә ат абзарына Ильяс килеп керде. Тәмәке кабызып, хәл-әхвәл сорашып торган бер мәлдә Ильясым йөзен читкә борып, үксеп елап җибәрмәсенме.

– Нәрсә булды? Әллә өйдәгеләрдән берәр күңелсез хәбәр алдыңмы?

– Юк. Барысы да исән-сау, Аллаһыга шөкер, – ди бу.

– Соң, нәрсә дип елыйсың, тик торганда?

– Рәис дус, мин атлар абзарында аунап үскән малай, үлеп яратам мин аларны. Хәтта менә шушы тирес исе дә рәхәтлек бирә күңелем җырлый, җаным бии башлый сыман. Мин аларны ашатасым-эчертәсем, яратасым килә Әгәр мөмкин булса, мин ат абзарыннан бер дә чыкмас идем. Ә сержант мине монда җибәрми. Башка нарядларга куйса куя, ә монда – юк. Сәбәбен һич кенә дә аңламыйм. Нәрсә дип болай эшли ул? Югыйсә, гаебем дә юк бит инде.

Мин нәрсә дип әйтергә дә белми аптырап калдым. Карадим, бу гаделсезлекне. Мине нинди дер хохол ефрейторы башымны кухнядан чыгармый газаплады, Ильясны шашып яраткан атлары янына җибәрми иза чиктерәләр. Сержантыбыз үзебезнең татар егете ләбаса. Нәрсә бу? Сержант Яушевка ни җитми?

Һай, бу кеше дигәннәрен, нигә шул кадәр рәхимсез була икән? Шушы өч көнлек дөньяның ләззәтен тоеп, бер-беренә игелек күрсәтеп яшисе генә бит, югыйсә. Юк шул, үзең кебек кардәшеңә этлек күрсәтеп, кыерсытырга кирәк.

Бераздан Ильяс тынычланган кебек булды. Ул тагы тәмәке төреп кабызды.

– Рәис дус, әгәр ачуланмасаң, атларның асларын үзем чистартыймчы?

Мин нәрсә дип әйтергә дә белми торган арада, Ильяс себерке, көрәк алып, эшкә дә кереште. Мин аның җитезлеген, өлгерлеген күреп, сокланып карап тордым. Ул бу эшләрне шул кадәр оста итеп, рәтен-җаен белеп башкарды. Ильяс эшне җиренә җиткереп, булсын дип, үзенә бер төрле канәгатьлек алып эшли. Гармунында уйнаган кебек итеп. Ул миңа төне буена җитәрлек эшне төгәлләп тә куйды. Бер очтан атларга печәнен дә салып чыкты.

– Син дневальный булып торган чакта килсәм, ничек булыр икән?

– Әлбәттә кил, Ильяс дус. Мин шат кына булырмын.

Ат җанлылык срак бабаларыбыздан мирас булып, буыннан-буынга күчеп килә татарга. Бу күркәм гадәтләрне безгә Бөек Дала үзе индергән!

КИЯҮСЕЗ ТУЙ

Ул елны минем туган көнем гомер буе көткән бәхетемнең дә туган көне булды.

Дус егетләр белән тыйнак кына табында кәеф-сафа кылып утырганда өебезгә туганнан-туган сеңдем Наилә килеп керде. Үзе белән дус кызын да ияртkән.

– И-и, мактап кына йөрисез икән! Өчпочмакларымны мичтән алып торышым гына ие, – дип шатланып каршы алды аларны әнием. Без дә бер-беребезгә карашып куйдык. Ни әйтсәң дә, кызлар белән күңеллерәк инде.

– Рәис абыйның туган көнендә мич ризыклары пешми калмас, сыйланып кайтырга исәпләп килүебез, – дип, шаяртып алды Наилә.

Кызлар килеп утыргач, табын ямьләнеп, нурланып китте. Әйтерсең, аңа гүзәл гөлләр бәйләме менеп кунаклады. Егетләрнең дә йөзләре яктырды, телләренә сандугач кунгандай булды. Хәтта бер кәлимә сүз ишетергә интектергән Мирсәет тә ачылып, төрле мәзәкләр сөйләп көлдерә башлады.

Әнием өстәл башында кайнап утырган зур ак самавырыннан хуш исле үләннәр салып ясаган чәйне кунакларга өләшә торды.

– Мин әйтәм, – диде Рәфкать, – шайтан суы чөмермы дә күңелле итеп утырып була икән табында!

– Рәис абый гармунында уйнап җибәрсә ул тагы да ямьлерәк булыр әле.

– Туган көнне иртәгә дә дәвам итәбезме әллә соң? Күңелле җирдән китәсе килмәс дим.

– Бик әйбәт булыр, – дип тагын да ачылып китте әни. – Ризык күп. Аш та салып җибәрдем. Улымның дус-ишләре белән бүлай матур итеп утыруын күрү мина да күңелле. Аның туган көне... бүген булмаса да.

Аның бу сүзләреннән аптырашып калдык. Сорамасак та, барыбыз да җавап көткәнен сизенде әни.

– Улым 1934 нең ураза гаете көнне туды, – диде ул. – Әтисе Арчага барып, 1935 елның гыйнварында туды дип, язу алып кайтты.

– Ә 1934 елның ураза гаете кайчан булды икән соң?

– Анысын инде үзегез исәпләп карагыз. Ураза һәм Корбан гаетләре һәр утыз өч ел саен бер үк көнгә туры килә

– Димәк, 1967 елның Ураза гаете көнне мина утыз өч яшь тулган көн, ягъни минем туган көнем була. Барыгызны да туган көнемә кунакка чакырам. Онытмагыз! – дидем мин.

Алга китеп шуны да искәртим: 1967 елда да, 2000 елны алтмыш алты яшь тулган көндә дә Ураза гаетләре 27 декабрьгә туры килде.

– Ул көнне дә бүгенгедәй күркәм итеп, хәмерсез генә уздырырбыз, – диде Рәфкать.

– Ураза гаете көнне авыз күтәреп аракы эчеп утырмабыз инде, иншалла, – диде Наилә

Вакытында үзенең сихри моңы белән тирә-як авыл кешеләренә рухи рәхәтлек биреп, бәйрәмнәрдә, мәҗлес-кунакларда аларны җырлаткан-биеткән әти тальянын кулыма алдым. Бу гармунның тарихы инде 1915 елларга үк барып тоташса да, аның яңгыравыклы җиз телләре әле бүген дә моң тулы. Әнием өйдә чакта мин аны уйнамаска тырышам. Чөнки гармун авазы, аның күңелен тетрәндереп, моңсагышка сала, әтием белән бергә үткән елларны исенә төшерә. Андый вакытларда ул аулакка посып, үкси башлар иде.

Гармун сайрады да сайрады. Шул чорның яратып җырланган «Рамай», «Шахта», «Таһир-Зөһрә», «Яшь наратлар», «Уфа юкәләре», «Олы юлның тузаны», «Оныта алмыйм» җырларын кат-кат җырлап, күңел ачтык.

Әй, гомерем буйларына Рәйхан,
Оныта алмасам нишләрмен...

Бу юлларны үзенә тиң күреп яраткан иркәсен җуйган җаным, мәхәббәт ярасыннан сыкранган йөрәгем гомерем буе кабатлар шикелле.

Тукта, мәҗлескә сәнләм белән бергә килгән кунак кызы Сания турында бөтенләй онытып җибәрдек түгелме? Бу кыйссаның төп каһарманы нәкъ менә ул ләбаса.

Мин җыр белән мавыккан кунакларыма сиздермичә генә, каршымда утырган аксыл көләч йөзле, фирүзә кебек зәңгәр күзле, маңгай өстендәге чәчләре дулкынланып киткән әлеге чибәргә күз төшереп алгалыйм. Ләкин никадәр генә яшерергә тырышсам да, Саниянең бераз моңсу, ләкин ягымлы күз карашлары белән һаман очраша тордым.

Ул арада кызлар кайтырга да җыена башлады. Егетләр дә кул сәгатьләренә караштыра.

– Кунак булсаң, тыйнак бул, дигәндәй, вакыт җиткән икән шул, – диде Рәфкать.

– Рәис абый, бүген тугап көнең булмаса да, безне өйләребезгә озатып куйган көнең булсын, йәме, – диде Наилә уенычыны белән.

Егетләрне озаткан арада кызлар әнигә табынны җыештырырга, савыт-сабаларны юышырга булыштылар. Соңыннан без өчәүләп Яңа бистәгә юл тоттык.

Наилә сәнләм әтисе Насыйбулла җизни, әнисе Зәйнәп

апа, энесе Наил белән Яңа бистәнең М.Гафури урамында яши иде. Ишегалларының түрендә тагын бер йорт бар. Анда Саниянең җизнәсе Насыйбулла хатыны Марзия апа белән яшәде. Сания исә Шәле авылыннан килеп, җизнәсе-апасы өендә торып, итек басу комбинатының ашханәсендә кассир булып эшли икән. Яңа бистәдә безнең жизнине олы Насыйбулла, Саниянең жизнәсен тулы Насыйбулла дип атап йөртәләр иде. Чөнки ул зур гәүдәле, олпат кеше иде. Алар икесе дә хөрмәткә лаек, ихтирамлы зат булдылар.

Алтынчы номерлы трамвайның соңгы тукталышыннан соң бер тыкырык арасы заманында кырмыска оясы кебек мәш килеп тора иде. Хәзер бу урыннарда Төгәл машина төзү заводының административ биналары, цехлары урнашкан. Х.Ямашев исемендәге мех комбинаты чатындагы «пивнушка»дан ир-атлар беркайчан да өзелеп тормады. Бу «көфер почмагы»ида кочаклаштылар да, пычаклаштылар да. Мех комбинатында җитештерелгән барлык төр әйберләрне монда арзан бәягә сатып алырга яки кирәк кадәренә заказ бирергә мөмкин иде. Бу әйберләрнең барысы да бокеләре шалтшолт килеп, туктаусыз ачылып торган аракы шешәләре, агач мичкәләрдән ургып чыккан сыра күбеге эчләренә кереп, юкка чыга торды. Биредә шәһәр хәбәрләренең иң яңаларын, булачак үзгәрешләрнең иң төгәлләрен, серләрнең иң яшереннәрен белергә мөмкин иде. Көтүдән кайтмый калган малларны эзләргә чыккан хуҗабикәләр кебек, хатын-кызлар өйләренә вакытында кайтмаган ир кисәкләрен шушында килеп, җиткәләп тә, сөйрәп тә алып китәләр иде. Ләкин, нәрсә генә булса да, ни генә сөйләнсә дә, башкалар өчен бу хәлләр сер булып кала бирде. Яңа бистәнең үзенең яшәреп сере, үзләре генә аңлаган теле, үз гореф-гадәтләре, үз кануннары бар иде. Халык боларга карата ихтирамлы булды, аларны изге кануннар итеп хөрмәт итте. 1950-52 елларда Тукай

урамындагы җиденче һөнәр училищесында укыган чакларымда апа-җизниләрдә еш булдым, шуңа күрә Яңа бистәнең үзенә генә хас тормышы белән беркадәр таныш идем.

...Гыйнварның үзәкләргә үтәр салкын коннәре бер-бер артлы узып та китте. Сания белән без тагын Совет Армиясе көнендә генә күрешә алдык. Һәм бу очрашу безнең араларны тагын да жылытты. Шуннан соң без еш күрешә башладык. Сания күркәм хатыклы кыз булып чыкты. Аның һәр эшнең җаен-рәтен белеп, чиста-пөхтә итеп башкаруына күрше-тирәләр сокланса иде. Зәйнәп апам килгән саен аның уңганлыгын һәм чибәрлеген мактап телгә алмый калмады. Әниемнең дә тел тегермәне Яңа бистә якларыннан искән җилдән әйләнде. Сания белән үзара мөнәсәбәтебез дә көннәнкөн нык бары. Берәр көн күрешми торсак, бер-беребезне юксына, сагыныша башладык. Инде бер-беребезнең өлешенә тигән көмеш икәнлегенә шик юк иде.

8 Март көнне бүләкләр алып, туры үзләренә барып кердем. Саниянең шатлануы әйтеп бетергесез иде. Йөзеннән кич буе елмаю китмәде. Мин дә аның зәңгәр күзләренең тылсымлы карашын, кечкенә генә борынының алсу көләч йөзенә шул кадәр килешеп, аны бизәп торуын, чамасын белеп кенә, кыйгачлап уелган ирennәре арасыннан энҗе бөртекләре кебек ап-ак тешләренең җемелдәп торуын беренче мәртәбә күргән сыман, аңа табынып утырдым.

Иннек тидермәсә дә, һәрчак кызылсу ирennәрендә татлы бер тәм, үзләренә тартып торган яшерен сер бар иде. Бәлкем аның шушы табигыйлеге әсир иткәндер дә Шәфәкъ алсулыгында косынган офыкларның сихри гүзәллеген күпме карасаң да карап туя алмый сокланасың ич. Саниянең ирennәре дә шәфәкъ алсулыгына манылган кебек иде. Мин аларның сихри тәмен гомерем буе татып яшәдем. Аның шушы табигый матурлыгы, гаилә тормышын дөрес итеп

алып бара белүе мине тугрылыклы ир итте, үрләргә менәргә этәрде.

– Яз җитте. Тиздән сыерчыклар да килеп җитәр. Мин оя ясап, өй кыегына элеп тә куйдым инде, – дидем кичләрнең берендә.

– Миңа да бер оя эзләргә туры килмәгәе әле...

– Ничек алай? Оян бар ич.

– Шулай. Әлегә тәгаен билгеле түгел. Ачыкланган әйтермен.

Саниямның йөзе кинәт үзгәреп китте, моңсуланып калды. Аның борчулы зәңгәр күзләре миңа текәлде. Мин аны кочагыма алып, күкрәгемә кыстым.

* * *

Саниямнең «Үземә оя эзләргә туры килмәгәе әле», дию юкка гына түгел икән. Тиздән Марзия апаның кызы белән кияүгә читтән кайтып төшәчәкләр. Аларны прописка керту өчен Саниянең пропискадан төшүе кирәк ди. Бу турыда ишетүгә, тимерне кызуында сугарга булдым: «Бездә урын күп. Әни дә мин. Бул әниемә килен!» – дидем. Шуны гына көткәндәй, Сания дә җавапны озак көттермәде.

– Риза! – диде, үзенә бер төбәккәллек белән. Миңа эссе-суыклы булып китте. Менә моңысын мин хәзергә кадәр аңлый алмыйм. Әллә гомергә бер килә торган шушы җаваплы мизгелнең кинәт кенә бер каршылыксыз чишелешенә күңел әле әзерлексез булганмы? Шул каушатып җибәргәнме? Әллә шушы кадәр җаваплылыкны үз өстенә алган йөрәк моңа әзер икәнен сиздергәнме? Ничек кенә булмасын, мин утта яна идем.

Санияне капка төпләренә кадәр озаттым да, артыма борылып карый-карый трамвай тукталышына йөгердем.

Ана йөрәге иң сизгер приборлардан да сизгер икән ул. Йокламаган иде, кечкенә ак самавырын кайнатып каршы алды. Мондый хәлнең әле булганы юк иде югыйсә. Мин кичен кайтканда ул һәрвакыт яткан була иде. Бүген ул уяу. Алай гына да түгел, тәмле конфетларын куеп өстәл әзерләгән. Ятыр алдыннан ашау-эчү гадәте булмаса да, бүген күзләре йокы качкан иде.

– Борчылма, улым. Сания белән ким-хур булмассың, матурлыгы да бар, эшкә дә уңган, – дип ничектер үзе сүз башлады.

– Ә син кәян белдең?

– Йөзең әйтеп тора ич.

...Әни иртә таңнан торып намазга басты. Озак итеп теләкләрен теләде. Аллаһы Тәгаләдән безгә бәхет-тәүфыйк, балаларыбызның исән-сау дөньяга килүен сорады. Матур киемнәрен киеп, Яңа бистәгә Зәйнәп сеңелләренә чыгып китте.

– Сезнең сүз куешу – эшнең башы гына әле ул, – диде ишекне япканда.

Бирәм дигән колына, чыгарып куяр юлына, дигәндәй нәкъ шул көнне бернинди йомышлары булмаса да, авылдан Саниянең әти-әнисе дә Марзия апаларга киләсе иткәннәр.

Безнең Сания белән киләчәк язмышыбызга бәйле кешеләрнең барысы да М.Гафури урамындагы шушы йортка җыелган булып чыкты. Тәкъдир түгел диген инде! Алар самавырларын яңарта-яңарта никах һәм туй мәҗлесен кайда һәм кайчан узачагын, кемдә яшәячәгебезне бәйнә-бәйнә сөйләшкәннәр. Һәм һәркемгә бурычлар тәгаенләнгән. Без Сания белән кичекмәстән ЗАГСка гариза бирергә тиеш идек. Җитәкләшеп Ленин урамына йөгердек.

Ул чорларда өйләнешүчеләрнең ният ныклыгын сынар

өчен ике атна вакыт бирелә иде. Безнең язылышу 30 март көнне көндезге икегә билгеләнде. Димәк, егет булып тагын ике атна йөрисе калды. Аннан соң — хуш, яшьлек! Вакыт сүтелә бара, Сания белән көнаралаш диярлек очраша торабыз. Мин аны шулкадәр сагына идем, ансыз яшәүне күз алдына да китерә алмый башладым. Ник элегрәк өйләнмәдем икән дип, үземне битәрли идем. Хәер, һәр нәрсәнең үз вакыты бар шул.

* * *

Санаулы көннәр узып та китте. 30 мартта смена мастеры белән сөйләшенгәнчә, бирелгән эшләрне төшке ашка кадәр эшләп бетереп, сәгать унберләрдә өйгә кайтып китәргә тиеш идем. Эшне өеп бирделәр. Әгәр үзем генә матапсам, ике-өч кондә дә башкарып чыга алмаган булыр идем. Рәхмәт инде, дус егетләр булышты. Мин эшләгән группада без барыбызда диярлек армиядан кайткан кичәге солдатлар идек. Үзара шулкадәр дус, тату идек ки, хәтта иң якын туганнарыбызга да әйтмәгән серләребезне уртаклаша идек.

Егетләр эш арасында шаяртып, уен-колке белән киңәшләрен бирәләр. Мин бүген кәләш кочагына керәсе кияү бит. Уен эш түгел. Шул кочакта, иншалла, киләчәк буыннарга нигез салыныр. Монда уйлап эш итәргә кирәк. Без, хәтта тәмәке тартырга да бүленмичә, баш күтәрми эшләдек. Көндезге сәгать унбер дигәндә бирелгән эшне контролерлар кабул итеп алганнар иде инде. Гадәттәгечә, яныбызга өлкән мастер килде. Мин заданиенең үтәлгәнен әйттем һәм кайтып китәргә рөхсәт кәгазе сорадым. Ул бу турыда беренче мәртәбә ишеткәндәй: «Нинди кайту ул тагын. Бүген 30 ы икәнен беләсеңме? Ай ахыры, квартал ахыры бүген, план-заданиеләрне үтәп бетерергә кирәк! Язылышуың беркая да

качмас. Аның өчен башка көн дә бар. Ә хәзер тиз генә капкалап алыгыз да, җиңнәрегезне сызганып эшкә керешегез. Бүген утызы, ай ахыры!» — димәсенме? Ул тиз генә китмәкче иде дә, ләкин егетләр юлын бикләде. Алар өлкән мастердан мине җибәрүен үтенделәр. Кирәк булса, икенче сменага да калып эшләячәкләрен әйттеләр. Ләкин аның үз туксаны туксан: «Юк!». Шуннан соңгы хәлләрне мин томан эчендә кебек кенә хәтерлим. Кинәт ярсып китеп, верстакта яткан чүкечне алганмын да, мастерга ташланганмын. Ярый әле егетләр тотып калган. Югыйсә бу хәл үлем белән тәмамланасы иде. Агарынган-күгәренгән өлкән мастер абынасөртенә цех начальнигы Попов янына йөгергән. Хәбәр минуты белән бөтен цехка таралган, бөтен халык безнең янга җыелган. Бу вакытта мин бераз аныма килә башлаган идем. Барысы да миңа теләктәшлек билдерә, мастерны сүгә. Цех начальнигына делегация җибәрмәкче булдылар.

Ул арада цех начальнигының секретарышасы үзе килеп җитте. Мине Попов чакырткан икән. Үзем белән бергә үйнап үскән Мансур бер яктан, Каравайда апаларында торган Мөбәрәкша икенче ягымнан култыклап, цех начальнигына алып киттеләр. Безнең арттан шау-гөр килеп халык иярде. Без килеп кергәндә цехком рәисе Гайсин, комсомол секретаре Андреев анда иделәр инде. Мансур дустым хәлне бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Попов өлкән мастерга карап: «Шулай булдымы?» — дип сорады. «Әйе, шулай булды», — диде тегесе. Цех җитәкчесе урыныннан торып басты һәм миннән башкаларга бүлмәдән чыгарга кушты. «Бик күңелсез хәл килеп чыккан, — диде ул, икебез генә калгач. — Сүз дә юк, без гаепле. Алдан ук гариза язып, үземә керергә кирәк булган сиңа. Ә хәзер тынычланырга тырыш». Шуннан ул табельщицаны һәм цехком рәисен чакыртты.

— Сафинга акчалата ярдәм итә аласызмы?

– Булыр, завком аша оештырыбыз.

Аннан табельщицага карап,

– Аның отгуллары күп, хәзер өч көнен алсын. Үзе кирәк санаса, тагы да алыр, – диде.

Попов кат-кат гафу үтенеп, безне озатып калды. Мин бүлмәдән чыкканда бөтен цех аякка баскан, умарта күче кебек гөж килә иде. Кешеләр миңа уңышлар теләп озатып калдылар.

* * *

Өйгә кайтып, ашык-пошык өс-башларымны алыштырып, Ленин урамына йөгерсәм килгәнче, хәйран вакыт үтте. Туган-тумачалар ЗАГС ишеге төбендә мине көтә-көтә көтек булган. Кайберләре инде кайтып китәргә дә ниятләгән. Әгәр Нәҗип абыем уен-көлке сөйләп, күңелләрсн күтәрмәсә, шулай эшләгән дә булырлар иде. Бу хәл бигрәк тә Санияне пошаманга салган. Киләсемә ышанса да, барыбер хафага төшкән.

Соңга калуым өчен кат-кат гафу үтенгәч, язылышу залына үттек. Безне мөлаем йөзле ханым каршы алды. Шушы минуттан башлап үзебезнең ир белән хатын икәнлегебезне имзаларыбызны куеп беркеттек. Әлеге мөлаем ханым тәбрик итеп, язылышу турында таныклык бирде. Залда тантаналы музыка яңгырады. Туганнарыбыз да берәм-берәм килеп, кулларыбызны кысып, тәрбикләде. Барысыннан да бигрәк кияү егете булып килгән Нәҗип абыем шат иде.

Урамда безне йөрәкләргә дәрт-сихәт бирүче яз кояшы иркәләп каршы алды. Аның җылы нурлары юл кырыендагы кар өемнәреннән челтәр бәйли, асфальтка җыелган кар суларында коена. Урам халык белән тулы. Барысының да йөзе көләч. Яз бит, яз! 1962 елның язы тантана итә. Мин дә

куанырга, хәтта «Мин бәхетле!» дип кычкырырга тиеш идем кебек. Тик булдыра алмыйм. Мине нидер баскан, күңелемне никадәр генә күтәрергә тырышсам да, җанны ниндидер шом биләп алган, йөрәкне нәрсәдер тырный. Ачу да юк сыман, ләкин җан сызлана, күңел үкси.

– Рәис, нәрсә булды? Соңга калуыңның сәбәбе нидә?

– Соңыннан барысын да сөйләрмен. Хәзер минем ул турыда тел тибрәтәсем дә килми.

– Нәрсә булды соң, энекәш? Дөресен генә әйтеп бир безгә. Югыйсә Саниянең дә, башкаларның да әллә нәрсә уйлаулары бар. Гаиләнең нигезе – бер-беренә карата намуслы, эчкерсез булу. Аның беренче адымнары дөреслектән башлансын, – диде Нәҗип абый.

– Өлкән мастер җибәрмәскә маташты. Ай ахыры, квартал ахыры, план үтисе бар, имеш...

– Сволочь. Чын кабәхәт икән. Монда кешеләрнең язмышы хәл ителә, аңа план кирәк. Менә шундыйлар агулый да инде безнең тормышыбызны.

Нәҗип абый шытырдатып тешләрен кысты. Аның бала башы кадәр йодрыклары агарып килгән иде.

Бу сөйләшүне янымда барган Сания дә ишетте. Ул миңа ныграк сыена төште.

– Ярар, энекәш, борчылма! Узгынчы борчу булсын. Барысы да әйбәт булыр, иншалла... Бәхетле булыгыз. Бер-берегезне тыңлап, хөрмәт итеп яшәргә язсын.

Никах мәҗлесе башланырга беркадәр вакыт бар иде әле. Без ашыкмый гына Кольцога таба юл тоттык. Саниям янымда. Тик күңел һаман тынычланып җитә алмый. Цехта булган хәлләр күз алдымнан китми, өлкән мастернын сүзләре колагымда яңгырый. Ә бит язылышуның да, никах мәҗлесенең дә булмый калуы мөмкин иде. Әгәр цех начальнигы Попов та өлкән мастер кебек фикер йөрткән булса? Ләкин

ул, бәхеткә, производство планнарыннан өстенрәк булып чыкты. Комсорг та үз сүзен нык итеп, кистереп әйтә белде. Рәхмәт инде аларга.

Безне капка төбенә чыгып каршы алдылар. Күрше йортлардан абый-апалар да килеп котлады, өйдә ризык белән тулы остәлләр кунакларны көтә

— Бар, бабаң-әбиең белән таныш, алар кече өйдә, — диде әни. Без өйгә кердек.

— Исәнмесез?!

— Шөкер генә әле, кияү, — диде бабам урыныннан торып. Ул урта буйлы, текә маңгайлы, башына кара кәләпүш, остенә изүен уң яккарак авыштырып тегелгән утырма якалы зәңгәр күлмәк, кара костюм кигән иде. Аның битендәге кызамык авыруы уеп калдырган белеспер-беленмәс шадрасы, төс-кыяфәтенә килешеп торган җәенкерәк борыны, беренче карашка ук кешеләрнең игътибарын үзенә жәлеп итә. Без ике куллап күрештек. Ул күзләрен кыса төшеп баш какты, ризалыгын белдерде.

Болын чәчәкләре белән бизәлгән бала итәкле күлмәк кигән, шундый ук чәчәкле алъяпкыч япкан, биленә кадәр төшкән ак яулыгын ияк астына бәйләгән әбием дә кулларын алга сузды. Ягымлы көләч йөзенә алсулык йөгерде. Бер мизгелгә төбәлгән зәңгәр күзләре мине сыйпап үтте. Аның шифалы жылы карашы безгә фатыйха бирүе булды.

Алар икесе дә киң күңелле, актык сыныкларын да башкалар белән уртаклаша белүче мәрхәмәтле кеше булдылар. Утыз ел дәверендә без бер-беребезне ихтирам итеп, сыйхөрмәт бүлешеп яшәдек. Әби дә, бабай да мине үз балалары кебек күрде. Мин дә аларга игътибарлы булдым. Үз әтием-әниемне яраткан кебек яраттым. Бабай үләр алдыннан: «Минем урыныма Рәис кияү кала. Аны ихтирам итегез, мине тыңлаган кебек тыңлагыз!» — дип, васыять итеп әйтеп

калдырган. Авыр туфрагы жинел, урыннары Жәннәттә булсын!

...Ул арада никах укучы абзый да килеп житте. Кунаклар өстәл тирәсенә утырышты. Сания белән безнең урыныбыз түрдә булып, уң ягыбызда минем әнием, сул ягыбызда аның әти-әнисе урнашты.

Никах укучы абзый үз эшен бөтен шартларын китереп башкарды. Садака бирүчеләр кулларын юеш сөлгеләргә сөрткәннән соң, барыбыз да бисмиллаларыбызны әйтеп, кашыкларыбызга үрелдек. Марзия апа аш-су осталарының да остасы шул. Ризыкларның барысы да телеңне йотарлык булган.

Бер кат ашап-эчкәч, ял итәргә тышка чыктык. Иш-ишен таба дигәндәй, минем янына да тәмәкесен пыскытып, жор телле кунак елышты.

— Танып булыйк. Мин Насыйбулла булам. Ягъни мәсәлән бажаң. Сания балдызның Минсафа исемле апасының ире.

— Әйдә соң. Бер мәҗлестә өч Насыйбулла булса да, күп май салганнан ботка бозылмас, — дидем мин шаяртып.

— Без бер мәҗлестә өч булсак та, хатыннарыбыз өчен тик берәү генә. Марзия апаның үз Насыйбулласы, Зәйнәп апа да ирен берәү белән дә уртаклашасы килми. Алар әбинең кияүләре түгел. Мин — Насыйбулла — әбинең өченче кияве. Син дүртенчесе булдың. Тагы да өч балдызыбыз өйләрендә кияү көтеп утыра. Алла боерса, киләчәктә жиде бажа булырбыз. Әгәр, теге әкияттәге кебек, бүре ашамаса...

Кем уйлаган Насыйбулла бажаның ул вакытта шаяртып әйткән сүзләре рас килер дип. Жиде бажадан бүген мин берүзем калдым. Башкаларын бүре түгел, вакытсыз әжәл ашады. Минсафа апа да шул вакытсыз корбаннарның берсе булды. Ул, әнисе кебек, халкыбызның иң күркәм сый-

фатларына ия кеше иде. Мин әле дә булса аңа сокланам. Гомумән, ул мәҗлестә кунак булганнардан берничә генә кеше калдык инде. Ни әйтсәң дә, кырык ел гомер үткән.

Без янә табынга утырыштык. Никах укучы абзый китмәгән иде әле. Ирләр, читләтеп-читләтеп, аңа китәргә вакыт икәненә ишарә ясап карасалар да, кузгалырга исәбе юк. Алай да булмагач, ачыктан-ачык эшкә керештеләр. Табынга аракы чыкты.

– Мин сезне шушы шайтаннан сакламак булып утыра идем. Хәләл никахны хәрам аракы белән бутау – зур гөнаһ гамәл. Бу безнеңчә, моселманча булмый бит, җәмәгать, – диде абзый.

– Бу советча була! Советча, ягъни заманча!

– Советның да, никахтан соң аракы чөмерегез, дигән карары юк.

– Аракы эчкәннән генә никах бозылмыйдыр бит?

– Юк, бозылмый. Никахны талак кына боза ала. Ләкин аракы никахның сафлыгын югалта, кадерен бетерә..

Абзыйны сыйлап, юмалап, жизниләр озатып куйды. Аның белән минем дә җаныммнан нидер киткән төсле булды. Ул бушап калды.

Тамаклары туеп, йокымсырап утырган ирләргә жан керде. Авызлар ерылды, тел дигәннәре йөгәннән ычкынды.

Гомерендә аракының исен дә белмәгән әнием дә торып китте. Аның артыннан әби белән башка хатын-кызлар да иярде.

Беренче рюмкалар безнең исән-саулыкка, бәхетле тигез гомер итүебезне теләп эчелде. Калганнары инде, сүзсез генә акты да акты.

– Тот әле берәрне! Утырма борыныңны салыпдырып!

– Юк, кияүгә ярамый. Аның эше бар әле.

– Эшләнәсе эш, эшләнер. Алда төннәр күп.

– Берәр рюмканың әллә ни зыяны тимәс. Тот, диләр сиңа! Курыкма. Бабаң күрми ул. Аның күзе пыяла бит.

Бабай борылып миңа карады.

– Мин күземне сугышта калдырып кайттым шул. Нәфсең булса, мин каршы түгел, – диде ул.

Миңа рәхәт булып китте. Эчкә кергән яшел елан тамырлар буйлап шуышты. Акыл «ярамый» дисә дә, шайтан коткысы җиңнәрен сызганып эшкә керешкән булып чыкты.

Чираттагы тәнәфестә яныма Мәрзия апаның әлеге читтән кайткан кияве Нияз килде.

– Минем монда яшереп куйган нәрсәм бар. Берәрне дөпибез мәллә?

Берәр дигәне күпкә китте. Нияз бүген цехта булган хәлләр белән дә хәбәрдар икән.

– Сука буду. Мин ул падланың эчен агызам әле! – диде ул, өлкән мастерга янап.

Нияз төрмә шулпасын шактый чөмергән һәм кирәк чагында пычагы да һәрвакыт әзер кеше иде. Аның үлеме дә шул пычактан булды.

Эчелгән һәр рюмка утка бензин бөркегән сыман иде. Яраланган жанымның әрнүе, кимсетелгән-мыскылланган күңелем дәһшәтле өермәгә әйләнде. Күкрәгемдә ачу-нәфрәт вулканы кайнады. Мин инде бервакыт дә кыстаганына мохтаж түгел идем. Күрәсең, шушындый давыллы чакларда эшләнәдер ул акылсыз жинаятьләр.

* * *

Баш чатнавына чыдый алмыйча уянып киттем. Көчхәл белән күзләремне ачып карасам, аптырап калдым: таныш булмаган урында, ап-ак җәймәләр өстендә ятам. Тирә-

як тып-тын. Кайдадыр сәгать кенә текелди. Карашым түшәмгә төште. Анда иртәнге җилдән салмак кына тибрәнгән агач ботакларының шәүләсе кояш нурларында биешә. Алар белән мин үзем дә тибрәнәм, чайкалам кебек. Болай да әлҗе-мәлҗе башым әйләнә үк башлады. Күземне йомдым. Әкрен-әкрен зиһен җыела, башка аң керә кебек. Йә Ходa! Мин кичә кияү идем түгелме соң? Әйе, кияү идем шул. Никах укылды. Эсселе-суыклы булып китте. Эре-эре тир бөртекләре бәреп чыкты. Ишкәнмен икән ишәк чумарын. Инде нишләргә? Саниянең күзенә ничек күренергә? Әнием, әби-бабай, кунаклар ни әйтер? Юрган чите белән битемне сөртеп алдым. Чак кына башымны күтәрә төштем. Җинаятьче сыман як-ягыма карандым. Күрәм, карават башындагы урындыкта Саниям утыра. Ул иңенә эре-эре роза чәчәкләре төшкән яшькелт халат салган. Өстендә алсу эчке күлмәк. Аның алсулыгы Саниянең дә йөзенә күчкән сыман. Челтәрле өске киеменнән яртылаш ачык күкрәкләре калкып тора. Йә Ходa, нинди сокландыргыч гүзәл алар! Сабыйны имезеп кеше иткән, ирләрне гомер буе ымсындырган сихри күкрәкләр. Мин беренче мәртәбә күрәм мондый тылсымлы гүзәллекне! Чөнки безнең заман егетләре яраткан кызларын култыклап йөрүдән ары узмады. Кочаклау, үбүләр дә бик сирәк әләгә иде.

Каршымда алиһә кебек асыл кәләш. Һәм шушы затлылыкны, хушбуйлар сөртеп, зәфаф төненә бөтен әзерлеген күргән, сөйгәненең кайнар кочагында ир ләззәте алырга әзер кызны хәмергә, аның сасы исенә альштырган мескен кияү.

Аз гына алга китеп әйтим: бу вакыйгадан мин гыйбрәт алдым. Гомерем буе хатын-кызны хәмер белән бутамаска тырыштым. Алкоголь минем дошманыма әверелде. Чөнки ул иң якын туганнарымны вакытсыз гүр иясе итте. Ә инде эчүне, тартуны ташлый алмыйм, дию – үземнең ихтыярсызлыгымны, булдыксызлыгымны акларга теләп әйтелгән буш сүзләр.

– Ач күзеңне, дөнья бу!

Саниянең бу сүзләре мине айнытып жибәрде.

– Хатын, сәлам.

– Әлегә хатының була алмадым.

– Кызганыч. Борчылма, булырсың иншалла. Тик син миңа үпкәләмә инде. Киләчәктә мондый акылсызлыкны кабатламаска тырышырмын.

– Сүзләрең фәрештәләрнең «амин» дигән сәгатенә туры килсен иде, Раббым.

– Һичшиксез туры килер, Аллаһы боерса. Әгәр бу жүләрлегемне гафу итәр булсаң, китерче миңа кайнар чәй.

Сания тиз әйләнеп килде. Чәй кухняда кайнап утырган булса кирәк.

– Таныттың үзеңне, бик яхшы таныттың. Шаккатырлык булды, – диде кулындагы чокырын миңа тапшырып.

– Якалашу-мазар булмагандыр ич?

– Утырган урынында йоклап киткән кеше белән кем якалашсын ди?

Монысына мин бик шөкер идем. Әни әйтмешли, баш тишелмәгән, күз чыкмаган.

Озакламый иртәнге чәйгә дәштеләр. Без кичәге тәртиптә үз урыннарыбызга утырыштык. Табында әнием дә бар иде. Ул:

– Яңа күлмәгең бәрәкәтле булсын, игелеген күр, – диде.

Мин күлмәгемә карадым. Дөрес, ул бераз таушалган. Ләкин кичә генә кигән яңа күлмәк. Барысы да елмаешып миңа карады. Әнинең нәрсә әйтергә теләгәнен соңыннан аңлаттылар. Бу зәфаф төне үткәргән кияү белән кәләшкә әйтелә торган сүзләр икән.

Иртәнге аштан соң тышка, тәмәке пыскытырга чыктык.

Нияз кичә кич булган хәлләрне, ипштәннәрне тезеп китте:

– Әбиең сине култыклап урыныңа яткырырга барганыбызны күргәч: «Үзебезнекеләр дә бик җиткән иде, тагы бер исерек артты», – диде. Ә бабаң молодец, кәттә мужик икән. «Исерек булса да, үз ипебез, безгә башка торлесе кирәкми», – дип җавап кайтарды.

Бабай бөтен тирә-якка данлыклы тегүче булганга, Шәле кешеләре генә түгел, күрше авыллардан да килеп, бишмәт, сырган чалбар, телогрейка тектертәләр иде. Эшләгәннең ашы да бар дигәндәй, кайчакларда ул салгалап та куйгалый. Ләкин чамасын белеп.

Төшкә Зәйнәп апалар чәйгә дәште. Без зәвык белән әзерләнгән табынга утырыштык. Беренче карашка өстәл өсте тыйнак кына күренсә дә, аны берсе артыннан икенчесе чыккан, күз явын алырлык ризыклар бизи торды. Зәйнәп апа гөбәдияне бигрәк тә оста, ссрен белеп әзерли иде.

Бер кат чәйләр эчкәч, җизни, гадәтенчә, ашыйкмый гына, әйтәсе фикеренә басым ясый-ясый сүз башлады.

– Кайнеш, – диде ул миңа карап. – Кызның менә дигәнен алдың. Бер ипегалдында торгач, кемнең кем икәнен яхшы беләбез. Инде эш үзеңнән тора. Син туры әйткәнем өчен үпкәләмә, ачуланма да. Әтиең урынына калган җизнәң буларак, үз сүземне әйтергә хакым бар. Шуңа күрә әйтәм дә: синең кичәге тәртибең йөзебезне кызартты.

– Җизни, монда мин дә гаепле инде, – дип Нәҗип абый сүз әйтә генә башлаган иде.

– Юк, кайнеш, – дип, туктатты аны жизни. – Һәркем үзе өчен үзе жавап бирә. Дөрес, кичә үк без аның кулына суга ала идек. Әмма бу эш аның дәрәҗәсен төшергән булыр иде. Акылсыз кешене генә тыялар. Акыллы кеше акыл белән, үзе белеп эшли. Сезнең әтиегез авылыгызда гына түгел,

бөтен Арча районына данлыклы гармунчы иде. Өчәр көн кунакта булды. Әмма аракы дигән хәрамне теленә дә тиереп карамады. Шуңа күрә ул хөрмәтле дә кадерле дә булды. Менә сез кем балалары!

Әниегез яшьләй тол калып, сезне ач-ялангач итми, авырлык белән үстерде. Сез дә аңа игелекле булыгызчы инде. Яхшы булу акча сорамый, яманлык кына сорый...

Табындагыларның барысы да тып-тын. Мин әниемә карадым. Ул утырган урынына сеңеп бетеп, бөрешеп калган. Әйтерсең җизнинең сүзләре миңа түгел, аңа әйтелгән.

– И, әнием, гафу ит мине, кичер мине, әнием.

Миңа шул кадәр оят, шул кадәр уңайсыз булды ки, әгәр җир ярылса, ике дә уйламый, җир ярыгына ташланган булыр идем. Хәзер инде олы яшьтә булсам да, җизнинең шул сүзләре әле дә колагымда яңгырый.

Әйе, халкыбызның күркәм гореф-гадәтләре, кадерле дине, иманы белән советларның динсез йолаларын бәрелешкән чор иде бу. Суслов даирәләренең тамырларыбызга балта чапкан борылыш чоры.

Никах укылган йортта ике төн үткәрергә кирәк, шулай тиеш дигәч, куна калдык.

Иртәгесен, 1 апрель көнне ике такси алып, Җиләкле бистәсенә юл тоттык. Ул көнне бистәбезнең С.Щедрин урамына киленнәр төшкән көн булды. Каршы йортта торучы Мансур да өйләнеп, хатыны Сания белән кайтырга тиеш иде. Аларны каршыларга әти-әнисе, туган-тумачалары, күрше-күлән урамга чыккан. Безнең кайтуыбызны күргәч, олысы-кечесе яныбызга йөгерешеп килде. Олы абый-апалар изге теләкләрен юллап, хәер-фатыйхаларын бирделәр.

Табыныбыз җырлашып-биешеп, бик күңелле үтте. Без – өч ир туган, бердәнбер Рәисә сеңелебез гармунда, тальянда уйнадык. Рәшит абый гаҗәеп оста биюче дә иде. Филармо-

ниядән берничә мәртәбә чакыру кәгазе килсә дә ул барырга теләмәде. Рәисә кинәт сулышлы, көйнең бөтен нечкәлекләрен белеп, аны җиренә җиткереп җырлаучы моңлы иясе иде. Аның:

Әй, абыем, Дим буе,

Бик сагындым бу юлы, – дип, җырлавы күңелемне искә төшкән саен әле дә тетрәтә. Әйтерсең ул бу дөньядан иртә китәсен сизеп, үзенең безгә булган мәхәббәтен әйтеп калдырган.

* * *

Никах мәҗлесе үткәрергә бирелгән өч көн ялым үтеп тә киттс. Егетләр минс тәбриклəп, шатланып каршы алдылар. Төшке аш вакытында яныбызга теге өлкән мастер килде. Тик инде өлкән мастер булып түгел, гади фрезерчы булып.

– Бөтен җаным-тәнем белән гафу үтенәм. Зинһар, мине каргама, Рәис.

– Сиңа бернинди дәгъвам да юк. Үз эшеңне эшләтмәдең ләбаса.

Шуның белән теге күңелсез вакыйга онытылды кебек. Ләкин...

Көннәр бер-бер артлы уза торды. Туйга да ерак калмады. Тик соңгы көннәрдә тәнемне басып алган ниндидер бетчәләр хафага сала. Кашый башласаң, кычыткан урыннан кулларны алып булмый. Кычыту бөтен тәнгә тарала, шашыр хәлгә җитәссң. Озакламый ул бетчәләр бергә кушылып, тәнемдә юеш урыннар барлыкка килде. Түзә алмагач, врачка киттем.

– Бу юеш экзема дип атала. Ул афәт, гадәттә, тирән эчке

тетрәнүләр, хәсрәт-борчулар нәтиҗәсендә барлыкка килә. Әллә берәр төрле күңелсезлек, фаҗига кичердеңме?

Бу әлеге дә баягы цехта булган вакыйгаларның кайтавазы икән.

Мине эштән азат иттеләр. Берничә көннән теге бетчәләр шул кадәр ишәйде, тәнемдә юеш урыннар киңәйгәннән киңәйде, көч-хәл белән йөри башладым. Марляга уралган тәнемне ривонол дигән сыекча белән чылатып, урын өстендә ятам. Бары шушы сыекча гына әзрәк тынычландыра, тәнемнең сыркып торган урыннарын киптерә төшә.

Нинаять, 1 Май төне җитте. Безнең туебыз буласы көн башланды. Ләкин, ул безнең өчен тантана көне булырмы? Килəчəктə безне нинди язмыш көтә?

Хәлем шуңа килеп җитте ки, вакыт-вакыт аңымны жуя башладым. Кара кайгыга баткан әнием, үзе авыруга сабышты.

– Раббым, алма баламны, алма минем газиз улымны, – дип калтыранган куллары белән башымны сыйпый.

– Кунакларга нәрсә дип әйтербез, әни? – дип өзгәләнә Сания.

–Дөресен әйтербез. Авыруны сорап алмыйлар. Үлем дә берхак. Раббым, рәхмәт-шәфкатеңнән ташлама. Саулык-сәламәтлек бир улыма.

Ул арада күршебез Наил дә кереп җитте.

– Наил, улым, нишләп карыйм икән соң? Әллә ашыгыч ярдәм чакыртыйкмы?

– Бу хәлдә кияү булып, туенда утыра алмас шул.

– Бар, чакырт, – диде әни күз яшьләрен сөртеп.

Төнге сәгать икедә мине ашыгыч ярдәм машинасына чыгарып салдылар.

Кеше дигән җан иясен вакыт-вакыт шундый халәт биләп ала: дөньяның шатлык-куанычлары, кайгы-хәсрәтләре,

мәшәкать-борчулары каядыр китеп югалган сыман була. Ул бушанып кала. Аның һичкемдә эше юк, бернәрсәгә дә исе китми башлый. Мин дә нәкъ шушындый хәлдә идем. Әйтерсең барысы белән дә исәп-хисап ясалган, эшләнәсе эшләнгән, хуш фани дөнья!

Мине Зур Кызыл урамдагы сырхауханәгә алып килделәр.

– Зинһар өчен аякларыгызга басып торырга тырышыгыз, без дә булышырбыз.

Кыңгырау төймәсенә баса торгач, ниһаять, ишек ачылды.

– Бездә буш урын юк, – диде йокысыннан айнып бетмәгән хатын.

– Моңа кичекмәстән сезнең ярдәм кирәк. Күрәсез ич аның нинди хәлдә икәнен, – диде мине китергән табиб.

Ишек төбендә тагы бер ак халатлы ханым килеп басты. Мине күреп:

– Кертегез, урын табарбыз, – диде.

Тарта-өстери торгач, көч-хәл белән мине икенче катка мендерделәр.

– Бирегә!

Зур булмаган, җыйнак бүлмәгә кердек. Мине тәрәзә янындагы караватка яткырдылар. Бу дежур торучы табибларның ял итә торган бүлмәсе икән. Озакламый янына табиб килде.

– Йә, күрсәт, байлыкларыңны!

Мин марля, чүпрәкләремне чишеп, шәрә калдым.

– Ай-һай, монда эш күп икән. Ләкин өмет бар. Экзема – псориаз түгел, аны дәвалый беләбез!

...Ниһаять, кояшның беренче нурлары бүлмә диварларына төрле фигура, рәсемнәр ясап шаяра башлады. Әле вакыт иртә булса да, коридорда аяк тавышлары тынып тормый. Бу тире авырулары белән иза чигүчеләрнең гадәтенә

әйләнгән күренеш икән. Алар төннәр буе йөренеп, кашынып чыгалар.

Дүрт сәгать саен шәфкать туташы берничә укол кадый, марляларымны алыштыра. Инде ничә көн юньләп ашап-эчкәнем булмаса да, тәнем кипми. Суы каян килә диген. Хәтта керфекләремнән дә тама.

Урамда 1 Май бәйрәме. Хастаханә Ирек мәйданыннан ерак булмаганлыктан, демонстрациядә катнашучыларның кор тавышлары ишетелеп тора. Ул заманнарда аны куштышы, тантаналы итеп уздыралар иде бит. Һәр коллективның вазифа-гамәлләре алдан ук, энәсеннән җебенә кадәрле язылып куелды. Һәркемнең нәрсәгә җаваплылыгы план-мероприятиеләрдә күрсәтелде. Әгәр мин мондый хәлгә калмасам, һичшиксез, анда булыр идем.

Көн кичкә авышты. Урамнардагы шау-шу да тынып калды. Коридорда тыз-быз йөргән авырулар, палаталарына кереп, туган-тумачалары китергән бәйрәм күчтәнәчләре белән сыйланалар булса кирәк. Кырык эшен кырык якка ташлап, янына әнием дә килеп китте. Әллә туй мәшәкатьләре башыннан ашканга, әллә минем тыныч йөземне күреп, ул үзен сабыр тотты.

– Борчылма, әүвәле-ахыры хәерле булсын. Тумыштан килгән авыру түгел, төзәлерсең, Аллаһы боерса, – диде ул саубуллашканда.

Баганаларда утлар кабынды. Шәһәр тынып калды. Тик бераздан ишегалдында шаулашкан тавыш ишетелде.

– Нинди кияү ди ул. Йөрмәгез авыруларны борчып!

– Кияүне күрмичә беркая да китмибез. Баста!

– Кодагый кияүне шушы бүлмәстә ята диде түгелме соң? Әллә ялгыш килдекме?

Бу минем туемда булган кунаклар иде. Алар җыйнаулашып кияүнең хәлен белергә килгәннәр.

– Болар минем кунакларым. Момкин булса, кертегез бер-икесен, – дип сорадым табибтан.

– Ә кияү дигәннәре кем була?

– Мин булам. Бүген минем туем идс...

– Бар икән хәлләр...

Яныма Сания белән Насыйбулла керде. Бажай минем хәлне күреп, башын читкә борды.

– Балдыз, – диде ул бераздан Санияга карап, – Рәис бажа авыруыннан терелеп, аягына басмыйча, беркая да китәсс түгел! Ул яшьле күзләрен йодрыгы белән сөртеп алды.

Насыйбулланың бу сүзләренә мин соңыннан гына төшендем. Сания аерылып китәргә уйлаган икән бит.

* * *

Сырхауханәдә илле көн яттым. Хәлем мактанырлык булмаса да, әкрен-әкрен үз аякларым белән йөри ала идем инде.

– Бар, кайтып яшь хатыныңны кочакла! – дип шаяртты табиб.

Өйдә әнием генә иде. Без кочаклашып күрештек. Икебезнең дә күзләребездән яшь ага, шатлык яшьләре.

Бигрәк тә эчкерсез, саф идс шул безнең мөнәсәбәтләребез. Бу ана белән баланың табигать тарафыннан бирелгән мәхәббәте иде. Гомеренең соңгы өч елын әнием авырып, урын өстендә ятты. Сәякләре, бөтен эчке әгъзалары сызлады. Күрәсең, сугыш вакытында язгы кар суларын ера-ера, әле эри генә башлаган язгы туң жирдән черек бәрәңге жыюларның галәмәте булгандыр. Аның гомере буе йөрәге авыртты, тыны кысылды. Аллаһының кушканнарын ихлас күңеленнән үтәп, тыелганнарыннан тыелып яшәве бәрабәренә 86 яшен тутырып Ахирәткә күчте.

Без өйдә юк чакларда урындыкны үз алдыннан этеп, шуңа таянган хәлдә ул кирәк жиренә бара иде. Көннәрнең берендә ишек кыңгыравы чылтырый. Озак дәвам итә бу чылтырау. Аптырагач, көч-хәл белән барып ишекне ача. Анда таныш булмаган бер хатын басып тора икән.

– Апа, жаным, борчуым өчен ачуланма. Авыру газабы китерде яныца.

Әни үзенең дә ярдәмгә мохтаж хәлсез карчык икәнен, хәтта аш кашыгын да килене тотып ашаткапын әйтә

– Күрәм, үз хәлең үзеңә житкән. Син сыпырып кына кара, нәрсә булганын гына әйт. Сырхауханәләрдә ничә тапкыр ятсам да, файдасы булмады. Табиблар, авыруың юк, диләр.

Хатын әниемне күтәреп, урынына илтеп сала.

– Чишен, күрсәт авырткан жиреңне.

Чыннан да, хатынның аягы тубыктан тайган булган. Озак вакытлар үтү сәбәпле, сояк яшеренгән, жайлашкан. Ләкин авыру калган. Нишләргә? Электә кебек тартып утыртырга көч-куәт юк. Әнием шунда да жаен таба. Һәрвакыттагыча, башта хатынның үзеннән авырткан жирнең өйләнә-тирәсен атланмай белән удырта. Шулай итеп, анда утырган кара каннарны тарата. Тәне житәрлек дәрәжәдә кызгач, хатынга идәнгә ятарга куша. Бер урындыкны да идәнгә яткырып, хатынның авырткан аягын урындык аерчасына кыстыра. Авыртмасын өчен, урындык белән аяк арасына чүпрәкләр куйдыра.

– Ә хәзер,– ди,– урындык белән бергә авырткан аяңгыңны бераз үзеңә таба тарт. Ә икенче аягың белән арадагы аягыңны әкрен-әкрен генә, як-якка боргалый-боргалый түбәнгә таба эт!

Озак азапланалар хатыннар. Теге апа инде китмәкче дә була.

— Килгәнсең икән, түз! — ди аңа әнием.

— Берничә мәртәбә уып, сылап тырыша торгач, сөяк шырт итеп урынына кереп утыра.

Әнием бу изгелекләрне күп очракта бушка башкарды. Сәлек салгач та, үлгәннәре өчен генә акча алды. Һәм бу изге гамәлләрне кешенең милләтенә карамый эшләде. Кабатлау булса да әйтәм: әнием танылган дин әһеле дә булды. Изге Рамазан, Мәүлет айларында аның вакыты сәгатенә кадәр язылган булыр иде. Участок милиционерлары кәгазьгә кул куйдырып алсалар да, органнарга чакыртып кисәтүләр ясасалар да, ул мәрхүмнәрнең өчесенә дә җидесенә дә, кырыгына да барудан баш тартмады. Коръән укып, догасын кылды. Мәчетләр тыелган шушы куркыныч чорда да әнием изге Коръән сүзен халыкка җиткерүдә әлеге мөмкинлекләрнең иң уңай урын икәнен яхшы белгән һәм үз вазифасын намус белән башкарган. Бу — ул заманнар өчен зур батырлык иде, динебезне, иманыбызны сөюнең фидакарь үрнәге булды. Аллаһының рәхмәте яусын, авыр туфрагы җиңел, урыны Җәннәттә булсын!

...Минем сырхауханәдән кайтуыма Сания тыштан шатланган кебек итсә дә, йөзеннән бәгырьләрне өшетә торган салкынлык бөркелә иде. Өйдәге вак-төяк эшләрне башкара алсам да, күбрәк вакытымны бакчабыздагы беседкада ятып үткәрдем. Бөтен юанычым китаплар булды. Мин аларны көне-төне укыдым. Сания, төрле сәбәпләр табып, еш кына авылына кайтып китә торган булды. Өйдә чагында да янына сирәк керә башлады. Авыру кеше хәтта хатынына да кирәк түгел икән. Тик әниең генә синең өчен ут йота, араларның салкынаюына борчыла. Рәхмәт инде әниемә. Бөтен җанын биреп тәрбия иткәне өчен.

Ничарадан бичара дигәндәй, хастаханәдән кисәтеп җибәрсәләр дә, яшь хатынымны кочакларга да, күңелен

күрергә дә туры килде шул. Нәтиҗәсе озак көттермәде. Табиб әйткәнчә булды. Инде адәм күзенә күрсәтерлек булып килгән тәнем бер төн эчендә сазламыкка әйләнде.

Бу юлы ашыгыч ярдәм машинасы Толстой урамындагы тире авырулары хастаханәсенә илтеп куйды. Биредә бөтенләй башка мохит: бөтен җирдә чисталык, тынлык, саф һава. Атнасына бер мәртәбә профессор авырулар янына кереп хәлләрен сораша, кирәк тапса, башка дарулар билгели. Ул минем күптән түгел өйләнгәнемне белеп:

— Кияүне, һичшиксез, аякка бастырачакбыз! — дип шаярта иде.

Дөрестән дә, хәлем күзгә күренеп яхшыра башлаган иде. Инде атна-ун көннән бөлкем чыккан да булыр идем. Әгәр...

Аллаһы Тәгалә бәндәсен төрлечә сыный шул. Кайгы-хәсрәт биреп тә, газап-михнәтләр чиктереп тә.

Кичкә таба минем күңелне ниндидер шом биләп алды. Бөтен жаным-тәнем хәвеф көткәндәй сагаеп калды. Бер тын кысылгандай булды, бер тәнем кызышты, йөрәгем күкрәктән чыгардай булып сикерде.

Йокымның да рәте булмады. Тузга язмаган төшләр күреп, саташып беттем.

Иртәгесен яныма Рәисә сеңлемнең ире Камил килде. Аны күрүгә йөрәгем нидер сизенеп, туктап калгандай булды. Без хастаханә бакчасына чыктык.

— Рәисә кинәт кенә авырып китте бит әле, — диде Камил.

Калтыранган кулымны анын иңенә салдым.

— Камил, без синең белән күптәнге танышлар да, якын дуслар да. Егет чагыбыз бергә үтте, бергә кызлар озаттык. Язмыш биргән бу олы кайгы-хәсрәтне дә бергә, бер-беребезгә таянып, ярдәмләшеп үткәрик. Үзеңә пар тапканчы кызың

Резидә бездә торыр. Рәисә сеңлемнең үлемен тиктомалга әйтмәвең өчен рәхмәт.

– Син каян белдең?

– Бүген мин төне буе саташып чыктым. Шул саташулар арасында төш күреп алдым. Төшемдә әнием Рәисәне юып, кәфенләп куйды.

Камил үксеп елап җибәрде.

– Кем уйлаган, кем уйлаган болай булыр дип, – ди Камил, күз яшьләренә буылып. Авырса-нитсә, тагы бер хәл. «Эh» дигәнче үлде дә китте бит.

Рәисә сеңлем бер яшьлек кызы Резидәне имезергә дип, иртән кочагына алып яткан булган. Кызы имгән арада үлеп тә киткән.

Әжәл яшен-картын тикшереп тормый шул. Тормышын әле башлап кына җибәргән 23 яшьлек ана яшәсә дә бик ярар иде дә. Ләкин бу безнең ихтыярга буйсынмый. Камил – хатынын, Резидә – әнисен, без – бердәнбер сеңлебезне югалттык.

Мин кайтканда Рәисәнең җәсаде юылган, кәфенләп коласага салынган иде. Әйтерсең ул йокыга талган гүзәл кыз. Шул ук кыйгач кашлар, йөзенә ямь биреп торган кечкенә борын. Тик битендәге алсулыгы гына юк. Сизелер-сизелмәс ирен читләренә яшеренгән елмаюы, үзенең вакытсыз якты дөньядан китүе өчен бездән гафу үтенә сыман. Чак кына турсайган иреннәре кемгәдер үпкәләгән кебек. Кемнәргә үпкәләп китәсең сеңлем? Әгәр гаебебез булса, гафу кыл, бәхилләә безне!

Әнием дә бу олы хәсрәтне күтәрә алмый, урын өстенә ауган. Берничә мәртәбә ашыгыч ярдәм чакырганнар. Ул көч-хәл белән күзен ача төшеп:

– Кайттыңмы, улым? – дия алды.

Баржаларда күтәреп йөк ташуда тиңе булмаган, пәһлеван сыман Нәҗип абыем да шиңеп, бөрешеп калган. Ул калтыранган зур кулларын миңа сузды:

– Бер сеңлебез бар иде, ул да юк булды...

Аның кысынкырак соргылт күзләреннән гөрләвекләр акты. Ул уч төпләре белән яшьле битеп сөртеп:

– Минем дә эчемдә нидер өзелде бугай, энекәш, – диде моңсу гына.

Кара кайгыга чумган өй тулы кешеләр арасында бары тик Рәшит абыем гына, үзенә хас сабырлык, түземлек белән, күмү хәстәрен күреп йөри. Ул тойгы-хисләрен тирәнгә яшерә белә торган, гаҗәп тә чыдам кеше иде, мәрхүм. Алар Камил белән бөтен әзерлек чараларын күрделәр.

Сеңлемнең баш һәм аяк очларындагы кәфенен бәйләделәр. Кешеләрнең бер-берсе белән мәңгегә хушлашу минутлары иде бу. Иң авыр минутлар. Башка бервакытта да сеңлебезнең бит урталарын батырып, серле итеп елмаюларын күрә алмабыз инде. Аның моң белән мөлдерәмә аһәнле тавышын да ишетмәбез инде. Хуш, бәхил бул, кадерле сеңлебез, бердәнберебез!

– Хуш, кызым, бәхил бул, – диде әнием, чак кына башын күтәрә төшеп.

Өй бушап калды. Килендәшләр – Фиса, Хатирә җиңгиләр, Сания ой җыештырырга, юасы керләрне юарга тотындылар. Ул арада күршебез Әминә апа:

– Ходаем, Хәбибҗамал абыстай үзе дә үлә түгелмс? – дип, ачынып кычкырып җибәрде. Без барыбыз да әнием ятагына ябырылдык. Сания әниемә нашатырь спирты иснәтте. Ул бераздан башын боргалап, ыңгырашып куйды.

Йа, Раббым, рәхмәт-шәфкатеңнән ташлама. Шушы юлларны күз яшьләренә манчып язган мин – бәндәңә көч-куәт, акыл-зиһен бир!

Сеңлемне Пороховой зиратына җирләделәр. Аның кабе-

рс һәрвакыт караулы, пөхтә итеп җыештырылган, үзе шикелле күркәм булыр. Кызы Резидә – хәзер инде педагогика фәннәре кандидаты — үзенең тату гаиләсе белән әнисенең кабереннән эзен суытмый. Камил дә ташламый. Алар икесе дә Казаныбызның Максимов урамында исән-имин яшәп яталар, Аллаһыга шөкер.

...Мин хастаханәгә килгәндә көн кичкә авышкан, авырулар төшке аштан соң ял итәләр иде. Сеңлемне җирләү, әниемнең хуштан язып урын өстендә ятуы, Нәҗип абыемның шиңеп, бөрешеп калулары – боларның барысы да әле томан эчендә сыман, аң белән анализланмаган, йөрәк аша узарга өлгермәгән иде. Бөрелгән-сугылган, киселгән урын да соңрак авырткан, әрнегән шикелле, менә хәзер генә бөтен кайгы-хәсрәте, сагышлы сызланулары белән йөрәгем аша үтә бөтен нечкәлекләре белән аңымда кабатлана башлады. Бары хәзер генә бу афәтләрнең никадәр тетрәндергеч, тирән икәнен тойдым. Җанны югалту газабы, хәсрәт биләп алды.

Әлбәттә, боларның берсе дә эзсез узмады. Профессор һәм табибларның фидакарь тырышлыгы янәдән котырган экзема сулары белән ташып, агып китте.

Сеңлемнең өчесен, җидесен уздыру мәшәкатьләре мине оныттырды, берүземне хәсрәт дәрьясында калдырды. Бу васмсызлык мине гафу итә алмаслык гөнаһка этәрде.

Газиз ирем, олы улын сугышта югалткан кадерле әниемне, якын туганнарымны яңадан-яңа борчу-хәсрәтләргә салып, сөекле хатынымны тол итеп, булачак баламны ятим итеп (Сания балага узган иде), шушы гүзәл, тылсымлы якты дөньядан китмәкче булдым.

Бу сеңлем Рәисәнең җидесен уздырган көн иде. Мин вакытны ниндидер зур фаҗиганең булачагын көтеп, хәвефләнеп үткәрдем. Ниндидер сихри көч мине шушы вакыйганың эченә этәрде, аның шулай кирәк икәненә шик кал-

дырмый, шуңа әйдәде. Тик җаным гына тыныч түгел. Ул читлектәге кош кебек талпына, үрсәләнә, үзенә урын таба алмый. Шагыйрь әйтмешли, хәзер миндә ике мин. Берсе яшәү өчен көрәшсә, икенчесе – газаплардан котылырга, тәвәккәлләде. Ниплөргә? Үлчәүнең бер ягында – яшәү, икенче ягында – хурлыклы-мәсхәрәле үлем.

Аллаһы Тәгалә бар нәрсәне дә парлы итеп яраткан: көн белән төн, яхшы белән яманлык. Шулар белән беррәттән Иман белән шайтанны да. Иманнары нык булмаган куркак җаннар шайтан коткысына бирелә икән. Мин дә шундый корбаннарның берсе булырга җыенган идем.

Авырулар йоклап беткәч, халат кесәмдәге бауны капшап, туалетка юнәлдем. Бауның бер очын су торбасына бәйләп, элмәкне муенына салдым.

* * *

Минем белән янәшә койкада яткан Фәрит абый:

– Рәис, Рәис, – диеп, артымнан бастырып килеп тә життә. Бу көтелмәгән хәлдән каушап калдым. Аякларым хәлсезләнем китте. Мин иректсездән асылынып калдым. Муенны элмәк буып алды. Гырылдап тыпырчынуымны ишеткән Фәрит абый килеп, аякларымны унитаз өстенә куйды.

– Бас! – дип боерды ул.

Без бакчага чыктык. Тышта җәйге төн пәрдәсе күтәрелеп, офыкларга сизелер-сизелмәс алсулык йөгергән. Тирәякта горур тынлык тантана итә. Һава шулкадәр саф ки, ул үзе агылып эчкә керә, бөтен тәнгә рәхәтлек тарата. Бар тереклек шау-шулы көнне, якты Кояшны каршыларга әзерләнә. Тормыш дәвам итә.

Тәмәке кабыздык.

— Беләм, хәлең авыр. Ә кемнеке җиңел соң? Синең кырында яткан Сашаныкымы?

— ...

— Шул-шул. Бөтен тәнен каплаган аның псориазы янында безнең экземалар чүп кенә ул. Безнең өле өмет бар. Аныкы юк. Өмет яшәтә кешене. Өметсез кеше — юк кеше. Саша да хәтта нәрсәгәдер өметләнә. Димәк, яши дигән сүз. Тормыш дигәнең, ай-һай катлаулы штука. Ул сине тегеләй дә, болай да сынап карый. Аңа карап җебеп төшәргә ярамый.

— Мине күп сынады инде ул.

— И-и, бу әле аның баласы, түрдә икән анасы, дигәндәй, Аллаһы Тәгалә боларының әүвәлен-ахырын хәерле кылып, сынауларның тагы да рәхимсезләрен бирә күрмәсен.

— Бер караганда, яшәү — үзе сынау. Без көн саен сынау үтәбез.

— Бик дөрес әйттең, менә шул сынауларда сынмый калырга кирәк. Яшәүнең бөтен асылы да шунда. Син яшь әле. Тормышка яңа аяк басып киләсең. Баскан җирең ныык булсын. Хатыныңны, булачак балаларыңны киләчәккә алып барырлык ир кеше бул.

Без тагы берәрне кабыздык.

Фәрит абыйның сүзләре йөрәгемә сары май булып ятты, саташкан күңелемә юл күрсәтте, яшәргә өмет уятты. Әйтерсең, иңнәремне басып торган авыр йөктән бушанып калдым. Күптән башлаган эшемне очлаган кебек, канәгатьлек кичердем. Бөтен тәнемә рохәтлек йөгерде.

— Һай, һавасы да һавасы, сулап туя алмассың, валлаһи. Салкын чишмәләрнең тәмле суын эчәсең мени. Кара бу матурлыкны, искитмәле бит. Йөрәкләрне яшәртеп җибәргәндәй итә Шушы каләр тылсымлы дөньяда син дә бер җан иясе булуың бәхет бит, ә?! Бәхет. Бәхетнең дә өле ниндие!

Миңа уңайсыз булып китте. Фронт юлларының газапларын кичеп, күзләре күрер-күрмәскә әйләнгән бу кешенең тормышка булган чиксез мәхәббәте алдында оят иде миңа. Гомерем буе шул вакыттагы ахмаклыгымны гафу итә алмый жан газабы кичердем. Үз-үземне битәрләп, оялып яшәдем. Һәм бу вөждан газабы бүген дә дәвам итә. Бу хәлләргә кырык ел вакыт үтсә дә. Фәрит абыйга мең-мең рәхмәтемне әйтеп, аның алдында башымны иям.

Ашыйсы ризыгы, эчәсе суы, сулыйсы сулышы бетмәсә. Әҗәл үтерми кешене, дигән борынгылар. Моның шулай икәнен мин үземнең яшәвем белән исбатладым.

...Безнең авылда Әмир исемле телсез малай бар иде. Дүрт яшемдә вакытта шул Әмир белән бер-беребезне чанада тартышып уйнаганбыз. Чират миңа житкән. Әмирне тарту жиңел булмаган, күрәсең. Әле генә тимерчедә дагалаткан атына атланып, хат ташучы абыйның түбән очка төпсп барышы икән. Мин йөгереп килеп, чанамны шул атның койрыгына бәйләмәкче булганмын. Әлбәттә ат моңа һич кенә дә риза түгел. Һәм арт аягы белән жилле генә итеп, селтәп тә жибәргән. Сул яңагым иягемә кадәр салынып төшкән, мине үлем хәлендә өйгә кайтарып салганнар. Бернинди тереклек әсәре булмагач, жирләү хәстәрен күрә башлаганнар. Моннан алда гына кызамык авыруыннан вафат булган Хәмит һәм Әдһәм абыйларымның хәсрәтеннән айнып житмәгән әти-әнием өчен бу хәл чын фажига булган. Ул арада әбием белән бабам да килеп житәләр. Мине шашып яраткан Галиулла бабам өнсез үк кала.

Нишләмәк итәсең, язмыштан узмыш юк. Минем үлеме, тереме икәнемне тәгаен генә әйтергә табиб та юк. Инде юарга дип колашага салганда, зәгыйфь кенә итеп ыңгырашын куйганмын. Кырык көн аңсыз-һушсыз ятканмын. Әтием белән бабам дуңгызның эч маен эретеп битемә ябып дәвала-

ганнар. Әнием авызыма кашык белән су салып торган. Шулай итеп, мин исән калганмын. Моннан алтмыш ике ел элек ат дагасы салып калдырган тамга бүген дә битемне бизәп тора.

Әҗәл белән бу минем беренче очрашуым булды.

Икенче мәртәбә ул миңа биш яшемдә «сәлам биреп» үтте.

Ир бала үзенең шуклыгы аркасында әллә нинди хәлләргә мажараларга тап була бит ул. Мин дә шук идем. Сеңлем Рәисә яткан бишеккә үрмәләп менгәнмен дә бишек ыргагы ялгыш бугазыма кадалган. Әгәр сеңлем куркуыннан ачыргаланып кычкырып елап җибәрмәсә үле гәүдәм шул ыргакта эленеп калыр иде. Монысының да җөе бугазымда саклана.

Мин чик сакчысы булып Памир таулары арасында хезмәт иттем. Безнең Баш-гумбез (Баш каберлек) исемле застава диңгез тигезлегеннән 5200 метр биеклектә тора иде. Ул чакта – бу 1954-1957 еллар – мондый югарылыкта самолетлар да, вертолетлар да очмый иде әле. Һава аяз булган көннәрдә генә кечкенә самолет тау араларыннан Дүшәмбедән таулы Бадахшанның баш шәһәре Хорохка оча ала иде.

Тауларның табигате гажәп кырыс. Җәй башланырга да өлгерми, ул арада үтеп тә китә. Перевал ачылган шул кыска вакыт эчендә машиналар Кыргызстаннын Ош шәһәреннән солдатларга еллык азык-төлек, атларга комбикорма, тюкланган печән, көрпә ташып куялар иде. Кыскасы, без тау башында бөркетләр, тау кәҗәләре янәшәсендә яшәдек. Яңа ел белән тәбрикләгән открытка-хатларны 1 Май бәйрәмнәрендә алып укыдык.

Кислородның 44 процент җитмәве безгә – бу шартларда туып-үсмәгән солдатларга авырга туры килде. Күпләребезнең чәчләре коелды, тешләре төште. Кайберләребез йөрәккан тамырлары авырулары алды. Кыш көннәрендә салкыннар минус 50 градуска кадәр җитә Әфганстан сугышчылары үзләренең җырларына керткән «афганец» (әфган җиле) тау араларыннан ыжгыртып искәндә туннар да, бүрекләр дә саклый алмый иде. Үзәкләргә җелекләргә үткән бу салкыннардан, бу җилләрдән бары тик ташлар ташып кына җылына идек. 8-10 сәгать сакта торганда абына-сөртенә ташыган таш өемнәре көн саен бер урыннан икенчесенә күчеп торды. Атларыбыз ничек түзде икән, белмим. Хәер, аларны да өледән-әле алыштырып торалар иде.

Шундый зәмһәрир салкын көннәрнең берсендә (чик буе асылда төнлә саклана) дозор булып нарядка киттек. Мин өченче елымны хезмәт иткәнлектән, нарядта өлкән идем. Без заставадан унике км сраклыктагы яшерен урынга җитеп, хәлне әйтеп, заставага шалтыратырга тиеш. Ярты юлны узгач буран күтәрелде, ишелеп кар ява башлады. Монда ул кайчак шул кадәр тыгыз булып ява ки, әйтерсең син кар болытлары эчендә Янында барган атлы кешене дә күрмисең. Хәтта күккә аткан кызыл ракеталар да кар катламына кереп, сүнгәнче үк күздән югала.Шундый бураллы төннәрнең берсе иде. Билгеләнгән урынга җитеп, застава белән хәбәрләшкәч, атларыбызны кайтыр юлга бордык. Озак кына барып, атларыбыз туктагач күтәрелеп карасак, өнсез калдык: Совет хөкүмәтенең кан дошманнары – басмачылар торган киез йортлар янына килеп чыкканбыз. Алар монда көтү көткән булып, безнең һәр адымыбызны күзәтеп торалар иде. Әгәр сизсәләр, башларыбыз киселмәсә дә зур халыкара гауга чыгасы көн кебек ачык. Яки кол итеп саткан булырлар иде. Миңа эсселе-суыклы булып китте. Күңелемә бала чакта әбием ойрәткән, инде күптән онытылган дип йөргән догалар килеп төште. Аларны ашыга-ашыга укый башладым:«Йа, Раббым рәхмәт-шәфкатеңнән ташла-

ма?» Шунда могҗиза булды: алдыбызда бүрек кадәр кызыл шар калыкты. Калыкты да, акрын гына тәгәрәп тә китте. Атыма бернинди ым ясамасам да, ул шарга иярде. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән хасил булган бу мәрхәмәтле кызыл шар заставага кайтып җиткәч кенә юкка чыкты.

Әҗәлнең салкыны миңа тагын бер мәртәбә кагылып узды әле.

Хәзерге Мәскәү районы базары урнашкан урында элек яртылаш җиргә сеңеп барган бер катлы агач йортлар иде. Тукталышның хаҗәте булмаган бу араны трамвай-троллейбуслар зур тизлек белән узалар иде.

Эштән кайткан чакларымда шул урынга җиткәч, трамвайдан сикереп төшеп калгалый торган начар гадәт кердә берчак. Имеш, юлны кыскартам. Сикереп төшәм дә, әлеге авып-түнеп барган йортлар аша узып, Җиләкле бистәсенә, өйгә кайтып җитәм. Ул көнне дә шулай эшләдем. Тик, гөнаһ шомлыгына каршы, трамвайның алгы ишегеннән сикердем. Төнлә явып үткән карның өсте йомшак сыман күренсә дә, асты боз булып чыкты. Мәтәлчек атылып, егылып барганда янымнан выжылдап каршыга килүче трамвай узып китте, мин аның юлына төшеп утырдым. Секундлар белән исәпләнгән бу арада ниндидер илаһи көч мине трамвай астына керүдән саклап калган, монысын бер Аллаһы Тәгалә генә белә. Югыйсә, мине трамвай өзеп китәргә тиеш иде.

...1969 елның 4 май көнне гаиләбез белән циркка киттек. Без килгәндә халык тамаша залына утырышкан, вестибюль бушап калган иде. Безне мәшһүр клоун Юрий Никулин каршы алды. Ул шунда әрле-бирле йөри иде. Никулин йөгереп килеп, дүрт яшьлек улыбыз Ирекне кочып күтәреп алды.

— Без сезне кайчаннан көтәбез, ә сез соңга калып йөрисез, — диде ул шаяртып, Ирекнең башыннан сыйпап, елмаеп, безне тамаша залына озатып калды. Урыныбыз иң өске рәтләрнең берсендә иде. Кергән шәпкә түзәрлек булса да, бераздан зал яхшы ук эсселәнеп, бөркүлөнеп китте. Миңа һава җитми башлады. Тыным бетеп, күз алларым караңгылана, каршымда ниндидер түгәрәкләр оча, сикерешеп уйный. Мин аңымны җуйганмын. Һушыма килеп, күзләремне ачсам, хатыным Сания, уларым Расих, Ирек нишләргә белми аптырап, янымда басып торалар. Балаларны урынарында калдырып, Сания белән цирк артистларының медпунктын эзләп киттек. Шәфкать туташы шунда ук ашыгыч ярдәм чакыртты. «Инфаркт-миокард, стенокардия-напряжения» дигән диагноз белән мине хастаханәгә илтеп тә салдылар.

Моңа 1967 елның 8 Мартын — Хатын-кызларыбызның бәйрәмен каршыларга ниятләнеп йокларга яткан Нәҗип абыебызның мәңгегә күзен йомуы да сәбәпче булгандыр.

Менә утыз җиде ел инде йөрәк бакасы дигән авыру белән икәү, бер-беребезне хөрмәт итеп гомер кичерәбез.

... Мин боларны нигә сөйлимме? Хак Тәгалә безгә сынауларның төрлесен җибәреп кенә тора. Йә киребеткән мәгънәсез бер өлкән мастер килбәтендә килә ул сынау, яисә якын кешеләреңне мәңгелеккә югалту нәтиҗәсендә йөрәк әрнүләре булып инә Адәм баласының Иман дәрәҗәсе әнә шул хәлләрдә үз-үзен ничек тотуына карап бәяләнәдер, мөгаен. Мин бу сынауларны ничек, нинди билгегә тапшырганмындыр, әйтә алмыйм, монысы да — Аллаһы Тәгалә ихтыярында.

ТУНЫМНЫ САТСАМ САТАМ...

Бәхетемә булгандырмы, әллә бәхетсезлеккәме, белмим, мәңге яшел субтропик үсемлекләр, шау чәчәк-гөлләргә төренгән Кара дингез буеның данлыклы пеләжләрендә кызынып ятарга, яр буйларына тезелеп киткән берсеннән-берсе гүзәл, берсеннән-берсе зиннәтле, патша сарайларына тиң йортларда яшәп, сәламәтлегемне нығытырга насыйп итте миңа. Элеккеге Рәсәйнең югары катлау даирәләре, кенәзләр, графларның сарай-йортлары үз вакытында архитектураның иң мөкаммәл үрнәкләрен туплап, югары зәвык таләпләренә җавап бирерлек итеп төзелгән булган. Әлбәттә, бу хакимнәр кеше акылының бетмәс-төкәнмәс фантазиясен, сәләтен чагылдырган, кабатланмас төсләр, формалар белән бизәлгән әлеге мәһабәт пулатларны үзләренә дип салдырганнар. Тик игелеген генә күрә алмаганнар.

Мин озак еллар экзема авыруыннан интектем. Аның да әле, каһәр суккыры, юеш экзема дигән төре иде. Аның юк кына сәбәпләр аркасында да ялкынсынып, азып китүе мине озак вакытларга сафтан чыгара, айлар буе хастаханәдә ятып дәваланырга мәҗбүр итә иде. Ярамаган берәр ачы-төче нәрсә ашасаң, килешмәгәнне эчсәң, ул үзен шунда ук сиздерә башлый. Хәмерне әйтәсе дә юк инде. Тозлырак ризык ашау да ярамады. Икенче көнне үк тәнгә бетчәләр чыга башлый. Алар тәмле-татлы кычытып зураялар һәм тишелеп ага башлыйлар. Кайвакыт шулай азына иде ки, тәннең бөтен җиреннән саркып су чыга, урыны-урыны белән чишмә булып ага, хәтта керфек очларыннан тамчыларга тотына. Авыруның болай кискенләшеп киткән вакытында йокы кача, реваноль дигән саргылт сыекча сөндерелгән марляга уралып, төнемне көне-төне чылатып утыра идем. Ул тәндәге «чишмәләр»не киптереп, тирене тарттырып куя. Шул эпләнеп кипкән урыннар аз гына саксыз хәрәкәтләрдән дә ертылып китәләр һәм ярыклардан янә юешлек саркый башлый. Тире кибеп җитмәгән урыннарга ичмасам май да сылап булмый. Ул шунда ук дымлана, аннары лычкылдап чыга. Һай, газаплар күрдем дә инде экзема дигән каһәр суккыры белән! Аның кычытуыннан изаланырга дошманыңа да язмасын икән. Бу аның өчен дә рәхимсезлек, җәзаның да иң авыры булыр иде. Һәр яз минем күңелемә шом салып, хәвеф алып килде. Табигатьнең нәкъ шушы гүзәл чагында, барлык жан ияләре кебек үк, экземам да уянып, агач бөреләре сыман бүртенеп, бетчәләре тулышып, «чәчәк ата». Күп тә үтми, ярларыннан ташып чыккан елгалар, гөрләвекләр кебек, төнем суланып ага, тамчылар тама башлый.

Берничә мәртәбә хастаханәдә ятып чыгып, сихәтләнә төшкәч, профкомнан юллама биреп, дәвалануны дәвам иттерү өчен Кара дингез буена җибәрәләр иде. Бу хәл озак еллар шулай кабатланып торды. Тагын шунысы да гажәп иде: төрле кешедәге бер үк төрле экземага бер үк дәва килешми икән, башка җирләрдәге санаторийларның бер дә файдасы тимәде. Миңа тик сасыган йомырка исе килеп торган мацест ванналары һәм Кара диңгезнең үтә күренмәле тозлы суы шифа бирде. Көннәрнең берендә мин эшләгән райкомның секретаре кәгазендә авырып китте. Аның ике кешегә дип алынган путевкасы «яна» икән. «Бирәм дисә колына, чыгарып куяр юлына» булды инде бу. Минем исә чираттагы ялым килеп җиткән чак иде. Беркөнне иртән «беренче»

үз янына дәшеп, юлламаларны миңа тәкъдим итте. Бу инде күктән төшкән бәхет кебек булды. Озак тартмый-сузмый, табиблардан анализ кәгазьләре алып, хатыным Сания белән юлга чыктык. Поездга утыруыбызга ике тәүлек тулар-тулмаста санаторийда идек инде. Июнь-июль айларындагы эсселек бераз сүрелә төшеп, Кавказда «алтын сезон» башланган чак иде. Хәер, монда елның һәр фасылы сокландыргыч матур. Рәхәтләнеп ял итәргә бөтен шартлары килгән. Бу якларның гүзәллеге беркайчан да жуелмый, ел әйләнәсендә үзенә тартып тора. Аның мәңге яшел агач-куаклары, орчыктай төз мәһабәт пальмалары, тагын без белмәгән-күрмәгән мең төрле башка нәфис үсемлекләрнең ысплай кәүсәләре, күркәм төс-кыяфәтләре белән кешеләрне сихерли, аларга рәхәтлек, жан тынычлыгы бирә. Юл буйларын, зур осталык, зәвык белән салынган сукмак кырыйларын, бакчалар әйләнәсен шакмаклап кыркылган куаклар урап алган. Һәр тарафта гөл-чәчәкләр балкып утыра. Ул сылуларны шундый итеп үстергәннәр ки, әйтерсең, синең алда төрле ымсындыргыч төсләре белән данлыклы Иран келәме җәелеп ята. Һәр жирдә пөхтәлек, чисталык хөкем сөра.

Әлбәттә инде, Кавказның энҗе-гәүһәре саналган, үзенең илаһи суы, ярсып дулаган дулкыннары белән миллионнарны әсир иткән тылсымлы Кара диңгез, бу искитмәле гүзәллекнең тажы булып тора. Башлары болытларга ашкан, мәңге яшел урманнар белән капланган мәгърур таулар да ямь өстенә ямь бирә. Тауларның яшел шәүләсе диңгез өстен кочып, йөгерек дулкыннарда тибрәлә. Әйтерсең, алар абыйсеңелле бертуганнар. Берсе ташкыялар өстендә үскән урманнарга су эчерсә, икенчесе – үзенең затлы яшел хәтфәсенә бөркәнеп, назлы кояш нурлары балкыган су өстендә иркәләнә, дулкыннарында чайкалып коена. Алар бер-берсен тулыландырып, бер-берсенә ямь биреп, көч-куәт алышып

яшиләр. Диңгез пакылеге, урман сафлыгы кушылган һаваның чисталыгын, башларны әйләндерерлек тәмле хуш исен әйтеп тә торасы юк. Аны сулаганда челтерәп аккан саф чишмә суларын эчкән кебек буласың, ләззәт аласың. Бу бигрәк тә иртәнге сәгатьләрдә шулай. Әйтерсең лә сиңа дәртләрман үзе агылып кера.

Вакытыбызның өйләгә кадәр өлешен төрле дәвалану процедуралары алып уздырсак, төштән соң пеләждә кызынып үткәрәбез, диңгездә коенабыз. Мин бигрәк тә инде. Төбе күренеп торган төзлы судан чыгып, бераз кызынган сыман итенәм дә янә үтә күренмәле йөгерек дулкыннарга чумам. Тәндәге кутырлар күзгә күренеп кими, яралар берәм-берәм йомыла, төзәлә бара. Диңгез суының бәрәкәтле шифасы әйтеп бетергесез. Аның файдасын бүген дә тоеп яшим. Мин аңа мең-мең рәхмәтле. Ул күрсәткән игелекне һич кенә дә онытырга хакым юк. Мең яшә, Кара диңгезем!

Кемнең кулында, шуның авызында, дигәннәре бик тә төгәл әйтелгән шул. Моның шулай икәнлегенә тагын бер кат үзем күреп ышандым. Дөрес, үзем дә өлешсез калмадым кебек. Акмаса да, тамгалады. Мине дә курорт-санаторийларга жибәреп тордылар. Ләкин минем ипе райком инструкторы кебекләрнең яшәү шартлары партиянең югары дәрәҗәләрнеке белән чагыштырганда жир белән күк арасы кебек иде шул. Әйтик, райком секретареня тиешле путевка белән баргач, безнең номер аерым-аерым ике өлештән тора. Һәрберсендә уңайлы кин ятак, башка жиһазлар, кирәкярак урнаштырылган, ишектән керүгә үк йомшак диван, кәнәфиләр, газета-журналлар өчен тәбәнәк өстәл һәм шкафләннәрс белән кин иркен кунак бүлмәсе, шунда телефон куелган. Өстәл өстен һәркөн яңа гына кисеп алынган чәчәк бәйләме бизи. Эчәм дисәң, берничә төрле минераль су куелган.

Әлбәттә, бу уңайлыкларның барысы да безнең өчен дип түгел, әйткәнемчә, райком секретарьларыннан башлап тагы да югарырак урыннарда утыручылар өчен оештырылган. Кыйммәтле җиһазлар да алар өчен дип куелган. Монда синең кем булып эшләвеңне сорамыйлар, анысын торган бүлмәңнең дәрәҗәсе билгели. Шуңа карап кадер-хөрмәт күрсәтелә, өстәмә хезмәтләр дә кылына.

Бу төр санаторийларда ашау-эчү дә мулдан. Җаның ни тели, шул бар. Тәмледән тәмле җиләк-җимеш салынган ваза һәрчак тулып торыр. Яшелчә салатларының берничә төре аерым өстәлләргә куелган. Нәфесең кайсына төшсә, шуны-сын ал. Иртәнге ашка кызыл, кара уылдыклар белән әзерләнгән бутербродлар бирелә, алар янына атланмай, сыр кебек дефицит ризыклар да куелган була. Ит ризыкларының да күңеленә хуш килгәнен сайлап аласың. Официантка ханым аларның төрледән-төрлесен өстәмә ровештә тәкъдим итеп тора. Бу ризыклар, теге профсоюз санаторийларындагы кебек, ит исе кертеп ясалган котлетлар түгел инде. Алар зур-зур калҗалардан җиренә җиткереп, тәмле, йомшак итеп пешерелгән. Мин үзем ашау өчен түгел, ә яшәү өчен ашаучылар җөмләсеннән булсам да, көндезге һәм кичке ашларның да шушылай мулдан булуы, ни әйтсәң дә, канәгатьлек хисләре уята иде. Кыскасы, башка шифаханәләр белән чагыштырганда, җир белән күк арасы иде. Җәннәт шикелле гүзәл Гагра каласындагы шушы санаторийда, «ашау байдан, яшәү Ходайдан» дип, моңарчы төшләргә дә кермәгән рәхәттә кәеф-сафа корып, сый-хөрмәт эчендә ятабыз. Саниямнең гаҗәпләнүенә чик юк. Гомерендә беренче мәртәбә күрүе ләбаса.

— Менә ни өчен ел да монда килергә ашкынасың икән син! — ди.

Аны шаккатырып, исен-акылын җибәргәнс, өнен алганы — моңа кадәр бер-берсен бөтенләй белмәгән ир-ат һәм хатын-кызларның, монда килеп бер-ике көн үтүгә парлашып, ирле-хатынлы кебек чәкердәшеп йөрүләре, хәтта төннәрен дә бергә үткәрүләре булды. Бу хәлләр аның бөтен эчке дөньясын астын-өскә китереп ташлады, күңелендә нәфрәт уятты. Шушы кешеләрнең югары трибуналардан әдәп-әхлак, оят-намус турында сафсата сатулары тетрәндерде. «Коммунистлар менә нинди икән алар!» — диде.

— Моннан соң тунымны сатсам сатам, шәлсез калсам калам, әмма бу бозыклар арасына, зина оясына үземне генә ялгыз җибәрдем юк. Барсак — икәү, юк икән — икебезгә дә юл ябык! — диде хатыным кырт кисеп. Һәм шулай булды да. Без бүтән аерым-аерым йөрмәдек.

Бу урында, Саниямнең тунымны сатсам сатам, шәлсез калсам калам, дигән сүзләренә аңлатма биреп үтү кирәктер. Алтмышынчы еллар ахырларында тормыш хәлләребез әкренләп рәтләнә башлап, улларыбыз әни карамагында калырлык булып үсә төшкәч, хатыныма Кавказга бергәләп ял итәргә барырга тәкъдим ясадым. Чөнки күп кенә парлар йә иренә, йә хатынына бирелгән путевкага бергәләшеп баралар да, путевкасы булмаганы шунда үз акчасына бүлмә алып тора. Берочтан кирәкле дәвасын да ала. Әнә шуңа күрә дә чираттагы путевкамны алып кайткач, мин дә шулай эшләргә тәкъдим ясадым. Саниям гүя мондый сүзне күптән көткән, озак уйлап тормастан:

— Менә фәлән кадәр акчабыз бар, син үзеңә кирәк кадәрлесен ал. Калганына мин үземә тун сатып алмакчы булам, — диде.

Без шулай эшләдек тә. Мин бер тиенен әрәм-шәрәм итмәи, булган акчамның барысына да бүләкләр алып кайттым. Саниям да буш кул белән каршыламады. Ул үзенә яхшы тун юнәткән, миңа да тун тектерү өчен иләгән сарык тире-

се алып, яка, тышлыкларына кадәр әзерләп куйган. Рәхмәттән башка ни дисең инде бу эшкә?! Без икебез дә тунлы булдык.

Көн артыннан көн, ай артыннан ай узып, янә җәй килде. Минем чираттагы ял вакытым җитте. Алдан ук хәстәрен күреп, путевка дигәнен дә таптым. Саниямә тагын теге тәкъдимне кабатладым. Ул бу юлы да, балаларның өйдә ялгызы гына калуын сәбәп итеп, минем белән барудан баш тартты.

– Мин быел үземә мамык шәл алам, – диде.

Инде быел райком секретареның кәтмәгәндә каты авырып китүе, ниһаять, бергә ял итәргә мөмкинлек бирде. Санияга Кавказга юл ачты. Хатынымның, тунсыз калсам калам... диюенең тарихы шушы инде. Һәм без, хактан да, ел саен диярлек ялларыбызны бергә үткәрергә тырыштык. Бер җәйдә, туристик путевка алып, Теберда шәһәреннән башлап, Кавказ таулары аша Сухуми каласына килеп төштек. Бөтен кием-салым, азык-төлекне җилкәләребезгә аскан хәлдә әле. Икебезгә дә «Альпинист» дигән таныклык бирделәр.

Утыз алты ел бергә яшәү дәверендә Кавказ тауларын кичкәндәге кебек авырлыкларны күп кичәргә туры килде.

Без аларны кулга-кул тотынышып, бергәләп үттек.

ЭШЛӘП УКУНЫҢ ҮЗ ТӘМЕ БАР

Махсус рәвештә җыйсаң да болай ук килеп чыкмас иде, валлаһи. Цехта эшләүчеләрнең барысы да диярлек соңгы бер-ике елда хәрби хезмәттән кайткан солдат-сержантлар. Бездә кирза итекле пехота, тельняшкалы диңгезче, яшел фуражкалы чик сакчысы да, авиация, артельлерия дә, хәтта кырыс чырайлы төрмә каравылчысы да бар. Кыскасы, теләсәк, гаскәрләрнең барлык төрләре катнашында парад оештыра алыр идек. Без, әле солдат киемен дә салырга өлгермәгән кичәге хәрбиләр, үзара шулкадәр дус, тату идек ки, нәни генә проблемадан алып зур-зур мәсьәләләргә кадәр барысы да киңәшләшеп, уртага салып сөйләшеп эшләнде.

Күпләребез кичке мәктәп, техникумнарга укырга керде. Хәтта югары уку йортларында белем алучылар да бар иде. Соңыннан бу сегетләрнең бик күбе зур-зур коллективларны әйдәкләп баручы сәләтле, тәҗрибәле җитәкчеләр булып җитештеләр.

Ләкин, утыз яшен дә тутырмыйча, аракыга тончыгып, якты дөнья белән хушлашканнары да булмады түгел. Ә бит алар арасында үз һөнәренең чын осталары, зур белгечләр бар иде. Бикташев, Атнагулов, Бикмәмитов кебекләр эретеп ябыштыру буенча менә дигән инициативалы, актив инженерлар иде. Беренче космик иярченнәрнең корыч корпуслары нәкъ менә аларның акыл җимеше иде, аларның оста куллары аша үтте. Бу талантлы инженерлар генераль кон-

структор Зубецның уң куллары, заводның алтын фонды иде. Әлеге эшлекле егетләрнең сәләтенә, мактаулы хезмәтләренә үз вакытында лаеклы игътибар бирелмичә, кулларын кесәләренә тыгып, эшлекле кыяфәт чыгарып йөрүче тәти «инженерлар» белән бер рәткә куеп, 120 сум оклад плюс премия белән генә бәяләнү аларның рухын сындырды. Талантлар әрсезләнә белмәсәләр дә, кадер-хөрмәт яраталар шул.

Август урталарында булса кирәк, Абдул исемле дустым мине 22 нче кичке яшьләр мәктәбенә ияртеп алып китте. Минем әле уку истә дә юк, аңа ияреп кына баруым иде. Абдул 8 нче сыйныфка керергә алдан ук әзерләп куйган гаризасын мәктәп директоры Мәхмүтов абыйга тапшырды. Директор дигәнчә кечерәк буйлы, өлкәннәргә хас тулы гәүдәле, мөлаем йөзле, салмак кына сөйләшүче кеше иде. Беренче карашка гади генә булып тоелса да, соңрак мин аның кыю һәм тәвәккәл дә булуын белдем.

— Ә сезнең гаризагыз кайда?

Директорның көтелмәгән соравыннан бераз каушап, тотлыгып калдым

— Теге ни... Мин укырга керергә дип түгел...

— Егет кешегә вакытын бушка уздырып йөрү килешми. Менә кәгазь, языгыз гаризагызны, бергәләп укырсыз.

— Мин разрядымны күтәрмәкче булып, производство-техник курсларда укый башлаган идем шул...

— Анысы да кирәк нәрсә. Озакка сузылырмы соң ул?

— Яңа елга кадәр.

— Ярый, хуп. Алай булгач, яңа елда килерсез.

Бу сөйләшү бәлки шуның белән очланган да булыр иде. Әгәр курсларны тәмамлаганнан соң разрядны «юарга» дип кафега кермәгән булсак. Сөйләшә торгач, Абдул сүзне үзенең мәктәбенә борды.

— Ну, егетләр, безнең класстагы чибәркәйләрне белсәгез иде сез! Гел шуларны күрәсе генә килеп тора, аяк һаман шунда тарта, каһәр.

— И, туган, сине сихерләгәннәр түгелме соң?

— Булмас ла...

— Мәхәббәт белән.

— Ха-ха-ха.

Сүзгә Мансур исемле егет тә кушылды. Ул үзе дә авиация техникумының кичке бүлегендә укый иде.

— Кызларыңны, әнә, Рәискә күрсәт. Берәрсенә гашыйк булып, ул да сихерләнер бәлкем.

— Авызыңа бал-да май,- дип, Абдул кырлы стаканнарны тутырды.

— Яңа ел белән!

— Исәнлеккә, саулыкка, эшләребез уң булсын, мәхәббәт тулып торсын!

— Киттек, егетләр!

— Вакыт дигәнең укысаң да, укымасаң да уза. Аны дөрес файдалана белергә кирәк. Әнә Абдул, гомерен зыяга уздырмый. Ул хәзер тәрәз төбе кебек кышын да чәчәк ата башлады, молодец!

...Кышын чәчәк аткан Абдулыбызның туе да озак көттермәде.

Шулай итеп мин дә 1959 елда сигезенче сыйныфта укый башладым. Дөрес, классташларымның беренче яртыеллыкта үткән темаларын үзләштереп, куып җитәр өчен хәйран тир түгәргә туры килде. Тырышкан табар, ташка кадак кагар, диләрме әле. Кадагын ук кагып булмаса да, март ахырында барлык фәннәрдән дә диярлек куып җиткән идем инде. Диярлек дип әйтүем шуннан: алгебра, геометрия, тригонометрия дигәннәре баш бирергә җыенмыйлар иде. Бу фәннәрне укыткан класс җитәкчебез Әминә апа (мин аңа

гомерем буе рәхмәтле) никадәр генә тырышса да, ял көннәрендә егетләр белән әзерләнеп маташсак та, белемем а + в = ав дан ары китә алмады. Миндә бу фәннәрнең нигезләре төпле булмаган, күрәсең. Кайчак башка нәрсәдер кергән кебек тоелса да, үзенә урын, теләктәшлек таба алмаган ят нәрсә сыман, кай арада чыгып та шылган була.

Шулай да, бирәм дисә колына, чыгарып куяр юлына, дигәндәй, ниндидер могҗиза белән дип әйтимме, бер формула минем башка да кереп калды бит. Ин гаҗәбе шул: әлеге формула алда үтеләчәк темалардагы мәсьәләләрнең чишелешенә бәйле булып чыкты. Дәрестә берәр мәсьәләне чишү шушы формулага килеп төртелде исә, Әминә апа:

— Йәле, Сафин, теге кагыйдәне исебезгә төшер әле,- дия. Бу аның такта янына чыгып исбатларга кушуы инде.

Өч ел буе кабатланып килеп, инде гадәткә кереп киткән бу комедия минем өчен мәсхәрәле булып тоелса да, башкаларына тешең үтмәгәч, чыгарга туры килә Һай, оялганнарым шундый чакларда, нинди җан газаплары кичергәнемне берүзем генә беләм. Такта янына түгел, эшафотка барган кебек була иде. Бу халәтемне класташлар да сизә, минем сөйләгәнне башларын түбән иеп, күзләрен күтәреп карамый гына тыңлыйлар. Әлбәттә, Әминә апага да җайлы булгандыр димим. Ләкин журналда уңай билгеләр кирәктер шул. Дәрес, кайчак ул мине айлар буе да кузгатмый. Шулай да бер-ике "3" лене болай гына "незаконно" гына куйган була.

Чирек ахырында контроль эшләрне алгы партада утырган Рәхимәдән сүзен-сүзгә күчерә идем. Ул фәннәрне биш бармагы кебек белә. Бу эшемнең "3" лесе дә теге "незаконный"ларыныа янына кереп урнаша. Минем бу җитешсезлегемне укытучылар да, хәтта мәктәп директоры да белеп тора иде бугай. Үземнең булдыксызлыгымны аклау өчен генә булса да, шуны да әйтим: университет тәмамлап, дүртәр мең

кешелек коллективлар белән җитәкчелек иткәндә дә, башка очракларда да ул геометрия, тригонометрия фәннәрен белмәүдән мин беркайда да, авырлык күрмәдем, йөзем дә кызармады. Аларга минем гозерем дә төшмәде, мохтаҗлыгым да булмады. Ә инде исән-хисән эшләрен, һәр оешмадагы кебек, иртәдән кичкә кадәр чәй эчеп утыручы бухгалтерлар, финансистлар, экономистлар башкара һәм миңа кирәкле барлык мәгълүматны остәлемә куялар иде.

Ә менә икътисадны яхшы белү һәр җитәкче өчен мәҗбүри булырга тиеш дип саныйм. «Экономика экономлы булсын!» дигән заманнарда мин дә үземнең икъдисадый белемемне марксизм-ленинизм университетын «отлично»га тәмамлап ныгыттым.

Бер уйласаң, гаҗәпләнмәслек тә түгел бит: миңа баш имәгән шул фәннәр белән берәттән кергән физика, химия белән бернинди дә проблема булмады. Югыйсә аның балары да катлаулы формулаларга, исбатлауларга нигезләнгән. Бу фәннәрне мин яхшы билгеләренә генә укыдым. Хәтта татарчасы чамалы булган физика укытучыбыз, кагыйдәләрне башкаларга да аңлаешлы итеп төшендереп бирүемне сорап, такта янына мине чакыра иде.

Бу фәннәрне яхшы белүемнең сере армиядә чакта ярты ел буе кино-радиомехаиклар курсында укуымда булгандыр, мөгаен. Курсантлар арасыннан нибары икебез - элек тә шушы эштә эшләгән бер рус егете һәм мин - әлеге курсларны «отлично»га тәмамлап, икенче категорияле кино-радиомеханик дигән таныклык алган идек. Остәвенә мин радист та идем әле.

Мәктәптә гуманитар фәннәрне бигрәк тә яратып укыдым. Бераз тыйнаксызрак тоелса да әйтим, мин аларны су кебек эчтем, бик үк тирәндә булмаса да, балык кебек йөздем. Монда да миңа армиянең файдасы зур булды. Киномеха-

ник, димәк, мәдәни-агарту хезмәткәре буларак, мина ешкына иҗтимагый-сәяси темаларга әңгәмәләр үткәрергә халыкара хәлләргә күзәтүләр ясарга туры килә иде. Әлбәттә, һәр чыгыш белем, өзерлек сорый. Моның өчен күп укырга кирәк. Һәм мин частька килгән газета-журналларны кулыма блокнот тотып укып барырга тырыштым. Фирдәүси, Рудаки, Диккаки кебек мәшһүр шагыйрьләрнең әсәрләреннән ләззәт алдым, сихри чал тарих фәне дә өермә кебек бөтереп, мине үзенә тартты. Кинобудкамда җыелган китапларның күбесе күренекле шәхесләргә, тарихка кагылышлы иде. Шуңа да мәктәп дәреслекләре кысаларындагы тарихны да, университетта укыган кадәресен дә бер үк дәрәҗәдә җиңел үзләштердем. Алган белемнәр күңелгә рәхәтлек бирде.

Рус әдәбияты, бигрәк тә татар әдәбиятына кергән классик язучыларыбызның әсәрләрен элек тә кат-кат укыган булуым, аларга тирән анализ ясаган кайбер хезмәтләр белән танышлыгым бу фәннәрне дә җиңел үзләштерүемә ярдәм итте. Өстәвенә, беренче шигырьләре газета-журнал битләрендә күренә башлаган Тәүфыйк Камалиев белән мин танылган фронтовик шагыйрь Гали Хуҗиның әдәби түгәрәге әгъзалары да идек. Моны белгәч, татар теле укытучыбыз Мәгъмүрә апа таләпләрне дә безгә башкалардан югаррак итеп куйды. Ул таләпләр кайчак Тәүфыйкны чыгырыннан чыгарсалар да, без мөмкин кадәр яхшырак укырга тырыштык. Җитмәсә, Мәгъмүрә апа белән без күптәнге танышлар да булып чыктык. Мин аны башка беркемнекенә дә охшамаган язуына карап исемә төшердем. Аның кебек, хәрефләрне ярым язма, ярым басма итеп, почмакларын шакмакландырып берәү дә яза алмастыр. Менә шушы үзенчәлекле язу иясе моннан унике еллар элек безнең авылга килеп, татар

теле укыта башлады. Күрәсең, ул институт юлламасы белән җибәрелгән булгандыр.

Бүген, олыгайган көннәремдә, шул чакларны исемә төшерәм дә, Эминә апаның ышанычын аклау өчен ник тагын да ныграк тырышмадым икән, дип үземне битәрләп куям. Хәер, моның өчен минем вакытым да булмады кебек. Эшләү, уку өстенә, цехтагы иҗтимагый эшләрнс дә әләләр иде бит. Парторгның бер-бер артлы биреп торган бетмәстокәнмәс партйомышларыннан һич арынып булмады.

...Мәхәббәт. Бер башлагач, бу хакта да сөйләми калып булмый инде. Сөю-сөгадәттән башлар әйләнгән чаклар иде. "Язгы хисләр" дигән шигырем дә юкка гына язылмагандыр.

Белмим инде нишләргә дә,
Кайсын гына сөяргә?
Кемне күкрәгемә кысып,
"Җаным-бәгърем!"- дияргә?

Белмим, элек бу кызларны
Ничек күрмәдем икән?
Әллә, димен, гөлләр белән
Шытып чыктылар микән?

Әллә инде яз аларны
Үз яменә бизәгән,
Бизәгән дә, егетләрнең
Ут йөтасын бслмәгән...

Ни булса да, һәрберсенең
Нур балкый йөзләрендә
Ләкин бер кыз өчен генә
Урын бар йөрәгемдә

Бар иде шул соеп һәм сөелеп йөргән чаклар.

Их, яшьлек, яшьлек,
Калдың ераста.
Кайтавазларың
Күкри йорәктә.

Иң аянычлысы шул: мәктәптә бер генә сыйныфны да мин тулысы белән укый алмадым. Сигезенчене икенче яртыеллыктан башлаган булсам, тугызынчы белән унынчы классның да соңгы чирекләрен хастаханәдә үткәрдем. Хәтта аттестатны да чыгарылыш имтиханнарын тапшырмый гына алдым. Шушылай хастаханәләрдә озаклап авырып ятуымның сәбәбе армиядә чакта тарган фажигале хәлләргә бәйле иде. Хәер бер жай чыкканда ул хакта да сөйләрмен әле.

НИМЕСЧӘ ДӘ ЯХШЫ БЕЛӘ!

Кичке татар яшьләре мәктәбен эттем-торттемгә тәмамлап, бөрочтан кызып китеп, университетның журналистика бүлегенә укырга кермәкче иттем.

Юк, мин көндәлек матбугать казанында да кайнамыйм, мәдәният-мәгърифәт өлкәсендә дә эшләмим, уналты яшемнән моторлар төзү берләшмәсенең 7 нче разрядлы бөр слесаре мин.

Шулай да имтиханнарда мица жил уңайдан исеп, уңышның да берсе артыннан икенчесе килеп торды. Була бит кайчак шундый гажәп хәлләр!

Беренче сынау иншасын «4»легә тапшыргач, дәртләнеп китеп, калган ике фәннән дә дүртле-бишлегә биреп ташлаганмын. Арада кысылып чит тел имтиханы гына калды. Нишләргә? Миңа инглиз телен дә, французныкын да өйрәнергә туры килмәде бит. Кайчандыр, моннан сигез ел элек авыл мәктәбендә укып йөргәндә сугыштан имгәнеп кайткан Әнәс абый нимес телен ихлас күнелдән ойрәтергә тырышты тырышуын. Ләкин ул вакытта уку кайгысы түгел, тамак туйдыру кайгысы иде шул. Ир-атлар фронттан берәнсәрен кайта торсалар да, безнең ише 12-13 яшьлекләргә колхоз эше житәрлек иде әле. Яңа елга кадәр ындыр табагында иген суктырдык, басулар аз гына кардан арчыла башлауга, тубыктан былчыракка бытып, кар сулары ерып, былтыргы бәрәңге жыйдык.

Әнәс абыйның бер генә дә яраланмаган, имгәнмәгән

җире юк иде. Үзен шушы кадәр гарип итеп калдырган нимес илбасарларына карата бу күркәм кешедә олы нәфрәт тә, кан дошманлыгы да булмаган, күрәсең. Югыйса аларның телен болай оста итеп өйрәнмәс иде. Моңа инде 55 ел вакыт үткән булса да, әле дә хәтеремдә: аның бер яңак сөяге бөтенләй ватылып беткән иде. Кыйнычыклардан җыелган шул яңагы иреннәрен бераз тарттырып, чалшайтып тора иде. Үзенең сылу кыяфәтен җуйган ул иреннәр нимес сүзләрен шулкадәр җиренә җиткереп, аһәңле итеп әйтәләр иде ки, авылдашлар: «Нимесләр Әнәстән нимес ясап кайтарганнар»,– дип шаярталар иде. Изге күңелле, олы йөрәкле кеше иде ул.

...Әйе, калды бит арада кысылып шул чит тел имтиханы. Бернишләп тә булмый, киттем шул «Кафедра иностранных языков» дигән бүлмәгә Кердем. Анда ике ханым, үз ана телләре диярсең, рәхәтләнеп нимесчә гәпләшеп утыра. Мин ишек төбендә боларның сөйләшкәннәренә хәйран калып торам. Ниһаять, ханымнарның яшьрәге күтәрелеп карады.

– Йомышыгыз бармы?

– Теге, ни... менә сезнең фәннән имтихан бирәсе иде ләҗ– дидем кыяр-кыймас.

– Рәхим итегез! – диде әлеге ханым, буш өстәлләрнең берсенә күрсәтеп. – Сез сүзлек белән тәрҗемә итәсезме, әллә?..

– Сүзлек беләндер инде...

Гали үз эшендә Вәли дә үз эшендә дигәндәй, һәркем үз шөгыленә чумды. Газет текстындагы сүзләрнең тәрҗемәсен кат-кат карый-карый, көч-хәл белән бер җөмләне аннан-моннан ерып чыктым шикелле. Сүз Ю.Гагаринның космоска менүе турында бара иде. Инде икенче җөмләнең ахырына җитеп килгәндә теге ханым:

– Ну, егет, эшләр ничек бара?– дип сорап куймасынмы.

– Бик бармый шул...

– Ярар, бергәләп тотынсак, бәлки китеп тә барыр,– дип яныма ук килеп утырды ханым.

Мин беренче җөмләне вата-китә укып, ничек тә ерып чыктым бугай. Ә инде икенче җөмләдән соң көймәм бөтенләй комга терәлде. Ханымнар бер-берсенә карашып алдылар да, үзара нимесчә сөйләшә башладылар. Күз төшерсп алуларына караганда, сүз минем турыда бара. Янымда утырган ханым: « Нишлибез? Бу бернәрсә дә белми бит, тупой, как Сибирский валенок»,– диде бугай. Тегесе язган жиреннән баш калкытып: «Нишлисең, куй икеле!» диде.

Алар сөйләшкәндә мин «цвай» дигән сүзне шәйләп алдым.

– Пожалыста, цвай түгел, драй,– дидем.

– Минем бу сүзләремнән болар авызларын ачып, аптырап калдылар. Бераз аннарына килгәч, эчләрен тотып, шаркылдый-шаркылдый көлә башладылар.

Бу ханымнарының нәрсә турында сөйләшкәннәрен аңлагач, димәк, нимесчә белəм булып чыга бит инде.

–Куй шуңа драй! – диде читтәрәк утырган ханым, көлүдән чыккан күз яшьләрен сөртеп.

Мин дә җанланып киттем.

– Сезнең бу өчлегезне акларга сүз бирәм! – дидем.

«3» ле куеп чыгардылар. Менә бит ул, мәйтәм, тел белүнең файдасы! Әгәр Әнәс абый нимесчә санарга өйрәтмәгән булса, «2» ле чәпәп чыгаралар иде бит.

Шулай итеп, мин журналистика бүлегенең читтән торып укучы студенты булдым. Өч курс уку дәвамында нимес теленә биргән көчемне, вакытымны башка берәр фәнгә сарыф итсәм, һичшиксез, диссертация яклырлык белем туплаган булыр идем. Өч ел буе көн саен, кимендә 1-2 сәгать,

шушы телнең грамматикасын өйрәнеп, газет текстларын тәрҗемә итә-итә үтте кадерле гомерләр, студент еллары.

Ахырда бездән чит телдән сынау алучы ханым үз вакытында әле Керинский акчаларын алып укыткан, кем әйтмешли, утны-суны кичкән, олы яшьтәге мөгаллимә иде. Ул газет текстының бер өлешен укырга, тәрҗемә итәргә куша. Берочтан барлык грамматика кагыйдәләрен дә җентекләп сорый. Бу процедураны берничә мәртәбә кабатлап, синең җан тиренне сыккач кына, «Еле-еле душа в теле».-дип, зачет яки «3» ле куеп җибәрә. Тик шулай да белемем Әнәс абый (урыны Җәннәттә булсын) салып калдырганнан әллә ни артмады. Бу телнең миңа бервакытта да кирәге чыкмады. Менә шулай, җәмәгать, укымадык без ул долманнарның телен! Кирәге юк иде. Хәзер әнә, чит тел белмәсәң, ындыр артына да чыгып булмый.

СУКЫР ӘЧӘК һӘМ ЮЫЛМАГАН ДИПЛОМ

Дөньяны шаккаттырган гаҗәеп хәлләр, акыл колачламас серле вакыйгалар аледән-әле булгалап тора.

Казан университетының журналистика бүлеген тәмамлап, диплом алгач, без, яшь белгечләр, бу шатлыкны үзебезчә билгеләп үтәргә уйладык. «Казан» ресторанында тыйнак табын ясап утырмакчы булдык. Еллар буе бергә укып, кылдан нечкә кылычтан да үткен фән күперләрен бергә кичкән дус-иптәшләр белән аерылышу согатьләре килеп житте. Кемдер районнардагы гәзит-радио редакцияләренә, ә кайберләребез илнең ерак төбәкләренә үк таралышачак, әнә шул күңел кылларын чиертә, моңсулык тудыра. Ни әйтсәң дә, хушлашу-аерылышулар күңелле хәл түгел шул. Озаккамы бу? «Бәлкем айга, бәлкем елга, бәлкем гомерлеккәдер?» Анысын инде Аллаһы белә.

Минем үземнс дә Чүпрәле районы газетасына димләп караганнар иде. Ләкин ике нәпи улым белән хатынымны калдырып, торыр урыны да булмаган җиргә китәргә батырлыгым житмәдс. Бер жае чыгар әлс дип, заводта калып торырга булдым. Эшем зарланырлык түгел. Күтәреп-көчәнеп азапланасы да, пычракка батасы да юк, җылы, якты, тын бинада ак халатлар кисп эшлибез. Озак еллар хезмәт итү дәверендә эшемнең үзенә генә хас яшерен серләрен аңларга, бөтен нечкәлекләрен өйрәнергә омтылдым. Һәм, ниһа-

ять, бик зур осталык, үтә төгәллек таләп итүче слесарь-лекальщик һөнәренең чын белгеченә әверелдем. Мин хәзер иң югары – җиденче разрядлы оста.

«Корал эшләр, ир мактаныр,» – диләр бит. Бу әйтем минем һөнәргә аеруча туры килә. Чөнки без ясаган штамп, шаблоннар ярдәмендә меңләгән детальләр коелачак, күп төрле җитештерү кораллары ясалачак. Слесарь-лекальщик үз эшен никадәр зур төгәллек белән башкарса, коеласы, сугыласы детальләрнең сыйфаты да шул кадәр югары булачак. Бу исә уңышның нигезе дигән сүз.

Эшенә күрә ашы дигәндәй, акчаны да начар түләмәделәр. Цехның җәмәгать эшләрендә актив катнашып, хезмәттәшләрнең ихтирамын казандым. Абруем да бар, сүзем дә үтә кебек.

Бер уйласаң, шушы урында эшләп калу да мөмкин иде. Фатир алу исемлегендә дә беренче булып торам. Фатир алыр да, китеп барыр, дип бирми генә калмасыннар инде. Ә бәлки миңа заводның партия, профсоюз комитетларында эшләп караргадыр? Телем шома, кешеләр белән җайлы гына сөйләшә дә беләм, эшчеләрнең үз араларыннан чыккан ләбаса. Тәҗрибә дигәннәре акрынлап тупланыр иде әле. Берәү дә җитәкче булып тумый дөньяга.

Менә шундый уйларга уралып йөргән көннәрнең берендә интәшләр белән дипломнарны «юу» хакында сүз күештык. Ләкин бу мәҗлес кыл да сыймаслык ай ахырына туры килеп, бераз төерлерәк булып чыкты.

Смена мастеры белән алдан сөйләшеп куйган булсам да, план үтәлешенең язмышы хәл ителгән чакта эшне ташлап китү күңелне борчый иде. Баш та күтәрмичә икешәр смена тир түккән интәшләреңне калдырып китү – хыянәт кебегрәк килеп чыга. Ә инде, бер тарыдын барыбер ботка пешереп булмый, дип аклану партбюро әгъзасына бөтенләй дә килешми. Большевик булмасам да, коммунист ләбаса мин. Янәшә торып эшләүче дуслар ни әйтер? Күзгә туры карап әйтүчесе булмаса да, әллә ни уйлаулары бар. Иң авыры аның шул инде.

Сәгатьнең аты һәрчак җигүле: текелди дә текелди. Инде төшке ашны да ашап килдек. Ә кайтып китү мәсьәләсе һаман хәл ителмәгән. Берәр җирем авыртмыймы икән ичмасам, дип, тәнемне капшап карыйм, эчемә баскалыйм. Ләкин, үч иткәндәй, бер җирем дә авыртмый шикелле түгел. Башымның еш кына үтереп сызлый торган гадәте бар. Ул дүрт яшьлек чагымда ат тибүдән шулай булып калды. Бүген анысы да сиздерми. Үзеңә авыру теләү, чир чакыру юньле эш түгел инде ул. Тик бүген берәр җиремнең җиңелчә генә авырып китүенә бик тә риза булыр идем. Завод проходноеннан чыгып китү өчен генә дус-ишләр алдында үземне аклау өчен генә диюем. Аннары күз күрер иде әле. Табибка күренергәме, юкмы? Ләкин бернинди авыртту да, сызлану да юк. Әйтерсең, бөтен организмым план үтәргә керешкән, минем бәргәләнүемне ишетәсе дә килми.

Өйлә ялы әле бетмәгән. Мин дусларым янына курилкага юл тоттым. Белмәгәненне беләсең, ишетмәгәненне ишетәсең килсә, курилкага гына бар! Монда бәхәс учагы дөрләп, сүз казаны һәрчак кайнап торыр. Анекдотларның да иң зәһәрләрен ишетерсең, акыл-киңәш тә бирерләр. Акыллы кешеләр һәр җирдә бар бит алар. Зирәклек дигән тиңсез хәзинә дипломга кушып бирелми. Ул кешегә туганда ук Аллаһы тарафыннан салына. Күп кенә дипломлы кешеләрнең, хәтта хөрмәткә лаек зур галимнәрнең дә шыр җүләр икәнен күреп-белеп торабыз бит әнә.

Сөйләшә-сөйләшә сүз иярә сүз чыкканда, бәхәс кызганда кешеләрнең чын холкы ачылып, үзләре дә чишелеп китә. Кайчак хәтта елдар буе күңелләрендә йөрткән яшерен сер-

ләрен дә сүтеп салалар. Күптәнге дустың булып, аны тулысынча беләм дип йөргән кешенең дә бөтенләй башка сыйфатлары ачылып китә. Аның моңынчы үзе дә белмәгән сәләт-осталыклары чагылыш таба. Бу курилка атмосферасының үзенчәлегеннән килә, күрәсең. Монда һәркем хәр фикерле, тулы ирекле. Ә хакыйкать дигәнең бары тик ирекле кешеләр бәхәсендә генә туарга мөмкин. Аның шулай икәнен борынгы гректар инде күптән әйтеп, дәүләт белән идарә итү мисалында дәлилләп калдырганнар. Курилка демократиясенең асылы – аның хактан да ирекле булуында, күңелдәгене курыкмыйча әйтә алуында.

Тегесен-моңысын сөйләшеп, инде урынымнан торып китим дисәм, уң яктан корсак астын нидер чеметеп алгандай итте. Шул төшемне кулларым белән ышкып, баскалап карадым. Менә ул тынымны кысып, боргаларга ук тотынды. Тели белсәң – теләк, тели белмәсәң – имгәк, дигәннәре шушы буладыр инде. Гөнаһ шомлыгына каршы, азгын гозеремне Аллаһы Тәгалә ишетеп тә алган, озакка сузмый авыруын да юллаган булып чыкты. Хәзер инде теләсәм дә теләмәсәм дә медпунктка йөгерергә туры киләчәк.

Дежур табиб авырткан жиремне куллары белән тоткалап, бармак очлары белән баскалап карады да: "Аппендицитка охшаган. Сиңа кичекмәстән поликлиникага барырга кирәк булыр. Бар, тиз генә пропускыңны алып монда кил", – диде.

Ул биргән белешмәне тотып, цехка киттем. Аннан әйләнеп килгәндә ашыгыч ярдәм машинасы көтеп тора иде инде. Поликлиникага озата килүче шәфкать туташы мине терапевтка чиратсыз гына алып керде. Табиб, мине кушеткага яткырып, кулын корсак астыма батыруы булды, "аһ" дип бөгелеп үк төштем. Ләкин тиз генә үземне кулга алып, әлеге дә баягы гозеремне әйттем.

– Ресторан имеш! - диде табиб кырыс итеп. - Сез нәрсә моны үсн эш дип беләсезме әллә? Аппендицит беренче карашка гына жиңел авыру кебек. Аның белән шаярырга ярамый. Ул бик хәтәр һәм мәкерле нәрсә.

– Зинһар өчен дип сорыйм. Бу очрашу минем өчен бик мөһим, киләчәк язмышым хәл ителергә тиеш иде. Иртәгә иртүк килеп житәр идем. Йә жибәрегез инде.

– Беренчедән, мин сезнең белән иртәгә иртүк очраша алмыйм, икенчедән, хәзер сезнең киләчәк язмышыгызны мин түгел, авыруыгыз хәл итә. Тот шул жүләрнең кулыннан, жибәрмә! – диде табиб шәфкать туташына боерып.

«Күрмәгәннең күрәсе килә, күргәннең качасы килә», диләр. Минем белән дә шулайрак килеп чыкты. Табибә ханымның, киләчәгегезне авыруыгыз хәл итә, дигән сүзләрс мине айнытып жибәрде, шөбһәгә салды. Уеннан уймак килеп чыгарга да бик мөмкин ләбаса.

Ашыгыч ярдәм машинасы Киров районындагы 2 нче шәһәр хастаханәсенә юл алды. Чирсң кай жирдә – кулыц шунда, диләр. Мин дә сукыр эчәген кат-кат капшап карадым. Ул тынычланып калган кебек иде. Чәнчеми дә, сызламый да. Әллә бу зәхмәтнең узып китүе микән, дигән уй мине янә тегс очрашуга тарта башлады. Төрле тәмле ризыклар, тәмле сулар белән тулы табын, алар янында кукрасп утырган хәмер шешәләре күз алдыма килеп басты. Күңелгә кереп оялаган шайтан: «Кач моннан!- ди.- Сине анда дусларың, сәяркәләр белән рәхәтләнеп типтерүләр көтә!» - дип котырта. Чыннан да ник дип әле мин бармаска тиеш?! Хәләл акчамны башкаларга караганда да күбрәк итеп бирдем, бөтсн оештыру мәшәкатьләрен үз өстемә алып, тегендә чаптым, монда йөгердем. Ә хәзер хастаханәгә кереп ят, имеш. Шушы булдымы дөреслек?! Юк, ничек кенә булса да барырга кирәк!

Шушындый азгын уйлар белән вәсвәсәләнеп барган арада машинабыз хастаханә ишек төбенә килеп тә туктады. Без авырулар кабул итә торган бүлмәгә кердек. Шәфкать туташы кулындагы юлламаны өстәл артында утырган ике ир кешенең алдына китереп куйды. Минем карашым каршы як диварга эленгән сәгатькә төште. Аның зур теле көндезге икенче яртыны күрсәтә. Димәк, әгәр биш-ун минуттан китә алсам, очрашуга вакытында барып җитәм икән әле. Өстәл янына килеп, кыяр-кыймас үземнең гозеремне әйттем.

– Күтәр күлмәгеңне,- диде теге ирләрнең кояшта кызынган йөзлесе. Кавказ, Кырым якларында булып кайткандыр, күрәсең, загары безнең климатныкы түгел.

Ул бала башы кадәр йомыры йодрыгын корсак астына батырды һәм шунда ук тартып та алды. Мин тагын бөгелеп төштем. Эчемдә нидер өзелеп киткәндәй булды. Күз алдымнан аллы-гөлле түгәрәкләр җемелдәшеп очты.

– Хәзер үк операциягә!- диде әлеге ир, янәшәсендәге интәшенә карап.

Яртылаш бөгелеп төшкән гәүдәмнең ике ягыннан ике шәфкать туташы култыклап, өстерәп дисәң дә ярыйдыр, икенче катка алып менеп тә киттеләр. Әзерлек эшләрен тиз тоттылар. Ярты сәгать үтәр-үтмәстә мин операция өстәлендә ята идем инде. Авыз-борыннарын марля каплавычлар белән бәйләп, кабул итү бүлмәсендә утырган табиб белән кыйгач кара кашлы ханым эшкә дә керештеләр. Тәнемне кискәннәрен ныклап сизмәсәм дә, агып төшкән канның кайнарлыгын тойдым. Табиб үзенә кирәкле кораллarны биреп торучы әлеге ханымга әйтә куйды:

– Бик бәхетле кеше булып чыкты әле бу егеткәебез. Гомере бетмәгән, күрәмсең,- диде.

Ул арада бүлмәгә минем корсакка йодрыгын батырган

теге кеше дә килеп керде. Соңыннан белдем, ул бокс буенча Татарстан чемпионы, шушы хастаханәнең баш табибы икән.

– Йә, нинди хәзинә яшергән булган егетебез?

– Байлыгы зурдан. Мөлдерәмә үлекле аппендицит таптык. Тагын бер-ике сәгатькә соңарып килсә, бу «граната», һичшиксез, шартлаган булыр иде. Ул чагында исән калукалмау, үзең беләсең, Аллаһы кулында. Егет просто күлмәкчән туган икән...

Бу хәлләрдән соң менә инде 35 ел үтте. Ул вакытта минем үлем тырнагыннан тартып алган изге күңелле табибларга гомер буе рәхмәт укып яшәдем.

Көтелмәгән операция белән ресторанда очрашу арасында бәйләнеш бармы? Әллә бу авыру мине вакытында кисәтү, ниндидер бер күңелсезлектән саклап калу өчен кирәк булганмы? Язмыштан узмышлар юк, диләр бит.

Палатага кертеп салганда сәгать өч тулып килә иде. Инде очрашуга китсәм дә барыбер соңга калган булыр идем. Тәртипсез, тәрбиясез кешеләр генә мәҗлескә соңарып йөри, шуңа күрә палатада гына калыйм, дип шаярттым үз-үземә.

Шулай итеп мин биш ел буе укып алган дипломымны юмыйча калдым.

КЫҢГЫР ЭШ

«Белгән белгәнен эшләр, белмәгән бармагын тешләр», дигәннәр борынгы бабаларыбыз.

Миңа да, үзем белмәгән хәтәр эшкә керешеп, соңыннан бармагымны тешләргә туры килде. Ничек кенә авыртты-рып тешләдем әле! Хәзер дә булса теш эзләреннән кан саркып, яңагым сыкрап тора. Гомерлек төзәлмәс яра булып калды ул эзләр.

Казан рестораннары трестында сигез ел партком секретаре булып эшләгәннән соң, өч ел элек ремонтка ябылган «Казан» ресторанына директор итеп билгеләделәр мине. Әйтергә кирәк, хуҗалык аяныч хәлдә. Коллектив таркау, тәртип юк. Кем кая теләсә шунда китеп бара, ни теләсә шуны эшли, иртән эш бәя тәзәтүдән башлана.

Озак еллар буе бергә бер трестта эшләгәнлектән, ресторан коллективы мине белә. Үз чиратымда миңа мондагыларның һәрберсе диярлек яхшы ук таныш иде. Беренче көннәрдән үк ныклы хезмәт тәртибе урнаштырырга керештем. Арба ватылса — утын, үгез үлсә — ит дип, эленке-салынкы йөрүчеләрдән әкрен-әкрен арына бардык. Ә җаны-тәне белән булсынга эшләүчеләр иркен сулыш алып хезмәт итә-теләр. Ремонт эшләре бик авырдан булса да, көннән-көн җанлана барды. Партиянең шәһәр һәм Бауман районы комитетлары кирәкле ярдәмне һәрчак күрсәтә тордылар. Җәмәгать тукланулы идарәсе башлыгы Кәшшаф Ибәтуллин да еш кына килеп, йә булмаса ярдәмчеләрен җибәреп, эш

барышын һәрдаим күзәтеп торды, бөтен кирәк-ярак белән булышты.

Ул елларда производство биналары, бигрәк тә кунак залларының бик югары сыйфат белән эшләнгәндә генә комиссия тарафыннан кабул ителә иде. Шуңа күрә залларны бизәргә шәһәрнең иң оста рәссамнәре чакырылды. Үз һөнәрләренең чын профессионаллары булган бу сәнгать әһелләре эшне менә дигән итеп башкарып чыктылар. Тугыз ай дигәндә «Казан» ресторан иң матур, югары зәвык белән бизәлгән ханәгә әверелеп, кунаклар кабул итә башлады.

Ләкин миңа үземә көнне төнгә ялгап башкарган шушы эшемнең игелеген күрү насыйп булмады. Шәһәрдәге ресторанларны бер-бер артлы баштанаяк төзәттереп, кирәк җирләрен үзгәртеп, уңайлы итеп төзеткән трест җитәкчесе Тәһир Нәби улы Хәсәнов эштән киткәннән соң, аның урынына Ураний Гали улы Вәлиевне китереп куйдылар. Без беренче көннәрдән үк аның белән бер-берсен сөймәгән килеш һәм кайнана кебегрәк булып киттек. Бер-беребезгә ияләшеп, килешеп, тату гына эшләп китә алмадык. Җыелышларда да әледән-әле эләгешеп алып, этле-мәчеле булдык. Һич тынышып тормадык.

Моңа кадәр җиләк-җимеш һәм яшелчәчелек трестын җитәкләгән бу кеше җәмәгать тукланулы системасының асылын, аның гаҗәп тә үзенчәлекле эш тәртибен, үзенә генә хас яшерен серләрен бөтенләй белми иде. Шуның өстенә яңа җитәкче бу хезмәттә озак еллар эшләп, зур тәҗрибә туплаган остазларның акыллы киңәшләренә колак салмады. Эшне яхшыртуга юнәлдерелгән чыгышларны үзен кимсетү, түбәнсетү дип кабул итә һәм җае табылганда (кирәксә җаен һәрвакыт чыгарып була), эчке бер канәгатьләнү белән алардан үч ала иде. Трестның алтын фонды булып исәпләнгән күп кенә производство мөдирләре, участок җитәкчеләре,

хәтта алтын куллы аш пешерүчеләр дә башка трестларга китүне кулай күрделәр.

«Казан» ресторанының ачылуының икенче көнендә үк шушы кеше мине үзенә чакыртты.

— Син ремонтны уңышлы башкарып чыктың. Эш барышында күп кенә төзәлеш оешмалары һәм башка предприятиеләрнең җитәкчеләре белән танышып, үзара дустанә элемтәләр булдырдың. Тәҗрибәң дә җитәрлек. Шушы уңай фактларны искә алып, югары партия һәм хуҗалык органнары белән киңәшеп, килешеп, сине Киров районындагы «Кызыл ашханә»гә җибәрергә булдык. Алдан ук кисәтеп куям: бик авыр участок. Әгәр риза булсаң, приказга хәзер үк кул куям,- диде.

Күрәм, карышып торуның файдасы булмаячак. Алдан белешеп куйган башка кулай эшем дә юк. Нишлисең, ризалашырга туры килде. Чөнки үз урынымда калсам, хәтта партия органнары да мине бу бәндәнең явызлыгыннан яклый алмаслар иде. Ул, төрле сәбәпләр табып, юкны бар итеп күрсәтеп, барыбер үз этлеген эшләр иде. Бу хәйләкәр, мәкерле гамәлен ул производство мәнфәгатьләрен кайгырту, план үтәлешен җайга салу максатындагы бер эш итеп күрсәтер иде. Ә болай бер атуда ике куян аткан булып чыга. Беренчедән, миннән — һәрвакыт керпе кебек чәнчеп торган бер башбирмәстән котылса, икенчедән, еллар буе хуҗасыз торган участогына җитәкче билгели.

Минем кул астында халык арасында «Кызыл ашханә» дип исем алган бу ханәдән тыш «Прибой» ресторан, балык кафесы, Фрунзе урамындагы диетик ашхәнә кебек үзләре аерым бер эре хуҗалык булып мөстәкыйль эш алып барырлык җәмәгать тукланулы предприятиеләре бар иде. Алар ремонтка ябылган булсалар да, кухнялары эштән туктамады. Ашчылар, кондитерлар пәрәмәч, өчпочмак, кыстыбый кебек төрледән-төрле чәй ризыклары, тәм-томнар әзерләп, Киров районының үзәгендәге данлыклы «Кызыл капка» тирәсенә урнашкан киосклларда, Петров паркында, почмак-чатларда сата идек. Ә инде шимбә -якшәмбе көннәрендә халыкның гадәти ял итү урыннарына машиналар белән барып сәүдә оештырдык. Аккош күле буена төзелеп киткән барлык ашату-эчертү урыннары безнеке булып, аларда җәен-кышын эш туктап тормады. Болардан тыш якын-тирәдәге барлык мәктәп ашханәләре, буфетлары да безнең карамакта иде. Кыскасы, әле тагын Киров районының буеннан буена сибелгән эреле-ваклы 22 иярченебез бар иде.

Әйткәнемчә, «Прибой» ресторанында, балык кафесында, диетик һәм «Кызыл ашханә»нең үзендә башланып, бик акрынлык белән барган ремонт эшләрен очлап чыгарга кирәк иде. Йә төзелеш материалларының булмавы, яисә башкасының җитешмәве күп вакыт эшне туктатып тора. Киров райкомында Бауман райкомындагы кебек дуслар юк иде шул. Танып-белеш бар барын, ләкин аларның ишекләрен киң ачып кереп, Баумандагылардан алган кебек ярдәмне өмет итеп булмый. Кергәләгән очракта да: «Сезнең үз җитәкчеләрегез бар, шулар кайгыртсын», - дип кенә җибәрәләр. Ә менә җыелышып килеп, бушка ашап-эчеп китәргә дигәндә онытмыйлар иде.

Районның ашханәләр тресты директоры әзербәйҗанлы Мамедовның җитәкчеләр каршында бернинди абруе булмавы да эш барышына, план үтәлешенә тискәре йогынты ясый килде. Ул заманда планны үтәмәү закон бозуга тиң иде. Мондый «закон бозучылар»ны райком, горком бюроларына чакыртып пешеклиләр иде. Кирәк тапсалар, партбилетыңны өстәлгә куеп кайтып китүең дә бик ихтимал. Ә бу инде сине исемлектән сызып ташладылар дигән сүз. Синең

өчен кара эшче булып эшләүдән гайре барлык юллар да мәңгелеккә ябыла. Хәтта «Дело» да ачарга момкиннәр әле. Азык-төлек базаларыннан, сөт, ит комбинатларыннан, «Заря» фабрикасы кебек тәм-том ширкәтләреннән наряд буенча бүлеп бирелгән товарларның планның күп дигәндә 70 процентын гына капларга җитүе дә сәбәп һәм дәлил була алмый иде. «Булдырган – җаен таба, булдыксыз – сәбәп таба,» – дип кенә җибәрәләр. Бүрене аяклары туйдыра дигәндәй, ары йөгереп, бире чабып, җитешмәгән 30 процент товарны үзеңә казганырга туры килә Мәскәү, Ленинград кебек башкалалардан ташып, тегесен җайлап, мопысын майлап, күп очракта шул чорның законнарын бозып, бик авырлык белән очын-очка ялгый идек ул планнарның.

Шулай җайлый, майлый торгач, ниһаять, без дә читтән дефицит һинд чәен юнәтүгә ирештек. Инде, иншалла, планнарны үтәп чыгу насыйп булыр, дибез. Әвәле-ахыры хәерле булып, исән-имин генә сатып бетерергә язсын, дип телибез. Склад мөдире дә, производство җитәкчесе дә беравыздан:

– Рәис Абдуллович, сату мәсьәләсен үзебезгә тапшырыгыз. Без аны үзебез җайлыйбыз,- диләр.

Беләм мин аларның арт ишектән шыпырт кына танышбелеш, туган-тумачаларына итәк астыннан сатып «җайлаганнарын». Туктале, мәйтәм, төмле хуш исле һинд чәеннән дары заводы эшчеләре дә авыз итсен! Тиз генә бер сатучыны чакыртып, чәйне машинага төяттем дә, эшчеләр эштән чыгуга завод ишеге төбенә китереп бастырдым. Халык томырылып ала калды, мин, игелекле эш кылуымнан канәгатьләнеп, эш бүлмәмә кайтып кердем.

Ярты сәгать тә үтмәгәндер, яныма, рөхсәт-мазар да сорап тормыйча, олы яшьтәге өч кеше килеп керде. Минем урын тәкъдим итүемә дә исләре китмәде боларның. Эшем кешеләре кебек сорау яудыра башладылар.

– Завод проходное төбендә һинд чәен сезнекеләр сатамы?- дип сорады төбәнәк юан гәүдәлесе.

Урыс сүзләрен вата-җимерә сөйләвенә караганда, ат дагалаганда ботын кыстырган бака шикелле, түрә булу кулыннан килмәсә дә, чабатасын түргә элергә омтылучан бу бәндә үзебезнең татар кешесе иде. Аның табактай битендәге тиресе элеп куелган кер кебек салынып төшкән.

– Әйе, безнекеләр.

– Ә син кемнән рөхсәт сорадың? Нигә чәйнең кабына ике тиен өстәмә куеп сатасыз? Бу совет сәүдә кагыйдәләрен тупас бозу. Син аның шулай икәнен беләсеңме?

– Беләм.

– Белгәч... Димәк, һәр каптан кергән ике тиенне кесәңә салырга уйлаган идең, шулаймы?

– Юк, кесәмә салу үземдә дә юк. Һәм мин ул тиеннәрне теләсәм дә, кесәгә сала алмыйм. Чөнки һәр товарга накладной язылып, бухгалтерия аша үткәрелгән. Ә ике тиен өстәмә куелуның сере шунда: ул чәйләр безнең ашханәләрдә кайнатылып, кешеләргә стаканнарга салып бирелергә тиеш иде. Ягъни кухня продукциясе итеп. План үтәү теләгеннән чыгып, без аны товар рәвешендә, ләкин кухня аша үткән чәй бәясеннән сатарга булдык.

– Хезмәт тыкмый гына керем алырга уйлыйсыз инде,- диде читтәрәк басып торганы.

– Барысы да аңлашылды,- диде татар дигәнебез.

Көтелмәгән кунаклар үзгәреп, җанланып киткәндәй булдылар. Аларның җыерчыклы йөзләре бер мәлгә яктырып алды, ләкин аларда зәһәрлек, нәфрәт чаткылары да юк түгел иде.

– Без районның халык контроле әгъзалары булабыз,- дип, таныклыкларын күрсәттеләр.

Арадан берсе, рөхсәт тә сорап тормыйча, өстәлемдәге телефоннан милициягә шылтыратты.

— Эчке эшләр бүлегеннән вәкил килмичә сез беркая да китмисез!- диде ул.

Вәкил озак көттермәде. Ул туташ булудан узган, әлегә ханым дип әйтерлек яшькә кермәгән чандыр гәүдәле хатын-кыз иде. Барысы да өстәл тирәли утырып, миннән сорау ала башладылар.

— Чәйгә икешәр тиен өстәп сатарга сез рөхсәт иттегезме?

— Мин.

— Сатучыга сез сатарга куштыгызмы?

— Мин.

— Бухгалтерия накладнойларны сезнең рөхсәт белән яздымы?

— Минем рөхсәт белән.

Тагын бик күп сораулар биредде. Бөтен жаваплылыкны үз өстемә алгач, милиция вәкиле протокол язып, халык контроле әгъзаларыннан да кул куйдырып, чыгып китте. Аның артыннан картлар да иярде.

Һай, нинди горур иде алар! Ул миңа карап хәйләкәр елмаю дисеңме, «Знай наших!» имеш. Зур жинаятьчене тоткан кебек кукрасп, күкрәкләрен киереп торулары дисеңме. Чыгып барышлый бүлмә ишегенә аяклары белән генә тибеп, хушлашмый да китеп барулары дисеңме... Берлиниы алган каһарманнар да болай ук кыйланмаганнардыр, валлаһи. «Ит яхшылык, көт явызлык»ның классик үрнәге булды инде бу.

Бу хәлләрдән соң өч ай тирәсе вакыт узып китте. Теге милиция хатын мине үзенә чакыртып, һаман да шул ук сорауларын кабатлап, янә беркетмәләр язып, аңа миннән кул куйдырып кайтарып жибәрә торды. «Бу ни дигән сүз

була соң инде?»- дигән соравыма каршы: «Үзем дә белмим әле», — дип жавап бирә килде.

Көннәрнең берендә янә милициягә чакыргтылар.

— Ниһаять, шаһитлардан сорау алынып, аңлатмалар яздыртып, тикшерү эшләрен төгәлләдек,- диде минем «Эш»не алып барган хатын. - Йөкләнгән вазыйфаларыгыздан явыз ниятгә файдаланган өчен бер елдан жиде елга кадәр, совет сәүдәсе кагыйдәләрен бозган өчен өч елдан биш елга кадәр хөкемгә тартылуыгыз ихтимал. «Эш»егезне хәзер үк судка тапшырачакбыз. Суд утырышы иртәгә иртәнге сәгать унда башланачак. Менә чакыру кәгазе, соңга калмый килегез. Ә хәзер «Эш»егез белән танышуыгызны һәм судка чакыру кәгазе алуыгызны раслап кул куегыз.

Чынлап-чынлап еласаң, сукыр күздән яшь чыга, диләрме әле? Бик тырышканда бер гөнаһсыз кешенең дә гаебен табып була икән шул. Уйнап кына башланган кебек тоелган эш уймак чыгарды да куйды. Уйламаган-көтмәгән жирдә килеп чыккан бу хәл өнсез калдырды, башка тимер таяк белән китереп суккандай булды. Милиция бүлегеннән аңлы-миңле булып урамга чыктым һәм кая барырга белми аптырап калдым. Бераздан аяклар ирексездән Киров райкомына таба атлады. Баруын барам, ләкин нәрсә эшләргә кирәген белеп түгел. Күземә ак-кара күренми, акылым томан эчендә. Кем уйлаган диген? Хөкүмәтнең баштан ашкан планын үтәү уе белән, кешелэргэ яхшылык кылмакчы булып тотынган эш өчен төрмәгә утыртырга жыенсыннар әле. Шушы булдымы дөреслек?!

Райкомның икенче секретаре Мачтаков Николай Васильевич мине берсүзсез кабул итте. Мәсьәләне бәйнә-бәйнә сөйләп бирдем. Ул телефонын алып, милиция бүлегенә анан район суды рәисенә шылтыратты.

— Моңынчы нәрсә караган соң ул Сафин дигән бәндәгез?

Әгәр алдан хәстәрен күргән булса, бу чүп безгә килеп тә җитмәгән булыр иде. Ә хәзер «Эш» теркәлгән, аны кире алу һич мөмкин түгел. Тик суд карары нигезендә, кайбер төгәлсезлекләр ачыкланмаган, дигән сәбәп белән генә аны тикшерүчеләргә кайтарып була. Анда инде үзегез хәл итәрсез. Йә булмаса, район прокуроры «Эш»не бүген үк үзенә соратып алырга мөмкин,- диде судья.

Секретарь елмаеп куйды. Урынныннан торып яныма килде һәм кулын иңемә салып: «Борчылма, берәр җаен табарбыз,- диде.- Һәрнәрсәнең башы һәм очы була. Ә хәзер бернәрсә булмагандай эшеңә бар. Хафалануыңны хәтта эт тә сизәрлек булмасын...»

Әгәр бер-бер көтелмәгән хәл була калса, дип, өй телефонын да бирде. Аның сүзләре эчкә бераз җылы кертеп, өмет чаткылары уятса да, мондый чакта ничек борчылмый-хафаланмый калмак мөмкин соң? Көнем томан эчендә төнем мең төрле вәсвәсә-саташулар белән үтте.

... Иртән эшкә килүемә, сине прокуратурага чакыралар, диделәр. Ни булса, шул булыр, дигән бер битараф тәвәккәллек белән закон сакчысының ишеген ачтым. Ул үз каршыннан урын тәкъдим итте.

— Мин сезнең хакта кирәк кадәр мәгълүмат тупладым, - диде ул , исәнләшеп, бер–беребезгә хәерле иртә теләгәннән соң. - Биографиягезне дә өйрәнеп, тормыш һәм хезмәт юлыгызны күздән кичердем. Дөресен әйткәндә, сезнең турыда уңай фикердә калдым. Минем бу уй-фикерләремне прокурор Кафил Әмиров та раслады. Ул сезне яхшы кеше, намуслы иптәш дип саный. Сезгә уңай бәя бирә..

Әйе, кайчандыр трест җитәкчесе булып эшләгән Тәһир Хәсәновны ришвәт алуда гаепләп тикшерү эшләре алып барган Кафил Фәхрази улы янында берничә мәртәбә миңа да булырга туры килгән иде. Юк, Хәсәновның гайбәтен сатып, аның исемен пычрату өчен түгел, ул эш хакындагы фикеремне прокурорга җиткерү өчен генә.. Кафил әфәнде ул чакта миннән, партком секретаре буларак, коллективтагы вәзгыятьнең торышын, тәртип-тәрбия мәсьәләләренең ни хәлдә булуын сорашты һәм управляющийның бу мәсьәләләргә карашы, аның проблемаларны уңай хәл итүгә керткән өлеше, парткомга ярдәме белән кызыксынды. Берочтан Хәсәновның әдәп-әхлак ягына да кагылып үтәргә онытмады. Мин, үз чиратымда, трест җитәкчесенә карата яхшы фикердә булуымны, аның үтә тырыш, принципиаль кеше икәнен сөйләп бирдем.

Әлбәттә, управляющий Тәһир Хәсәнов ришвәтчелектә гаепләнеп кулга алынгач, «Волга» ресторане директоры Юрий Кошелев һәм тагын берничә ресторанның производство мөдирләре белән берәттән, читләтеп кенә булса да, миңа да кагылып үттеләр. Мине дә җиз иләк аша үткәрделәр. Әгәр әнә очы кадәр генә гаеп тапсалар да, һичшиксез, мине дә кулга алачаклар һәм суд каршына бастырачаклар иде. Чөнки моның шулай булуын теләүчеләр дә юк түгел иде. Аллаһыга шөкер, эш урынымнан начар ният белән файдалану, банкет залларында бушка типтерү кебек гөнаһларым булмады. Намусымны һәрчак чиста тотарга кирәклеген истән чыгармадым, шайтан көткысына бирелмәдем. Шушы якларымны искә алып, трест коммунистлары ышаныч белдереп шул елның көзендә мине бишенче тапкыр үзләренең лидерлары итеп сайлап куйдылар. Ә бит, гадәттә, өстәмә җитәкчесенең гаебе ачылып хөкемгә тартылганда, партия өстәмәсы секретарен, һичбер гөнаһы булмаса да, автомат рәвештә эшеннән алалар иде ул елларда. Һич югында кисәтеп, каты шелтә бирәләр иде. Миңа бу күңелсез хәлләрнс, шөкер, күрергә туры килмәде. Чөнки партия каршында күңелем чиста, ниятем изге булды. Шуңа күрә

югары партия органнары бишенче мәртәбә сайлануга фатихаларын бирделәр. Бу минем үземә, намуслы хезмәтемә югары бәя иде.

Прокурор бу хакта яхшы белгән, тиешле урыннардан уңай характеристика алган, күрәсең. Ул сүзен дәвам итте:

– Сезнең намуслы кеше булуыгызны, үз мәнфәгатьләрегезне кайгыртып, пычрак эшләрдә катнаша алмавыгызны аңладым. Ләкин кайчак намуслы кешеләрнең дә хаталанган чаклары була. Әйтик, менә сез гафу ителмәслек җинаятьтә гаепләнәсез. Менә шулай, кадерле дускай. Инде нишлибез?

Бүлмәдә шомлы тынлык урнашты. Мин чатнап кипкән телемне әйләндереп берни әйтә алмадым. Гаепсезлегемне исбатларга тырышу артык сыман тоелды. Ул болай да күренеп тора бит инде. Әгәр чәй саткан акчаның бер тиенен генә кесәбезгә салган булсак та, монда чакыртып та тормаслар иде.

Ниһаять тынлыкны прокурор бозды.

– Сезнең намуслы кеше булуыгызны искә алып, исемегезне нахакка пычратасы килмәүдән чыгып, бөтен җаваплылыгын үз өстемә күтәреп, бу эшне ябарга уйлыйм.

– ...

– Әгәр үзегез риза булсагыз, әлбәттә. Тик бер шарт белән: бүтән беркайчан да сәүдә системасында эшләмәскә сүз бирергә тиеш буласыз. Чөнки сез сәүдә кешесе түгел, сәнгать кешесе. Ә андыйларны сәүдәгәр халкы һәрвакыт төп башына утырта. Сәнгать кешесенең сәүдә системасында буталып йөрүсенең һич кирәге юк. Сезнс батырырга теләүче дошманнарыгыз аз түгел. Бу комедияне кем әвәләде дип уйлыйсыз? Әнә шул сәүдәгәрләр. Алар сезнең «Эш»не ахырына кадәр җиткерүне таләп итеп, югары органнарга шикаятьләр яздылар, Мәскәүгә кадәр барып җитү белән янадылар. Әгәр дә вәгъдәгезне бозып, тагын сәүдә эшенә керәсез икән, анда

сезне тагын да зуррак күңелсезлекләр көтеп торачак. Бу юлы алар инде сезне болай гына җибәрмәячәкләр. Менә бу «Эш»егезне дә искә алып, зур гаепләр өештырачаклар. Әлбәттә инде, мине дә бик уңайсыз хәлдә калдырачаксыз...

Көтелмәгән бу хәлдән мин тагын бер мәртәбә өнсез калдым. Шатлыктан баш әйләнеп китте. Тотлыга-тотлыга, өзектәтек җөмләләр белән башка беркайчан да сәүдә системасында эшләмәскә сүз бирдем.

– Тынычланыгыз, мин сезгә ышанам, - диде прокурор. - Э хәзер барыгыз, трест директорының эштән китүегез турындагы приказын миңа китерегез.

Мин мең рәхмәтләр әйтеп чыгып барганда ул тагын туктатты.

– Менә сезгә бер визитка. Әгәр кирәк тапсагыз, минем исемнән шылтыратa аласыз...

Моңынчы күрмәгән-белмәгән бу ике кеше - Николай Васильевич һәм әлеге прокурор миңа әйтеп бетергесез яхшылык эшләделәр, төрмәдән алып калдылар. Югыйса мин аларга анкеталар аша гына таныш идем бит. Гаебемнең булу булмавы - икенче мәсьәлә, анысын суд күрсәтер иде. Ин кадерлесе - хакыйкатьнең җиңеп чыгуы. Нинди генә чор килсә дә, дөреслекне яклап көрәшүче батыр йәрәкле, җаваплылыкны үз өсләренә алудан курыкмаган тәвәккәл кешеләр булды. Болар җәмгыятьнең умыртка баганалары, замана маяклары. Мең рәхмәт андый көчле ихтыярлы кешеләргә Әлеге прокурор хәзер инде республикада мәгълүм шәхес, ике чакырылыш дәвамында ТР Дәүләт Советында гражданнарның хокукларын саклау комитеты белән җитәкчелек иткән, бүген исә ТР Кеше хокукларны саклау комитеты рәисе Рәшит Гаяз улы Вагыйзов иде.

Кичкә таба директор вазыйфаларыннан азат ителеп,

иңнәремнән тау төшкәндәй булып калгач, теге визиткада күрсәтелгән телефон номерын җыйдым.

– Иртәгә килегез, сөйләшербез,- диде ягымлы тавыш.

Берничә көннән мин, югары органнар белән килешеп, зур берләшмәнең генераль директоры урынбасары булып эшли башлаган идем инде. Уңай агымга бер эләксәң, җае үзеннән-үзе чыгып тора бит аның. Алты ай дигәндә ике бүлмәле яңа фатир хуҗасы да булдым.

Үз гомеремдә мондый хәлләр берничә мәртәбә кабатланды. Минс батырырга, юк итәргә теләүчеләргә үч иткән кебек, ниндидер илаһи көч үземне һаман саен өскә этәрде, дорожәле урыннарга менгерде, көтелмәгән уңышлар китерде. Чөнки янәшәмдә заманында зур берләшмәләрнең партком секретарлары булып эшләүче, Тимергалиев Дамир Шәйхи улы, Бакиров Рафис Гыйният улы кебек ышанычлы, изге күңелле дусларым булды. Бу хәлләрне күзәтеп торган көндәшләрем ачуларыннан шартлар дәрәҗәгә житәләр иде. Мин исә бу явыз кешеләргә үч тотмадым. Киресенчә, кулымнан килгән кадәр ярдәм итәргә тырыштым. Дошманым дип йөргән кешенең сина игелекле булуы, изгелек кылуы – иң авыр җәза бит ул. Әнә шуны тойган дошманың үзен бурычлы дип хис итә. Әнә шул бурыч аны эчтән кимерә, тынгы бирми, зиһенен чуалта.

...Бу хәлләрдән соң күп вакытлар үтте, дөнья үзгәрде. Шулай беркөнне Тукай урамы буйлап барганда бөкерәеп беткән бер карт кешегә игътибарым төште. Көч-хәл белән атлавын күреп, кызганып куйдым үзен. Өс-башы да мактанырлык түгел. Хәзер моннан яхшыракларын да чүп савыты янына куеп китәләр. Ирексездән бу кешенең йөзенә бактым һәм сискәндем. Ул Ураний Вәлиев иде. Эсселе-суыклы булып китте. Аның чандыр, кайчандыр зәһәрлек ургылып торган чыраен җыерчыклар каплап киткән, ул көзге көн кебек

нурсыз иде. Әле кайчан гына очкын чәчеп торган күзләре эчкә баткан, алардан сагыш саркый, газап ташый сыман. Әйтерсең гөнаһсызга рәнҗетелгән, урынсызга кимсетелгән кешеләрнең рәнҗеше, бәддогалары аның иңнәренә баскан. Бернәрсә дә эзсез генә үтми шул.

ЭЧТӘЛЕК

Тәкъдиренә каләм язылган 3
Бер мәхәббәт тарихы 7
Сәфәр чыктым хәтер буйлап... 54
Авылны казлар уятты 90
Батыр шайтан 95
Әүлия 101
Җенле кичәләр 107
Корчаңгы 115
Минем дә эш көнем бар 129
Кавалерист 133
Кияүсез туй 149
Тунымны сатсам сатам 186
Эшләп укуның үз тәме бар 193
Нимесчә дә яхшы бел! 201
Сукыр эчәк һәм юылмаган диплом 205
Кынгыр эш 212

Раис Абдуллович Сафин

История любви

Повести, рассказы

(на татарском языке)

Лицензия № 0209 от 06.10.97

Сдано в набор 21.11.2005. Подписано к печати 30.01.2006.
Формат 60x84 1/16. Бумага офсетная.
Гарнитура «Таймс». Печать ризографическая.
Усл. печ. л.14.25. Тираж 500 экз. Заказ К-19.

Министерство образования и науки РТ
Редакционно-издательский центр «Школа».
420111, Казань, Дзержинского, 3. тел.: 292-24-76
Отпечатано на множительном участке центра.